Безнең МИРАС
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
11
ноябрь 2022
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Югалып табылган авыл

18 бит

Кадыкай абыз

38 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең мирас
12 +
11
(347)
ноябрь 2022

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Зәки Нури

ТАРИХИ МИРАС

4 Чынлы егете – Мәрҗанинең тугры варисы. *И.Закиров*
11 «Безнең дәвернең кыяфәте». *Б.Урманче*
16 Сафиулла бине Габдулланың кабер ташы. *А.Гайнетдинов*
18 Югалып табылган авыл. *В.Данилов*
27 Уби риваятьләре. *А.Сабирова*
30 Чүпрәле – үткән заманнарда. *И.Гафаров*
34 Зирәк чуаш хатыны күлмәге. *А.Сабирова*
36 100 ел элек татар дөньясы
38 Кадыкай абыз. *И.Закиров*

ТАТАР ГАМЕ

48 Марат Гафаров: «Күп тел белгән кешенең рухи дөньясы баерак»

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразыев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рузәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррирләр
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)
Айзилә Сабирова
(843) 222-09-83 (17-92)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкаләләр авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

52 Мунчәли – бай тарихлы һәм мәдәниятле авыл. *И.Измайлов*
55 Ильяс хәзрәт Җиһаншин: «Өстебезгә бик зур җаваплылык алдык»
58 Үрдә. *М.Талипова*
64 Без – Иманкол бабай оныклары. *И.Халитов*
69 «Безнең мирас» котлый!

ДИНИ МИРАС

70 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
76 Бертуган Хәмидиләр мирасы. *Н.Мәхмүтов*
83 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*

ӘДӘБИ МИРАС

84 Шәрәф Мөдәррис шигырьләре
86 Үлемсезлек җырчысы. *Н.Хисамов*
88 Хәйдәр Гайнетдин: «Гел көтмәгән җирдә ява карлар...»

ХӘТЕР САНДЫГЫ

90 Хаҗ сәфәре. *Л.Лерон*
98 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

100 Халык җырчысы. *А.Хәкимова*
106 «Балкый Шәйморза утлары» җыры

ТАБИГЫЙ ЯДКЯРЛӘР

108 Өрәңге

СИХӘТЛЕ МИРАС

109 Өрәңге дәвалый

ТАТАР РИЗЫГЫ

110 Килен төшә – тура пешә

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Ноябрь*

76

100

Заказ №О-3217. Тираж – 2320 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 28.10.2022. Чыгу көне: 03.11.2022.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе иркле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Шагыйрь Шәрәф Мөдәррис һәм аның хатыны – балалар язучысы Ләбибә Ихсанова

Бердәм булып аяк типсә халык,
Тетрәтергә мөмкин җирне дә!

Зәки Нури

Рәсемдә (сулдан уңга): Шагыйрь-партизан, Чүпрәле районының Татар Төкесе авылы тумасы Зәки Нури (1921-1994) һәм фронтовик язучы, Яшел Үзән районының Татар Танае авылы тумасы Афзал Шамов (1901-1990). 1960 ел

Безнен мирас №11 ноябрь 2022

ЗӘКИ НУРИ*

(24.12.1921-18.02.1994)

Икмәк белән кеше – җир күрке,
Икмәк – җиңү, икмәк – көз дәрте.
И туган кыр, сине матур итә,
Батыр итә кеше хезмәте.

***

Җиребезгә җылы кояш нуры
Килгән кебек ерак-ерактан,
Яхшы сүз дә җан җылыта ала,
Чыкса әгәр кайнар йөрәктән.

***

...Зирәклегең – ярсыганда,
Дуслык хисең кыен чакта сыналачак.
Дуслык гөле – кадерле гөл барысыннан да,
Шул сынауда сынатмаса – сулмаячак!

***

Тынычлык ул – безнең тырышлык;
Тынычлык ул – булсын дигән сүз
Уңыш мул, нефть күп, корыч нык.

***

Йөрәк икән – яратмыйча типмәс,
Көрәш икән – җиңми калмабыз.
Гомер икән – бушка янып үтмәс,
Ә ил кушса – куркып янмабыз.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

---

*Зәки Нури (Зәки Шәрифҗан улы Нуретдинов) 1921 елның 24 декабрендә хәзерге Татарстан Республикасының Чүпрәле районындагы Татар Төкесе авылында туган. 1951 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. 1994 елның 18 февралендә вафат булды.

Чынлы егете – Мәрҗанинең тугры варисы

(Сафиулла бине Габдулланың тормыш юлы)

Иршат Закиров

Хан Урдасы мәчете

Мәрҗани Чүпрәле төбәгендә кимендә өч мәртәбә булган!

Бөек татар мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗанинең Чүпрәле төбәге белән бәйләнеше әлегәчә тиешенчә яктыртылганы юк. Безнеңчә, бу легендар шәхеснең тормыш юлындагы һәр мизгел, нәселенең һәр тармагы тулы һәм төгәл өйрәнелергә тиеш. Билгеле булганча, Ш.Мәрҗанинең әнисе Хөбәйбә ягыннан бабасы Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек – Сембер губернасының Буа өязенә кергән Иске Чокалы авылыннан. Аның ата-бабалары исә безнең яктагы Татар Шатрашаны һәм Татар Бизнәсе авылларында мулла булган. Әлегә без Шиһабетдин Мәрҗанинең Чүпрәле төбәгендә 1848 һәм 1860 нчы еллар-да булып киткәнлеген һәм бабаларының каберләрен зиярәт кылганын төгәл

беләбез. Бу хакта ул үзенең «Мостафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле хезмәтендә язып калдырган.

Сәйфелмөлек мулла, аның әтисе Мозаффар бине Мортаза, бабасы Мортаза бине Гали күренекле дин эшлеклеләре һәм танылган галимнәр булган, китаплар һәм дәреслекләр язган. Бу нәселләрдән Сембер һәм Казан губерналарында танылу алган бик күп имам-мөдәррисләр чыккан. Әмма алар турындагы белемнәребез шактый аз. Һәрнәрсә белән тирән кызыксынучан, күпне белергә омтылучан Мәрҗани хәзрәтләре Чокалы һәм Бизнә авылларында яшәүче туганнары турында мәгълүмат тупламыйча калмаган булырга тиеш. Әмма алар аның нинди хезмәтләрендә чагылыш тапкан? Галимнең бай мирасы һаман да өйрәнелеп бетмәү сәбәпле, бу сорауга анык җавап биреп булмый.

Алда әйтелгән ике сәфәреннән тыш, Шиһабетдин Мәрҗани Чүпрәле якларына үзенең вафатына чаклы, 1880 нче елларда кимендә тагын бер мәртәбә килеп киткән дип фаразларга тәвәккәлләдек. Мәрҗани бу төбәкнең кодасы да булган бит әле! Ә кода-кодачаны кунакка чакыру – татар халкында иң матур йолаларның берсе.

Мәрҗанинең шәкерте һәм кияве

Сүзебез күренекле якташыбыз, дин эшлеклесе, Ш.Мәрҗанинең фикердәше һәм кияве, 1849 елның 25 декабрендә Сембер губернасының Буа өязендәге Кече Чынлы авылында туган Сафиулла бине Габдулла хакында.

Кече Чынлы – хәзерге Чүпрәле районындагы иң зур авылларның берсе. Ул халкының мул тормышы, андагы «Цильна» хуҗалыгының уңышлары белән республикабызда гына түгел, илдә дә танылган. Сафиулла бине Габдулла исә – Шиһабетдин Мәрҗанинең яраткан шәкерте, эшенең дәвамчысы, татар мәгарифе тарихында тирән эз калдырган шәхесләрнең берсе. Бу галимнең эшчәнлеге әлегә чаклы тирәнтен өйрәнелмәгән һәм аңа тиешле бәя бирелмәгән дип саныйбыз. Аның дистә елга якын казакъ далаларында ислам динен таратуы һәм балалар укыту белән бәйле хезмәте, Казанга кайтып, таркалыр дәрәҗәгә җиткән «Мәрҗани» мәчетен һәм аның каршындагы мәдрәсәне аякка бастыруы гына да ни тора!

Сафиулла бине Габдулла турындагы тәүге мәгълүмат 1850 елның 16 июлендә Кече Чынлыда үткәрелгән ревизия язмаларында (ревизские сказки) урын алган. Анда 136 нчы сан белән лашман Кафис Шәмсетдинов гаиләсе теркәлгән. Бу гаилә составына, Кафисның үз гаиләсеннән кала, аның өч энесе – 33 яшьлек Хәбибулла, 31 яшендәге Габдулла һәм 27 яшьтәге Миңлебай Шәмсетдиновлар да кергән. Аларның һәр өчесенең дә үз гаиләләре булган. Габдулла Шәмсетдинов гаиләсендә 25 яшьлек хатыны Арифә Гобәйдуллова һәм алты айлык улы Сафиулла да язылган.

Сафиулланың әтисе указлы мулла була. Әлбәттә, улын ул киләчәктә укымышлы дин әһеле итеп күрә. Сафиулла 1867 елда Казанның «Мәрҗани» мәдрәсәсендә укый башлый, мәшһүр Шиһабетдин Мәрҗанинең үзеннән белем ала. Тырыш, башкаларга үрнәк шәкерт була ул. Сафиулла бине Габдулла, 1874 елда мәдрәсәне уңышлы тәмамлап, Буа өязендәге Кече Чынлы авылы мәчетендә имамлык итүгә указ ала. Күпмедер вакыт узгач, аны Буа мәдрәсәсенә мөгаллим итеп чакыралар. Анда ул гарәп теленнән дәресләр бирә. Шиһабетдин

Мәрҗани үзе укыткан шәкертләренең язмышы белән даими кызыксынып торган. Сафиулланың тәкъвалыгы, исламга нык бирелгәнлеге, белемгә омтылышы, тәртипле һәм итагатьле булуы Шиһабетдин хәзрәткә аеруча ошый. Ә 1884 елда ул укымышлы егетне үзенең кызына – икенче хатыны Бибинәгыймәдән туган Галиягә өйләндерә. Ш.Мәрҗани киявенә зур өметләр баглап, аны үзенең эшен дәвам итәчәк кеше итеп күргәндер. Әмма олыгаеп барган Мәрҗани шул заман традициясенә тугры калып, үзе урынына улын әзерли. 1889 елда Шиһабетдин хәзрәт вафат була. Мәрҗани мәчетендә беренче имам вазыйфасы һәм мәдрәсә белән идарә итү хокукы аның олы улы Борһанетдин хәзрәткә йөкләнә. Ш.Мәрҗани улы Борһанетдиннең зур эшләр башкарырга, мәдрәсәдәге алдынгы укыту тәҗрибәсен лаеклы дәвам итәргә сәләтсез икәнлеген аңлаган. Дини җәмәгатьчелек һәм мәхәллә әгъзалары да моны яхшы белгән. Шуңа да, Мәрҗани вафатыннан соң, Диния нәзарәте Сафиулла бине Габдулланы, Коръән һәм «Һәфтияк» басмаларын әзерләүдә Борһанетдин Мәрҗанигә ярдәмче итеп, Казанга күчерә. Бу хакта Шиһабетдин хәзрәт үзе исән вакытта Нәзарәткә әйтеп калдырган булырга мөмкин. Шулай итеп, Сафиулла хәзрәт бер үк вакытта «Мәрҗани» мәдрәсәсендә дә укыта башлый.

Аңа бу чорда хатыны Галия күп ярдәм күрсәткән. 1853 елның 23 октябрендә туган Галия әтисеннән төпле белем алган. Шиһабетдин Мәрҗани балалары арасыннан иң укымышлысы булган ул: Коръәнне яттан белгән, дөньяви фәннәрне дә камил үзләштергән, гарәп һәм фарсы телләрен, морфология, синтаксисны тирәнтен өйрәнгән. Ул Коръән басмаларын әзерләгәндә ире Сафиуллага, корректор буларак, зур булышлык күрсәткән.

«Кыргызның иң бөек хыялы – руслашу түгел, татарлашу»

1890 елда Сафиулла бине Габдулла, мәхәлләнең кайбер әгъзалары һәм Борһанетдин хәзрәт белән каршылыгы сәбәпле, Казаннан чыгып китә һәм Эчке Кыргыз Урдасындагы Нарын комлыкларында урнашкан Хан Урдасы дигән авылда имам һәм мәдрәсә җитәкчесе булып эшли башлый. Бу торак пункт хәзергәчә сакланган. Ул хәзер Казакъстан Республикасының Көнбатыш Казакъстан өлкәсе Бүкәй Урдасы районына карый. 1876 елдан бу җирләр Әстерхан губернасына кергән һәм анда казакълар, руслар белән бергә, татарлар да күпләп яшәгән. Рус этнографы А.Н.Харузинның (1864-1932) 1888 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Степные очерки (Киргизская Букеевская орда). Странички из записной книги» исемле китабында Сафиулла бине Габдулла барып чыккан җирләр яшәү өчен шактый авыр урыннар итеп тасвирлана. Алексей Харузин сүзләренчә, кипкән тоз күлләре һәм ком барханнары арасында урнашкан ике урамлы бер торак пункт булган ул чакта Хан Урдасы. Аны күчмәлектән акрынлап кына утрак тормышка күчә башлаган казакъ ханы Җиһангир төзеткән. Бу җирләрдә көйдергеч эсселек, ком бураннары, тузан өермәләре белән очраша галим А.Харузин. Урамдагы тирән комны ерып, сәләмә киемле төрле милләт балалары – казакъ, татар, рус, калмык һәм украиннар чабыша. Олылар көндез күренми диярлек – үз эшләре белән мәшгуль. Татарлар сәүдә эшләре, казакълар көнкүреш хезмәте күрсәтү белән шөгыльләнә, кайберләре исә Баскынчактагы тоз җитештерү предприятиеләренә барып эшләп йөри. Су җитмәү сәбәпле,



Сафиулла бине Габдулла турындагы тәүге мәгълүмат. 16 июль, 1850 ел.
Ульяновск өлкәсенең дәүләт архивы, 156 нчы ф онд, 2 нче тасвирлама, 367 нче эш.

игенчелек һәм терлекчелек юк дәрәҗәсендә. Халыкның ярлылыгы ярылып ята. Өйләрнең бик азы гына вак-төяк агачтан җиткерелгән, ә калганнары – балчык алачык яки киез тирмәләр. Мондыйларның күбесендә казакълар яши. Бер якта манарасыз мәчет күренеп тора. Христиан динендәгеләр дә үзләренә чиркәү әмәлләштереп куйган.

Кыргызларның (казакъларны руслар элек шулай атаганнар) татарларга карата ихтирамына аерым игътибар иткән А.Харузин. Казакълар татарларга мәгърифәт, цивилизация иңдерүчеләр итеп караган. Бераз хәллерәк тормышлылар, өсләрендәге «бохара халатлары»н салып, татарлар кебек европачарак киемнәр кияргә дә тырышканнар хәтта. «Кыргызның иң бөек хыялы – руслашу түгел, татарлашу», – дип язып калдырган рус этнографы. Ә нигә соң әле ул руслашу турында телгә алган?

Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән ханлыкларның берсе – Үзбәк ханлыгы биләмәсендә XV гасырның икенче яртысында Казакъ ханлыгы оеша. Күп тә үтми, анысы да этник һәм территориаль яктан өч берләшмәгә – Җүзләргә (Йөзләргә) бүленә. XVIII гасырның 30-40 нчы елларында патша хөкүмәте Олы, Урта һәм Кече Йөзләрне Россиягә кушу процессын башлап җибәрә. Әби патша Екатерина II казакъларны тыныч юл белән, үзенең хәйләкәрлеге ярдәмендә буйсындырырга ниятли. Башта ул бу эштә ислам диненә таянырга була. Казакъ элитасын, соңрак бар халыкны да үзенә җәлеп итәр өчен ул, беренче чиратта, татар муллаларына игътибарны арттыра. Казан якларыннан казакъ далалары-

на дин әһелләренең күпләп килүе шул чорда башлана да инде. Казакъ язучысы һәм галиме Чокан Вәлиханов язып калдырганча, һәрбер казакъ авылында бер татар мулласы һәм аның берничә шәкерте эшләгән. Муллалар рус дәүләте вәкилләре саналган, алар яхшы хезмәт хакы алган, гаскәри хезмәттән һәм салымнардан азат ителгән.

Кече Йөз әстерхан татарлары белән чиктәш тә булган. Аның ханы Нуралиның Бүкәй исемле улы 1801 елда, Россия патшасы Павел Iдән рөхсәт алып, үзенә буйсынган 23 меңгә якын кеше белән Идел һәм Җаек арасындагы калмыклардан бушап калган җирләргә күченә. Бүкәй үзен хан итеп игълан итә һәм бу җирләр Бүкәй ханлыгы (Бүкәй Урдасы) исемен ала. Бүкәй ханнан соң, 1815-1845 нче елларда ханлык белән аның улы Җиһангир идарә итә. Утрак тормышлы татарларга якынайгач, казакълар да, алардан күреп, бистәләр һәм авыллар төзи башлыйлар. Руслар Ханская Ставка дип атаган авылны Җиһангир үзенә яшәү урыны буларак төзетә. 1876 елда Бүкәй Урдасы җирләре Әстерхан губернасы составына кертелә. Шуннан соң да шактый вакыт бу биләмә Бүкәй Урдасы, Эчке Кыргыз Урдасы дип атап йөртелә.

Менә шушы җиргә килеп урнаша Сафиулла бине Габдулла. Ул үзенең миссиясенә кардәш халыкларга мәгърифәт нурын иңдерү дип карый һәм җиң сызганып эшкә керешә. Шигебез юк, алдынгы карашлы, прогрессив шәхес буларак, Сафиулла хәзрәт Эчке Урда мәктәп-мәдрәсәләрендә укыту процессына күп яңалыклар керткәндер, мәхәлләләрдәге дини тормышны югары дәрәҗәгә күтәрүгә ирешкәндер. Болай уйларга нигез дә бар: берничә ел эшләгәч, аңа «ахун» дәрәҗәсе бирелә. Сафиулла хәзрәт Хан Ставкасындагы ике сыйныфлы дәүләт училищесында да укыткан булырга тиеш. «К 1892 г. почти все учителя во Внутренней Орде были татарскими муллами. Эти муллы так доминировали в учебных заведениях Внутренней Орды, что даже преподавали в правительственных русско-казакъских школах. К тому же всё обучение в школах велось не на русском или казакъском, а на татарском языке» (Интернет-ресурс: *https://cyberpedia.su*).

Әмма Эчке Урдада Сафиулла хәзрәт эшләгән чорда Екатерина заманындагы вазгыять тамырдан үзгәргән була. Бу вакытка Урта Азия руслар тарафыннан тәмам буйсындырыла. Патша Россиясенең ахыргы максаты булып әлеге җирләрне ныклап үзләштерү, ә халкын христианлаштыру тора инде. Татар муллаларының кирәкләре калмый. Киресенчә, элек күпләп килеп урнашкан татар сәүдәгәрләре Россия хөкүмәте өчен куркыныч тудыручы көч дип санала башлый. Бер-бер артлы аларны кысуга, бөлдерүгә юнәлтелгән закон-указлар чыга, исламга каршы ачыктан-ачык көрәш башлана. Төркестан генерал-губернаторының 1898 елның 8 августында чыгарылган Циркулярында: «Духовными лицами не могут быть не принадлежащие к русскому подданству, а так же татары», – дигән күрсәтмә язылa. Шулай итеп, татарларга имам булу тыела. 1899 елда Сафиулла Абдуллин да Казанга әйләнеп кайта.

Мәрҗани традицияләрен дәвам итеп...

«Мәрҗани» мәдрәсәсендә хәлләрнең катлаулы чагы була бу. Мәчет имамы һәм мәдрәсә җитәкчесе Борһанетдин Мәрҗанинең сәламәтлеге тагын да начарлана. Ул мәхәллә эшләрен тиешле дәрәҗәдә алып бара алмый, дәресләр дә укытмый башлый. Нәтиҗәдә, мәчет һәм мәдрәсәнең эшчәнлеге бик сүлпәнәя,

җәмәгатьчелектә ризасызлык арта. Борһанетдиннең авыруыннан файдаланып, барлык җитәкчелекне үз кулына алган мәзин Хәйретдин Сабитов мәхәллә кешеләре белән дә, иганәче татар байлары белән дә уртак тел таба алмый, мәдрәсәдәге уку процессы таркалу дәрәҗәсенә җитә. Мондый шартларда мәчет һәм мәдрәсә эшчәнлеген матди яктан тәэмин итеп торучы Казан байлары хәлиткеч чаралар күрергә мәҗбүр була. Алар мәчеткә яңадан Сафиулла бине Габдулланы чакыралар. Тугыз ел читтә йөргән Сафиулла хәзрәт бу тәкъдимгә каршы килми. Әлеге хәлне бик үк өнәп бетермәсә дә, Борһанетдин Мәрҗани Сафиулланы үзенең ярдәмчесе һәм икенче имам итеп билгеләргә мәҗбүр була. 1899 елның 23 июлендә мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов тиешле указга кул куя. Сафиулла хәзрәткә бераздан мәдрәсәнең төп мөдәррисе вазыйфалары йөкләнә.

«Сафиулла бине Габдулланың татар мәгърифәтенә керткән иң зур өлеше – әлбәттә, «Мәрҗани» мәдрәсәсендә элекке традицияләрне яңартып, аны Идел буе мөселманнары мәгарифенең иң алдынгы үзәге итү.

Сафиулла хәзрәтнең тырышлыгы белән берничә ел эчендә мәчеттә дә, мәдрәсәдә дә хәлләр яхшыра, мәхәллә эше дә җайга салына. Ихлас рәвештә яңалыкка, үзгәртеп коруларга омтылучы кеше булса да, Сафиулла бине Габдулла мәхәллә әһелләре белән кискен каршылыкка керүне кирәк санамый. Ул тәртипне акрынлап, җайлап кына урнаштыра. Сафиулла хәзрәт иң әһәмиятле нәрсә итеп мәхәллә кешеләре арасындагы үзара җылы мөнәсәбәтне күрә. Шулай итеп, ул үзенең эшчәнлеге белән иске традицияләр яклыларны да, җәдитчеләрне дә канәгатьләндерә башлый, Борһанетдин Мәрҗани белән дә уртак тел таба. Алар арасында, берберенә каршылык урынына, эшлекле мөнәсәбәт урнаша. Бер үк вакытта яңа башланып киткән милли күтәрелеш агымына да кушыла Сафиулла хәзрәт. Ул татар буржуазиясенең алдынгы карашлы вәкилләре белән аралаша, Әхмәтҗан Сәйдәшев чыгарган «Бәян әл-хак» гәҗитенә күп яза, мөселман корылтайларын әзерләүдә актив катнаша.

Сафиулла хәзрәт 1904 елда Казан сәүдәгәре Габделвәли Чукин мәдрәсәгә васыять итеп калдырган, әмма янгында нык зарар күргән биналарны төзекләндерү эшенә алына. Моның өчен ул Казан байлары һәм мәхәлләнең хәлле тормышлы әһелләре белән тыгыз элемтә булдыра. Иганәчеләрдән җыелган мал янган биналарны торгызырга да, мәдрәсәне киңәйтү өчен ике катлы таш бина сатып алырга да җитә. «Мәрҗани» мәдрәсәсе каршындагы ятимнәр мәктәбе яңадан ачыла һәм уңышлы гына эшләп китә. Сафиулла хәзрәт 1907 елда Дилия Нәзарәте тарафыннан Түбән Новгородтагы «Ярминкә мәчете»нә вакытлыча эшкә җибәрелә. Ә инде 1908 елда аңа «Мәрҗани» мәчетенең өлкән мулласы вазыйфасы йөкләнә.

Тарихтан бер документ: Романовлар рухына дога

Сафиулла бине Габдулланың татар мәгърифәтенә керткән иң зур өлеше – әлбәттә, «Мәрҗани» мәдрәсәсендә элекке традицияләрне яңартып, аны Идел

буе мөселманнары мәгарифенең иң алдынгы үзәге итү. Мәдрәсә шәкертләренә, дин дәресләреннән тыш, география, тарих, татар һәм гарәп телләре, геометрия, педагогика, медицина нигезләре дә укытылган.

Сафиулла хәзрәтнең тормыш мәсьәләләренә реаль караштa торуына, җәмгыятьтәге урыны тотрыклы булуына, урынлы фикер йөртә белүенә мисал буларак, тарихта бер документ сакланган. Галимҗан Баруди, Газиз Гобәйдуллин, Сәетгәрәй Алкин һәм башка зур шәхесләр кебек, ул да Романовлар династиясенең 300 еллыгына багышланган тантаналарда актив катнашуны, шушы уңайдан халык алдында патриотик рухта чыгышлар ясауны кирәк санаган. Югарыда әйтелгән документ – 1913 елның 22 февралендә Казанның беренче мәчетендә үткән бәйрәм намазы һәм Сафиулла хәзрәтнең шушы уңайдан мәхәллә әһелләре каршында сөйләгән вәгазе хакында Казан губернаторы М.В.Стрижевскийга җибәрелгән мәгълүмат*. Мулла үз вәгазендә династиянең кайбер вәкилләренең, аерым алганда, «Әби патша»ның, Николай IIнең мөселманнарга карата хәерхаһлы хезмәтләре хакында телгә ала, Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең хәдисләрендә дәүләт башлыкларына буйсыну кирәклеге турында әйтелгән булуны искә төшерә. Ул император Николай Александровичның 1905 ел реформалары мөселман халыкларына милли үсеш өчен мөмкинлекләр ачуын, аларның гади халыкның тормыш дәрәҗәсен арттыруга юнәлтелгән булуын ассызыклый. Сафиулла хәзрәт сүзен Романовлар рухына дога белән тәмамлый. Патшаларга мәдхия белән сугарылган булса да, бу чыгышта милләткә каршы да, дингә каршы да бернинди сүз булмаган, әлбәттә. Бүгенге күзлектән карап, мондый чыгышлар өчен әлеге чор муллаларын гаепләү зур хата булыр иде. Чөнки ул чакларда бу патриотик хисләрне белдерүнең, хакимияткә ярашуның, шуның белән сәяси элитада мәхәлләгә, мөселманнарга карата уңай мөнәсәбәт тудыруның үзенә күрә бер тактик алымы булып саналган. Ул – Сафиулла мулланың агымдагы хәлләргә тиешле бәя бирә белгәнлеген, тормыш чынбарлыгын аңлап эш иткәнлеген раслаучы бер факт.

Сафиуллла бине Габдулла 1917 елда «Мәрҗани» мәчетендә имамлык вазыйфасын остазы Шиһабетдин Мәрҗанинең оныгы – Борһанетдин улы Габделхәмидкә тапшырып, үзе Казанның икенче мәчетенә имам булып күчә.

Күренекле дин эшлеклесе Сафиулла хәзрәт 1926 елның 19 гыйнварында Казан шәһәрендә вафат була һәм Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнә.

Зыялылык дәвам итә

Чүпрәле төбәгенең Сафиулла хәзрәт аша мәшһүр татар язучысы Әмирхан Еники белән дә бәйләнеше бар бит әле! Сафиулла бине Габдулла һәм аның хатыны Галия бинте Шиһабетдин (1924 елда вафат) Нәгыймә исемле кыз үстерәләр. Нәгыймәнең тормыш иптәше Таһир Әхмәтҗан улы Ильяси (1881-1933) – татарның зыялы шәхесе, галим-мәгърифәтче. Аларның Рәшит һәм Әмин исемле уллары, Наҗия исемле кызлары туа. Рәшит Ильясов белән Әмирхан Еники фронтташ дуслар булалар. Язучы гомеренең соңгы елларын аның сеңлесе Наҗия белән яшәп үткәрә.

Наҗия Ильясова Казан университетын тәмамлый, математика һәм астрономия фәннәре белгече була. Наҗия апаны белгән кешеләр аны якты күңелле, ачык йөзле, зыялы шәхес буларак искә ала. Шиһабетдин Мәрҗанинең оныкчыгына – Сафиулла Абдуллинның оныгына, күрәсең, бабаларының иң матур сыйфатлары күчкән булгандыр. ■

* Алексеев И.Е. Празднование татарами («мусульманами») Казани и Казанской губернии 300-летия царствования Дома Романовых. Интернет-ресурс: *https://ruskline.ru/analitika*

«Безнең дәвернең кыяфәте»

(Бакый Урманче көндәлекләреннән)

1967 ел

9 февраль.

Баязид Борнаев вафат. Безнең «Мөхәммәдия» шәрикләребездән иң сәләтле, иң тырыш иптәшебез иде. Беренче дөнья сугышы, әсирлек, революция, яңадан уку, партиягә кереп хезмәт итү, Сталин каһәренә дучар булып күп еллар концлагерь, озак авыру – безнең дәвернең кыяфәте!

Тупрагың җиңел булсын, кордашыбыз!

23 февраль.

Менә җитмеш яшь тә тулды.

Гомер савыты тулып, мөлдерәү дәрәҗәсенә җитеп килә.

Котлаулар күп.

Бүген кичкырын Мәскәүдән килгән уймачы Антропов Анатолий Петрович[1] белән утырдык. Гәптәш. Белемле кеше.

24 февраль.

СХда[2] минем юбилей кичәсе.

Бакый Урманче үзенең остаханәсендә. 1970 нче еллар. *Ф.Гобәев фотосы*

Шулай итеп кичәне үткәрдек. СХдан башка катнашкан группалар үзләрен бик яхшы яктан күрсәтеп, мәҗлесне рухландырдылар. Нәҗиб Җиһанов, Нәкый Исәнбәт[3], язучылар вәкилләренең чыгышлары гүзәл эчтәлекле булды. Дустлар, бигрәк тә мусыйк әһелләре бик күтәрделәр. Гани Сафиуллин, Яхин, Хәбибуллин, Булатова[4], Фатих Булатов һ.б.

---

[1] *Антропов Анатолий Петрович* – скульптор-монументчы А.П.Антропов (1906-?).

[2] *СХ* – «Союз художников» (Рәссамнар берлеге) атамасының кыскартылмасы.

[3] *Нәҗиб Җиһанов* – композитор, педагог, җәмәгать эшлеклесе, 1945-1988 нче елларда Казан консерваториясе ректоры Нәҗип Гаяз улы Җиһанов (1911-1988). Н.Җиһанов вафат булганнан соң Б.Урманче язган «Ярты гасырлык иҗади хезмәт» исемле мәкалә 2005 елгы җыентыкта басылган (457-461 нче битләр). Исеме көндәлек язмаларында еш кына Нәҗиб рәвешендә теркәлгән. *Нәкый* – язучы, галим, татар фольклоры, теле һәм әдәбияты белгече, тәрҗемәче Нәкый Сираҗетдин улы Исәнбәт (1899-1992). Көндәлек текстында алга таба «Нәкый» дип кенә язылганда Н.Исәнбәт күздә тотылган.

[4] *Яхин* – композитор, пианист Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы Яхин (1921-1993). *Хәбибуллин* – композитор, скрипкачы Заһид Вәли (Вәлиулла) улы Хәбибуллин (1910-1983). *Булатова* – җырчы, педагог Мөнирә Закир кызы Булатова (1914-2011), 1939-1978 нче елларда Татар опера һәм балет театры солисткасы.

Февральнең икенче яртысы һәм мартның беренче ярымында Галимҗан Ибраһимның кечкенә рельеф медальоны вә кечкенә бюсты белән шөгыльләндем. Керамика, кайтарма ут белән металлап ясарга теләгән медальоннар кайтару бирмәде, гади глазурь булып калды.

14 апрель, җомга.

Язарлар җәмгыяте Тукай атаулы клубта минем белән очрашу кичәсен уздырды. Кичәдә кереш сүзне Нәкый әйтергә тиешле иде. Бу, олуг бәхетсезлек, кайгы көнендә ул килә алмады[5]. Әмирхан Еники яхшы кереш ясады. Аннан соң төзүче Рәшид Мортазин[6] һәм профессор Хатыйп Госманов сөйләде. Болардан соң мин сүз алдым. Минем сүздән соң кечкенә генә концерт булып, Мөнирә Булат, Рөстәм Яхъя, Госман Әлми, Исмәгыйль Һилал, Наҗия Теркулова[7].

Үзенең җыелышта әйткән сүзе җае белән Хатыйп, Дәрдемәнднең безнең әдәбиятыбыздагы кыйммәтен тәкъдир итеп: «Дәрдемәндне миллионер диеп әйтәләр. Ләкин аның иҗади байлыгы, кыйммәте белән аның миллионер булуын чагыштырсак, ул миллионерлык хәерчелек булып кала...» – диде. Гаҗәп дөрест, тирән мәгънәле, олуг хикмәтле сүз!

Равил Гыйлаҗ килде. Эшләре белән. Гаҗәп кеше. Сафкүңел. Сәнгатьче.

2 май.

Өйдә ятам. *Soulage*[8] хакында укыйм. Бер җиргә барасы килми. Бары Идел буена барып кына ятар идем. Ятып укып кәефләнәм.

4 май, кече атна.

Көтмәстән, ике өлкән яшьле кеше килеп чыкты. Берсе минем белән 1918 елны Мәскәүгә барган Хәлил Гарифуллинның энесе Фәтхи Гарифуллин икән, хәзер Буада тора. Хәлил Ош шәһәрендә вафат икән.

Икенчесе минем белән Тәтештә очрашкан (ихтимал, миннән укыгандыр да) Ногманов булып чыкты. Озын буйлы ябык егет иде, әле дә шулай.

24 май, чәршәмбе.

Бүген Алман Демократик Республикасыннан килгән «Wochenpost» гәзитәсенең редакторларыннан Гюнтер Линдс белән Gerhard Desombre килеп, эшләрне карап китделәр.

25 май.

Әбелмәхҗән абый шылтыратты. Аның «Габделбакый» дип тутырып әйтүе әнкәйне, әткәйне, әбиемне һәм башка якын туганнарымны искә төшереп, күңелне йомшарта.

Шәйхе Сәгъдинең касыйдәләре бар, ди.

---

[5] Н.Исәнбәтнең хатыны Гөлсем Исәнбәт 1967 елның 12 апрелендә вафат була.
[6] *Рәшид Мортазин* – архитектор Рәшит Муса улы Мортазин (1911-1987). 1963-1967 нче елларда «Союзпромпроект» институтының Казан филиалында баш архитектор. Исеме Б.Урманченың көндәлек язмаларында еш кына Ришад рәвешендә теркәлгән.
[7] *Госман Әлми* – җырчы Усман Гафият улы Әлмиев (1915-2011). *Исмәгыйль Һилал* – мандолиначы, музыкант Исмәгыйль Гобәйдулла улы Һилалов (1898-1992). *Наҗия Теркулова* – җырчы, 1966-1991 елларда Татар дәүләт филармониясе солисткасы Наҗия Абдрахман кызы Теркулова (1929-2016).
[8] *Soulage* – француз рәссам-абстракционисты Пьер Сулаж (1919).

19 июнь.

Бүген киностудиядән иртән сәгать 6.30да кайттым. Кичә 23тә алып киткәннәр иде. Төн йокламадык.

29 июнь.

«Алатау итәгендә» атаулы картинны дәвам иттерәм. Ниндидер яңалык килеп чыгарга тиеш иде. Стиль эзләү, теләгән рәвешләрне табу кыен.

«Мәрҗани» гипска күчерелде.

«Дәрдемәнд» мәрмәргә күчеп бетә инде. Соңгы этап башланды.

Галим, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани. Гипс. 1968 ел

17 июль.

Фәйзи Гаскәревнең[9] репетициясендә булдым. 16сында ул һәм Ключарев[10] килгәннәр иде.

20 июль.

Иртүк Хафизның[11] бер газәлен тәрҗемә иттем, уңышлы кебек.

3 август, кече атна.

Остаханәдә яшьләр әңгәмә сурәтен төшереп һәм язып алдылар. Кояшлы көн иде. Уңышлы булды кебек.

10 август.

Розалина[12] килеп китте. Портрет өчен бик һәйбәт. Җитез кыз. Сәнгатьне төшенә, шигырь яза.

12 август, шимбә.

Черкенгә киттем, кино әһеле белән.

Черкен. Зөя күпере, кер юа торган басмасы шунда ук. Бала вакытта мөкаддәс гыйбадәтханә булган мәчет эчендә аракылап мәҗлес ясадылар. Әстәгъфирулла!

3 сентябрь.

«Ял көн иртәсе» алга бара кебек. Тизрәк язып бетерергә кирәк. Язу тарзы табылды, шулай аббарыйрга.

---

[9] *Фәйзи Гаскәрев* – балет артисты, балетмейстер, либреттолар авторы Фәйзи Әдһәм улы Гаскәрев (1912-1984).

[10] *Ключарев* – композитор, дирижёр һәм пианист Александр Сергеевич Ключарев (1906-1972).

[11] *Хафиз* – фарсы шагыйре һәм суфый шәех Шәмседдин Мөхәммәд Хафиз Ширази (1325-1390).

[12] *Розалина* – сәнгать белгече, шагыйрә, тәрҗемәче, рәссам Розалина Гомәр кызы Шаһиева (1945).

Дәрдемәнд. Мәрмәр. 1968 ел

4 сентябрь.

Rosaline[13] килде. Рәсемен башладым. Буяу белән язарга да кирәк.

18 сентябрь.

Кино эшләре. Кич белән сүзләр яздык.

***

Ходага тәвәккәл илән, Мәрҗани хәзрәтләренең сурәтенә керештем.

29 сентябрь.

Бүген, ахирел-әмер, фильмны[14] карап үткәрдек. Яхшы гына җирләре булса да, күп кыскартылган-кыркылган, кайбер кирәкле детальләре юк, кирәксезләре озынрак.

30 сентябрь.

Фильмны карадык. Кызык. Мавыгып карала, һәрхәлдә, күрсәтерлек. Кичен күргәзделәр. Халык яраткан кебек. Күп танышлар шалтыратып шатлык изһар иттеләр.

6 октябрь.

Яман сигналлар, уң кул бик каты сызлады. 3-4 көн инде эшли алганым юк. Бүген бераз җиңгелрәк. «Мәрҗани» монографиясен[15] укыйм.

7 октябрь.

Эшли алмыйм. Уң кул хәвефләндерә. Сызлавы бетми әле. Ләкин Шәйхе Сәгъдинең «Гөлстан»ын, «Мәрҗани»не уку күңелгә рәхәт бирә, вакыт әрәм китми.

[13] *Rosaline* – Розалина Шаһиева.
[14] Кинорежиссер һәм сценарист Владимир Вячеславович Стрелков (1938) төшергән, Бакый Урманчега багышланган «Сагыш» документаль фильмы. Бу фильм зур уңыш казана.
[15] *«Мәрҗани» монографиясе* – тарихчы һәм дин галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына һиҗри ел исәбе белән 100 ел тулу уңаеннан Салих Гобәйдуллин тарафыннан нәшер ителгән китап күздә тотылган (Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең виладәтенә йөз ел тулу (1233-1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матбагасы, 1915. – 639 б.).

30 ноябрь.

«Казан утлары» редакциясендә Габдулла Шамуковның Сөембикә манарасы хакындагы мәкаләсе[16] хакында киңәш булып үтте.

Катнаштылар: редактор Рафаэль Мостафин; Фуад Вәли – тарихчы, сәнгать белгече; Ибраһим Гази; Рәшид Мортазин – төзүче; Габдулла Шамук – уенчы; Нәкый Исәнбәт; Альфред Халиков – археолог; Фәхретдинев – археолог; Урманче; Фәрваз Миңнуллин; Ихсанова.

Һәрберсе әлеге мәкаләнең урынлы, вакытлы һәм журналда басылырга тиеш икәнен әйттеләр. Шуннан соң Рафаэль Мостафин: «Бу киңәш нәтиҗәсендә без Сөембикә манарасында урнаштырылган тактаны хәзергә алып торуларын сорап хат язабыз», – диде.

Ул тактада Сөембикә манарасының XVIII гасырда ясалып, рус сәнгате әсәре булуы хакында язылган.

Киңәш-фикер алышу бик җитди һәм ашкыр гыйльми рәвештә узды. Һәр өлкәдә гыйльми дәрәҗәсе югары булган галимнәр, осталарның барлыгы ачык булды. Шатланырлык.

3 декабрь.

Иҗади мөстәкыйльлек миңа хәзер генә ирешә. Ул матди мөстәкыйльлек белән чордаш-иптәш икән. Әгәр шул мөстәкыйльлек белән яшь дәрт, яшь көч тә булса иде. Дәрийгъ... Алары киткән-кичкән.

8 декабрь.

Ахирел-әмер, Нәҗиб концерт залы ачты. Шөкер, Казанда рәтле концерт бирерлек, уңайлы рәвештә музыка тыңларлык урын булды.

12 декабрь.

«Сагыш»ны янә бер мәртәбә Мәскәү күрсәткән. Фестивальгә үткәзгәннәр. Ләкин «цензура»быз Соловки[17] дигән җирен төшереп калдырырга боерган. Бу моменты аның иң кирәкле төше иде. Шулай итеп, аннан кыркып, моннан кыркып, әдәби әсәрләрнең, гомумән, сәнгать әсәрләренең дә кыйммәтен киметәләр.

18 декабрь, дүшәнбе.

Кич белән Шамуков кереп чыкды, Айдаровның[18] «Сөембикә» хакындагы мәкаләсен китергән. Шундый ук давыллы-шаукымлы җегет.

*Көндәлекләрне басмага **Раиф Мәрданов** әзерләде.* ■

[16] Г.Шамуковның Сөембикә манарасына багышланган мәкаләсе «Казан утлары» журналының 1968 елгы 9 нчы санында «Архитектура сәнгатебезнең бер истәлеге» исеме белән басылып чыккан (127-143 нче битләр).

[17] *Соловки* – Ак диңгездәге (Архангельск өлкәсендәге) алты зур һәм йөздән артык вак утраулардан гыйбарәт архипелаг. Шундагы әүвәлге Соловецк монастыренда 1920-1930 нчы елларда иң кырыс концлагерьларның берсе урнашкан була. Б.Урманче 5 елга хөкем ителеп, 1930-1933 нче елларда Соловкида булган һәм вакытыннан алда азат ителгән.

[18] Айдаров – архитектор-реставратор, архитектура теориясе һәм Татарстан архитектурасы тарихы буенча хезмәтләр авторы Сәйяр Ситдыйк улы Айдаров (1928-2014).

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

Сафиулла бине Габдулланың кабер ташы

Айдар Гайнетдинов

Сафиулла Габдулла улы Габдуллин 1849 елның 25 декабрендә хәзерге Чүпрәле районының Кече Чынлы саласында туган. Ул, Казанның «Мәрҗани» мәдрәсәсендә гыйлем алып, башта үз авылында мулла, аннан соң 1890 елдан Эчке Кыргыз Урдасындагы мәчетнең имамы һәм мөдәррисе, соңыннан 1899 елдан «Мәрҗани» мәчетендә имам һәм мөдәррис вазыйфаларын үтәгән. Сафиулла хәзрәт, җәдидчә төпле белем бирү оештырып, үзенең мәдрәсәсен хөр фикерлелек һәм иҗтиһад үзәгенә әверелдергән. Ул күренекле галим Мәрҗанинең кияве булган, ягъни Галия Шиһабетдин кызына өйләнгән. Сафиулла хәзрәт хатыны белән бергә Коръән басмасын төзәтү-дөресләү белән дә шөгыльләнгән.

Сафиулла бине Габдулла 1926 елның 18 гыйнварында бакыйлыкка күчкән һәм Казанның Яңа бистә зиратына җирләнгән. Аның кабер ташы хәзерге көнгә хәтле чагыштырмача яхшы сакланган. Текстының укылышы мондый:

Алгы ягы (уеп язылган):

- «Ли-лләәһил-фәәтихәһ
- Казан шәһәринең
- беренче мәсҗед җамигъ
- имамы Сафиулла
- бине Габдулла
- каблэз-зоһр дүшәнбә
- көн 4 нче рәҗәб
- 1344 сәнә һиҗриййә
- 78 йәшендә
- иртихаль итде
- рахимәһү-ллааһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Нәүвәра-ллааһү мәркадәһ».
Сул ягы (уеп язылган): «1926 сәнә румиййә гыйнвар 18ендә».

Алгы ягы:

- «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
- Казан шәһәренең
- беренче җамигъ мәчете
- имамы Сафиулла
- бине Габдулла
- төшкә кадәр дүшәмбе
- көн һиҗри 1344
- елның 4 рәҗәбендә
- 78 яшендә
- күчте.
- Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».
Сул ягы: «Милади 1926 елның 18 гыйнварында [вафат]».
Ташның үлчәмнәре: 103(134)х31х16.

«Татар энциклопедиясе»ндә Сафиулла хәзрәтнең 1927 елда үлүе һәм туган авылының Пильна булуы хакында язылган*, тик, күргәнебезчә, болар дөреслеккә туры килми. Бәлки, 78 яшендә вафат булганга күрә, үлеме 1927 елда дип уйлаганнардыр, тик элекке дин әһелләре үзләренең яшьләрен һәм гомерләрен һиҗри ел исәбе белән санаганнар. Димәк, милади ел исәбе белән Сафиулла бине Габдулла 76 яшьтә мәңгелек дөньяга күчкән булып чыга. ■

* Татарская энциклопедия: В 5 т. / Гл. ред. М.Х.Хасанов, отв. ред. Г.С.Сабирзянов. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002. – Т. 1: А-В. – С. 18.

Югалып табылган авыл

Вячеслав Данилов

Тарихи чыганакларга ышансаң, XV гасыр башыннан алып бүгенгә кадәр *Хуҗа Хәсән* исемен ике авыл йөрткән. Аларны Аксак Тимер явы вакытында Зур Чынлы һәм Зур Задур салаларыннан (хәзерге Чүпрәле районы) качып киткән крестьяннар нигезләгән. Исеме, имеш, Болгар һәм Алтын Урда морзасы Хәсәннән алынган. Качакларның бер өлеше, күрәсең, Гөбенә елгасына кушылган инеш буендагы гүзәл табигатькә, Урал тавына (ике кыйтганы аерып торган мәгълүм сырт белән бутамагыз) гашыйк булган һәм тормышын шунда гына корып калган. Авылга *Урал Хуҗа Хәсәне* дип атама биргәннәр. Урыс язмаларында аның исеме *Хозесаново при реки Кубня* дип йөртелгән. Качакларның Хәсән җитәкләгән төп өлеше ары киткән, инеш буйлап якынча ике чакрым өскә күтәрелеп, төп *Хуҗа Хәсән* авылын оештырган. Ул 100 елга якын Зөя өзәнә, ә 1750 елдан соң Чуел өязенә кергән Хуҗа Хәсән волостеның (хәзерге Кайбыч районы) үзәге булып торган. Ни кызганыч, ары таба галимнәр ялгыш җибәргән һәм *Гөбенә буендагы Хуҗа Хәсән* авылы (монда нибары 37 ир-ат яшәгән) китапларга, энциклопедияләргә волость үзәге буларак кертелеп, 250 кешелек Хуҗа Хәсән авылы (чын үзәк) игътибардан читтә калган. Бу хата бик күп җыентыкларда, басмаларда һаман күзгә төртелеп тора әле.

Татарстанның Тау ягын өйрәнүгә багышланган байтак китаплар күрше авылларның да (Мәлки, Корбаш һ.б.) XIV-XV гасырлар чигендә Зур Чынлы, Зур Задур качаклары тарафыннан нигезләнүен раслый. Мәскәү генеология лабораториясе 2018 елда уздырган тикшеренү эшләре дә бу фаразга каршы килми. Шунысын да искәртергә кирәк: өстә телгә алынган авылларның һәрберсендә иске мөселман зиратлары бар.

Инде Гөбенә буендагы югалган Хуҗа Хәсән авылына күчик.

Җирле халык әлеге торак пунктны төрлечә атаган: *Инеш Күпере* дә, *Урал* да, *Кыр Кизләве* дә, *Кечкенә Хуҗа Хәсән* дә. Урыс чыганакларында да атама төрле вариантларда бирелгән: *Малая Колясаново, Хутор Хозесановой, Починок Хозесановой,* яисә, әйтелгәнчә, *Хозесаново при реки Кубня.*

Укучыларга шул хакта искәртеп узасы килә: инешнең аръягында, Алмалык һәм Чуаш Чүтие авыллары арасындагы тау сыртында, куаклык баскан берничә аерым җир кишәрлеге бар. Чукындыру сәясәте безнең якларга килеп җиткәч, чукындырган татарларны шунда җирләргә мәҗбүр иткәннәр. Бу хәлләр 1910 елга кадәр барган. Шуннан алып һәр авылның үз зираты барлыкка килгән. Бүген әлеге кишәрлекләрне тәртипкә китереп, ата-бабаларыбызның каберлекләрен барларга, чистартырга иде.

Мин сабый чакта картлар: *«Бу авыл тирәсендә Емельян Пугачев чирүенең ыстаны торган, монда ядрә, хәтта туп калдыклары табылган»,* – дип сөйлиләр иде. Алар бәян иткән төрле хәлләр, вакыйгалар миңа бик ошый, әти-әниләр еш кына Инеш Күпере авылын да искә төшерәләр иде. Әйтик, әтием Влас Васильевич еш кына анда Кузьма Николаевич Мокрецов һәм Герасим Данилов янына кунакка йөргән. Алар безгә туган-тумача да туры килгән әле. Сугышка кадәр, хәтта сугыштан соң да, 1950 нче елларгача, бире дә Мокрецовлар, Варламовлар, Ильиннар, Семеновлар һ.б. – җәмгысе 39 кеше яшәгән.

Бу хәлләр мине бик нык кызыксындырды, өйрәнә торгач, турыдан-туры әби-бабаларымның да 1720 елга кадәр шушы авылда гомер иткәнен белдем. Болар арасында: Алиш һәм аның хатыны Дускай, балалары Тутай һәм Әсән Алишкиннар, ары таба – Әсәннең балалары Сәет, Муса. Даниловларның (ягъни безнең), Алексеевларның, Сергеевларның, Иллариевларның, Афанасьевларның, Андреевларның (Чөгендер Семен), Арбузовларның һәм башка нәселләрнең очы шушы Муса бабайга барып тоташа.

Алар, мәҗбүри чукындырудан качып, 1720 елда Хуҗа Хәсән авылына килеп төпләнә, күрәсең. Ул чакта миссионерлар *Инеш Күперенә (Гөбенә буендагы Хуҗа Хәсәнгә)* еш килеп-чыгып йөри, нәтиҗәдә, авылда беренче урыс фамилияле кешеләр барлыкка килә. Әлеге вакыйгаларның чын булуын раслаган документларны мин, эзләнә торгач, Россия дәүләт борынгы актлар архивында (РГАДА) таба алдым (анда төрле елларга караган җанисәп материаллары саклана).

Россиядә 1710 елда, Петр патша заманында уздырылган җанисәп кенәгәләре *Ландрат язмалары (Ландратские записи)* дип атала. Аларда ир-атлар да, хатын-кызлар да, балалар да теркәлгән, өйләнүчеләр, буйдаклар, толлар һәм авыру-сырхаулар аерым күрсәтелгән. Бу материалларда авыл исеме *Хозесаново при реки Кубня* диелгән, 16 утарда 70ләп кеше яшәгәнлеге язылган. Соңрак үткәрелгән 1717 елгы җанисәп кәгазьләрендә мондый мәгълүмат бар[1]: *«А по нынешней переписи в той деревни жилых чюваских[2] дворов 22 с 28 жилыми домами»*. Димәк, 22 утарның алтысында икешәр йорт булган.

Ул чорларда ил буйлап бик күп юлбасарлар, караклар, ушкуйниклар йөргәнен искә төшерик. Алар еш кына халыкның тынычлыгын бозгалаган. Шуңа күрә, иминлек саклар өчен, торак пунктлар хәзерге сыман урамлап түгел, утарлап оешкан һәм үзенә күрә кечкенә кирмән-крепостьны хәтерләткән. Андый утарларда, гадәттә, туган-тумача, дус-иш бергә, әмма аерым-аерым йортларда торган.

Бая әйтелгән 22 утарда барлыгы 42 ир-ат яшәгән: 25е – өйләнгән, 1се – тол, 8е – буйдак, 8е – балигълыкка җитмәгән. Шунда ук 49 хатын-кыз гомер кичергән: аларның 25е – кияүдә, 9ы – тол, 4есе – җиткән кыз, 11е сабый яисә үсмер булган. Димәк, 1717 елда Инеш Күперендә 91 кеше көн иткән һәм ул заманына күрә уртача авыл саналган.

Бер үк вакытта төп Хуҗа Хәсәндә 124 ир-ат яшәгән. Хатын-кызлар санын да шул тирә дип алсаң, бу авылда җәмгысе 248-250 кеше торган дигән сүз. Волость үзәге өчен монысы да яхшы, уртача күрсәткеч.

Гөбенә буендагы Хуҗа Хәсән (Инеш Күпере) авылы 1710-1717 нче еллар аралыгында 6 утарга һәм 12 гаиләгә (йортка) арткан. Бер үк вакытта 3 гаилә (йорт) авылдан (ихтимал, чукындырудан куркып) качкан, аларны хәтта эзләүгә дә биргәннәр. Болар[3]: *«1. Двор Емелки Кулушева; 2. Двор Сурмекея Биметова; 3. Двор Кодрячки Толбаева»*. Бу чорга, ягъни 1717-1720 нче елларга бәйле документларда авыл халкының һәммәсе диярлек татар исем-фамилиясен йөртә, 7 гаиләгә карата гына шик-шөбһә бар[4]:

«Во дворе вдова Бимяковская – жена Байбахтина Нурсолтан Атерякова шитидесят. У него сноха – вдова Савделет Алина сорока – у нее сын Уразмет Алманаев

---

[1] Мәгълүмат чыганактагыча бирелә. – *Ред.*

[2] Бу урында хәзерге чуаш халкын түгел, ясак түли торган аерым сословиене күз уңында тотарга кирәктер. – *Ред.*

[3] Мәгълүмат чыганактагыча бирелә. – *Ред.*

[4] РГАДА, 350 нче фонд, 1 нче тасвирлама, 360 нчы эш, 60-64 нче битләр. Мәгълүмат чыганактагыча бирелә. – *Ред.*

пяти. У него же вдовы Нурсолтанки сын – Айбулат сорока. У него жена Савделет Айбатырева пятидесяти лет. На том же дворе другой его сын же ее Айтуган тритцети пяти. У него жена (язу танылмый[5]) лет Урметево тритцети. Сын Алкеш четырех, дочь девка Иштелей семнадцати лет. Платят пол ясака за пол батмана меду.

Во дворе вдова Урачкина – жена Ижбалтина Айбисса Чемеева штидесяти пяти. У нее сын Чинбулат Урмяков тритцети пяти. У него жена Зевнякай Камаева пятидесят. Гульзевер Мураева тритцети.

Дети Чурай пятнатцети, Ибрай дву лет. Платит пол ясака.

Во дворе Сюрмекей Салтыков тритцети пяти. У него жена Екулка Ирмякова дватцети пяти. Сын Алишка трех лет. Платят за умершего Темечки Уренеева по чети ясака.

Во дворе Сидер Алкеев штидесят две. У него сын Дюсей дватцети пяти. У него жена матрена Аникеева тритцети. Дочь Болтан четырех лет. Платит четь ясака да за батман меду.

Во дворе Козяк Мрясов сорока пяти. У него жена Кадяк Булакаева сорока. Сын Бикметь пятнатцати лет. Платит за брата своего калеки Бичурина по чети ясака.

Во дворе Ишаля Басарин пятидесят. У него жена Кузей Уразбахтина сорока. Сын Алей дватцети. У него сноха – вдова – Янай Тинбулатова сорока лет. Платит четь ясака.

Во дворе вдова Секенеш Семенова пятидесят. У нее сын Кадырка Байметов пятнатцети. Дочь Сабыра шеснатцети лет. Платит отцовскую – Томилки Тойбулатова пол чети ясака.

Во дворе Кангилда Давлетбахтин штидесять. У него жена. Яналейка Ирекеева пятидесят пяти. Сын Абдулка двадцети лет. Платит четь ясака да за пол батмана меду.

Во дворе Яжбахта Сурмяков штидесят. У него жена Майрящка Митрофанова тритцети. Сын Юнус пятнатцети. Дочь сорока дву лет. Платит Асанки Алишкина на пол чети ясака.

Во дворе Бикбулат Тинбулатов сорока пяти. У него жена Бикнекей Совмурзина сорока. Дочь Шарняза дву лет. На том же дворе в другой избе брат ево родной Бикбулат двадцети пяти. У него жена Татяна Тойтимерова тритцети. Дочь Татслуйка десяти лет. Платит пол ясака да за пол батмана меду.

Во дворе Тоскубай Тимофеев тритцети. У него жена Изилепкейка Собаткина сорока. Дочь Айсолтан пятнатцети. На том же дворе в другой избе брат ево родной Тохтар тритцети. Биктерь дватцати. У них же мать Сювар Авкаева пятидесяти лет. Платит отцовскую – Темячки Урекеева полторы чети ясака.

Во дворе вдова Дюскей Булаева семидесяти. У нее сын Асан Алишкин тритцети. У него жена Казей Сюрметьева двадцети пяти. Дети Сеид пяти. Мусаля дву лет. На том же дворе в другой избе брат ево родной Тутай Алишкин тритцети пяти. У него жена Шашкеней Юртукова пятидесят лет. Платит полторы чети ясака.

Во дворе Улей Томилов тритцети пяти. У него жена Тикейслука Тимекеева сорока. Дочь Айсолтан трех лет. Платит отцовскую – Томилки чет ясака.

Во дворе Алтунбай Актубаков пятидесят. У него жена Гуляк Молакова сорока. Дочь Нуркабея семи лет. Платит Темички Урекеева пол чети ясака.

[5] Монда һәм моннан ары документ эчендә – автор искәрмәләре. – *Ред.*

Во дворе Алкай Нуркеев тритцети пяти. У него жена Бинябейка Алмеева тритцети пяти. Сын Ильметь пятнатцети. Дочь Азнабейка дву лет. У него же племяник девка Тиляслука Алмекеева шеснатцети лет. Платит пол ясака.

Во дворе Мамеделя Алмеева сорока. У него жена Илзяк Айдарова тритцети. Сын (язу танылмый) дву лет. Платит за брата своего Темячин Уренеева пол чети ясака.

Во дворе Емелка Ишеев тритцати пяти. У него жена Налей Серметева дватцети. Дочь Гуляк дву лет. У него же брат родной Люка дватцети пяти. У него жена Нукамбея Тойтерякова дватцети лет. Платит полторы чети ясака.

Во дворе Нуркей Укин сорока. У него жена Улита Килякова сорока. Дочь Салиха трех лет. Платить за умершего Тосупки Чикбулатова пол чети ясака да за пол батмана меду.

Во дворе Васил Акмурзин сорока. У него жена Гульсолтан Декеева тритцети. Сын Сапар четырех. У него же сноха – вдова Гулчачак Алкина тритцети пяти. Дочь Чибер дву лет. Платит за брата своего Алки Тимякова четь ясака.

Во дворе Сашка Тометов дватцети. У него жена Девкечей Крымсараева дватцети пяти. Сын Синяла дву лет. Платит умершего дяди своего Юсупко Чинбулатова пол чети ясака да за пол батмана меду.

Во дворе вдова Зелебейка Тенибякова сорока. Сын Калей Байчюрин дватцети лет. Платит пол чети ясака.

Во дворе Феткин тритцети. У него жена Иркасылука Биметьева дватцети. Дочь Гулейка дву лет. Платит Томилки Толубаева пол чети ясака.

Деревни Карабаев Агидреевка тож. На Милетке Карабаеве сотоварыщи с пашни и сенных покосов оброку один рубль десять денег».

Тора-бара Хуҗа Хәсән авылының волость үзәге буларак әһәмияте арта: 1717 елгы җанисәптән соң Инеш Күпере халкының күбесе бирегә күченеп өлгерә, 1720-1722 нче елларга караган документларда исем-фамилияләр дә урыслаша төшә (искә төшерик: Петр патшаның көчләп чукындыру сәясәте нәкъ менә шушы чорда аерата котыра; максатына ирешәм, дип, дәүләт 1720 елның 1 сентябрендә, 1721 елның 21 августында, 1722 елның 17 июнендә тиешле указлар чыгара). Инеш Күпереннән волость үзәгенә күченгән кайбер гаиләләрне санап үтик[6]:

«1. Семья Сурмекея Салтыкова – 35 лет.
2. Семья Янбахты Сурмякова – 50 лет и
3. его сына Юнуса Янбахтина.
4. Семья Сидера Алкеева – 62 года.
5. Семья Кангилдея Давлетбахтина – 60 лет.
6. Семья Казяка Мрясова.
7. Семья Ишали Байсарина.
8. Семья вдовы Дуская Булаевой – 70 лет (жена Алиша) и их детей с женами:
9. семья Тутая Алишкина – 35 лет, жена Шашканей Юртукова – 50 лет.
10. Семья Асана Алишкина – 30 лет, жена Казей Сюрметева – 25 лет. И их сыновья Сеит – 5 лет, Мусаля – 2 года.
11. Семья вдовы Зелейбека Тенибяковой – 40 лет (жена Байчуры) и семья ее сына –
12. Калей Байчурина – 20 лет – предки Горшковых».

[6] Мәгълүмат чыганактагыча бирелә. – *Ред.*

Чукындыру эшен максатчан рәвештә алып бару өчен, 1731 елның 23 августында Зөядә «Керәшеннәр канцеляриясе» оештырыла, соңрак ул «Керәшеннәр конторасы» итеп үзгәртелә. Әлеге конторага чиксез вәкаләтләр бирелә. Патшабикә Анна Иоанновна 1740 елның 11 сентябрендә «Об отправлении архимандрита с некоторым числом священнослужителей в разные губернии для обучения новокрещеных христианскому закону и о преимуществах новообращенным дарованных» исемле указ имзалый. Шул көннән алып, аерата конторaны Аксак Каратун җитәкләгән чорда, Казан төбәгендә чукындыру эше коточкыч колач җәя.

Икенче ревизия, ягъни 1744 елгы халык санын алу татар халкының үз динен яклауда күрсәткән батырлыгына һәйкәл булырлык. Бу җанисәптә авыл исеме *«Хозесаново-Починок-Кукшум тоже татары»* дип язылган. Юкка чыккан Инеш Күпере авылы… хәзерге Апас районы җирендә Күкшем (Күкшәм) буларак барлыкка килә. Икенче ревизия шунда, яңа урында уздырыла. Чиркәү үзеннән качкан кешеләрне бик тиз таба, алар турында кирәкле мәгълүматны бик җиңел җыя. Аннары, билгеле, иң якын чиркәү приходына теркәп кую хәстәрен күрә.

Әлеге җанисәп беренчесеннән соң 27 ел узгач үткәрелә. Аның нәтиҗәләре шактый уйландыра. Беренчедән, «чювас» урынына бу кәгазьләрдә «тоже татары» дип язылган. Шул ук вакытта 26 татар ир-аты һәм 11 «чювас» күрсәтелә (барлыгы – 37 ир кеше). Авыл халкының саны да, утарларныкы да артмаган. Киресенчә, икесе дә кимегән генә. Җанисәп документларында бик күп гаилә башлыгының вафат булуы теркәлгән, 19 гаиләнең 8е – шундый. Югыйсә үзләре урта яшьләрдә генә әле. Бер балага – 1 яшь, ике балага 2 яшь булган, 3 яшьлекләре бөтенләй юк. «Чювас» дип язылганнарның барысы да татар исем-атын йөртә: әйтик, Федор Беметев[7] һәм Ситула Маметев. Бәлки, алар башта мөселманлыкта булып, аннары чукындырылганнардыр? Шуңа күрә фамилияләре татарча калгандыр? «Чювас»ларның балаларына татар исемнәрен кушуы да күңелгә корт кертә. Мәсәлән, Силюшка Мамбеев үзенең икенче улын Айдар дип атаган. Аңа 1 яшь. Бикеней Маметов беренче улына – Залак (13 яшь), икенчесенә Юсуп (Йосыф, 7 яшь) дип исем кушкан. Бу – урыслаштыру сәясәтенең иң зәһәр заманында бит! Мондый гамәл атаның үзенә генә түгел, баласына да куркыныч тудырган лабаса. «Гөбенә буендагы Хуҗа Хәсән авылыннан Хуҗа Хәсән-Күкшем (документларда: в деревне Хозесаново-Починок-Кукшум тоже татары») авылына күченгән качаклар турындагы ревизия мәгълүматларына күз салыйк[8]:

«Умершего написанного в прежней переписи Исхака Ишметева, рожденный после переписи сын – Муслюм 14 лет.

Умершего написанного в прежней переписи Исайки Ишметова, рожденные после переписи дети – Мурсалим 16 лет, Муртя 11 лет, Мурат 7 лет.

Умершего написанного в прежней переписи – Уразак Бикчюрина, рожденный после переписи – Курмала 10 лет.

Умершего написанного в прежней переписи Резяпа Кулметкина, рожденные после переписи дети – Анна 10 лет, Борис 5 лет.

Отданного в рекруты, написанного в прежней переписи Бикмула Бикмурзина рожденный после переписи сын – Исмаила – 2 года.

Написанного в прежней переписи Ибрашко Бигашкин – 42 года. У него сын после переписи рожденный – Исай 2 месяца.

[7] Исем-фамилияләр чыганактагыча бирелә. – *Ред.*

[8] РГАДА. 350 нче фонд, 1 нче тасвирлама, 360 нчы эш, 4057-4060 нчы битләр. Мәгълүмат чыганактагыча бирелә. – *Ред.*

Написанного в прежней переписи Ирсан Давлетиндин 32 года.

Написанное в прежней переписи Утяшка Сабакеев 47 лет. У него дети в прежней переписи написанные – Наврузакейка 28 лет. После переписи рожденный Тоиш 22 года. У Наврузейки сын после переписи рожденный – Илсану 1 год.

Написанное в прежней переписи Адля Илмекева 45 лет.

Написанное в прежней переписи Сеит Девлеткилдину 39 лет.

Написанное в прежний переписи Утямей Утяшеву 30 лет. У него дети после переписи рожденные – Уразмет 4 года, Саимету 1 год.

Написанное в прежней переписи Заит Крюсеву 33 года. У него брат в прежней переписи написанное – Роман 32 года.

Написанное в прежней переписи Бикул Янгуткину 27 лет.

Собой перешедший поселившейся Аринской волости из деревни Белой Воложки на Камышелга тоже написанного в прежней переписи в той же деревне Бакчура Багилдин – 34 года. У него дети после переписи рожденные – Абдулмен 10 лет, Алкей 8 лет. Итого татар 26 душ.

В той же деревне Хозесанове чуваша.

Умершего написанного в прежней переписи Федора Беметева после переписи рожденные дети – Калика 15 лет, Михаила 8 лет.

Умершего написанного в прежной переписи Силюшки Мембеева рожденные после переписи дети – Матвей 10 лет, Айдар 1 год.

Умершего написанного в прежней переписи Ситулы Меметева, рожденные после переписи дети – Еманка 22 года, Юкунха 6 лет.

У Еманки сын после переписи рожденный – Ермолай 1 год.

Умершего написанного в прежней переписи Бикенейка Маметова, рожденные после переписи дети – Залакин 13 лет, Юсуп 7 лет.

Написанного в прежней переписи Калметка Федоров 40 лет. У него сын после переписи рожденный Матря 2 года.

Итого чуваш 11 человек».

Хуҗа Хәсән – Күкшәм авылында җәмгысе 37 кеше. Менә шушы урында галимголәмә ялгышлык җибәргән дә инде! Сүз Зөя һәм Чуел өязләрендәге волость үзәге булып торган Хуҗа Хәсән хакында түгел, ә Хуҗа Хәсән-Күкшем авылы турында бара, югыйсә... Әйткәнемчә, бу тупас хата әлегәчә төзәтелмәгән. Төп Хуҗа Хәсән авылы Инеш Күпере (яисә Гөбенә буендагы Хуҗа Хәсән) авылыннан ике чакрым ераклыкта урнашкан. Күрше Чуаш Чүтие авылында чиркәү төзелеп, аның приходына Мәлки, Иске Корбаш, Хуҗа Хәсән һәм Соравыл (Янсуринское) крестьяннары да теркәлгәч, волость үзәге белән ике арада кичекмәстән күпер төзү ихтыяҗы туа. Өяз үзәге булган Чуел шәһәреннән Сембергә сузылган юл да Хуҗа Хәсән аша салына. Хәзер 1762 елгы җанисәп нәтиҗәләренә күз салыйк. Анда Хуҗа Хәсән-Күкшем авылында 87 кеше яши, диелгән: шуларның 58е – татар, 29ы – чуваш; 45 ир-ат һәм 42 хатын-кыз; барысы да – «новокрещенный»лар (чукындырылган). Халык санын алганчы алар бире дә 18 ел яшәп, Тәтеш өязенең Чыпчык авылы чиркәве приходына теркәлгән булып саналган. Документлар мондый мәгълүмат саклый[9] (староста Еким Кириллов, выборный Михаил Иванов һ.б. тарафыннан 1762 елның 24 июлендә эшләнгән күчермә):

[9] Мәгълүмат чыганактагыча бирелә. – *Ред.*

«А именно:	1745 г.	Умерли	1762 г.
Из татар крещенных:			
Музлюм после крещения Михаил Иванов	*14*		*31*
у него жена – Татьяна Константиновна 25 лет, взята			
из Свияжского уезда д. Чутеево,			
ясашная			
у них дети рожденные после крещения			
Петр			*9*
Татьяна – 5 лет			*5*
Мурсали Янтимей – после крещения Максим	*16*	*умер*	
Семенов			
Мурти Янтимей после крещения Михаил Семенов	*11*	*умер*	
у него жена – Авдотья Семеновна			
25 лет из д. Хозесаново			
у них дети – Иван			*8*
Макар			*4*
Курмаля Уразайкин – после крещения Корнила Захаров	*18*		*27*
жена – Мария Никитина, 22 года взята из д. Б. Волош-			
ки, ясашная			
дети – Алексей			*3 мес.*
Корнила сестра – Зелтуня – 35 лет	*10*		
Алка Резавин – после крещения Алексей Семенов		*1759*	
у них родился после ревизии сын (исеме танылмый)			*6*
Бориса Резавин – после крещения Борис Семенов	*5*		*22*
жена – Дарья Петрова, 20 лет			
из д. Б. Волошки, дети Иван			*4*
дочь – году (исеме танылмый)			
исеме танылмый (ир-ат)	*21*	*умер*	
Ибрагима Батышкин после крещения – Иван Кириллов	*42*	*умер*	
дети – Иван	*1*	*умер*	
дочь – Дарья, 24 л. Выдана д. Кушелгу			
Иркей Девлетки – после крещения Роман	*32*		*49*
Андреев			
жена – Дарья Андреева, 30 л.			
дети – Яков			*2*
дочь – Аксинья, 4 лет			
Иван Захаров	*47*		*64*
жена – Дарья Андреева, 50 лет			
дети Михаил	*28*		*45*
Тимофей	*29*		*46*
дочери – Арина Иванова, 15 лет			
Михаила жена Арина Семенова, 30 лет взята из д.			
Янсурино			
дети Иван	*1*		*18*
Никита			*5*
Никифор			*1*
дочь – Афима, 11 лет			
Еимофея (?) жена – Аксинья Иванова 32 года из д.			
Колесаново			
дети – Федор			*6*
дочь – Арина, 4 лет			
у него жена – Марфа Никитина, 20 лет			
из д. Белой Волошки			
Андрей Андреев	*45*	*умер*	
Сейт Деалевикшин	*39*	*умер*	
дочь – Анесия, 25 лет выдана в д. Б. Волошка			

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

«А именно:	*1745 г.*	*Умерли*	*1762 г.*
Утемей Утяшев после крещения Линмор Кириллов	*30*		*47*
жена – Ирина Семенова, 35 лет из д. Ишмурзино			
дети – Уразмет после крещения Алексей	*4*		*21*
Саймет – некрещенный	*1*	*умер*	
Егор			*9*
дочери – Марина, 25 лет			
танылмый (малай)			*6*
Иван			*2 мес.*
Закир Захаров	*33*		*50*
Жена – Арина Семенова, 50 лет			
дети – Арина			
Борис Андреев	*27*	*умер*	
жена – Катерина Семенова, 30 лет			
дети – Иван			*7*
дочь – Арина – 20 л., Арина – 3 л.			
Бориса сестра – Рахима – 40 лет.			
выдана замуж в д. Тутаева			
Банчура – некрещенный	*34*	*умер*	
дети – Абдулмен после крещения Михаил Иванов	*10*		*27*
Ашкен после крещения Алексей Иванов	*8*		*26*
дочь Кумыези выдана в д. Чутеево			
Михаила жена – Авдотья Семенова			
Алексея жена – Матрена Иванова			
сын -– Иван (яше танылмый)			
Чеваш крещеных:			
Кузьма Кириллов	*15*		*32*
жена 30 лет (исеме танылмый)			
дети Захар (яше танылмый)			
дочь Марея, 5 лет			
Авдотья Семенова – 25 лет			
Михаил Федоров	*8*		*26*
его жена 25 лет взята из д. Б. Волошки			
их сын рожденный после ревизии Матвей			
(яше танылмый)			
Матвей Кириллов	*10*		*27*
сын по крещении Алексей Кириллов	*1*	*умер*	
Еманил по крещении Семен Семенов	*22*		*39*
его жена Авдотья Алеуева 34 года			
дети Ермола	*1*	*умер*	
Иван			*4*
Дмитрий			*5 мес.*
исеме танылмый (ир-ат)	*6*		*23*
жена (исеме һәм яше танылмый)			
дети --------------			
Иван			*3*
дочь -------------			
Вдова Семенова			
Еким Кириллов это по крещении	*13*		*30*
жена – Катерина Родионова 27 лет			
дочь – Мария 5 лет			
Екима сестра – Марина Семенова 29 лет из			
д. Темеши			
Анна Семенова 35 лет, вдова			
Есюв Бикментин после крещения Осип Кириллов	*7*		*24*
жена Матрена 25 лет из д. Байтеряково			
дети Петр			*1*
дочь Домна 5 лет			

«А именно:	1745 г.	Умерли	1762 г.
Калмет после крещения Кирилл Захаров	40	1762	
жена – Анна Семенова, 50 л.			
дети Матвей	2		19
Андрей			10
дочь Дарья Кириллова 25 л.			
Марья 17 л.			
Матрена 13 л.			
А также в деревне татар:			
Роман Ирикеев	34		41
жена – Бикаби Биксулатова 17 л. из д. Ишмурзино			
дочери Калимя 40 л.			
выдана в д. Б. Волошку			
дети Семен			10
Итого в д. Колесаново			
мужчин татар новокрещен.	36	14	44
ясашн. татар	1	–	1
женщин новокрещен.	–	–	41
ясашн. татар	–	–	1
Женщин чуваш новокрещ.	18	–	18
Мужчин чуваш новокрещ.	18	3	15
Итого чуваш новокрещ.	36	3	33».

Ахыры киләсе санда

Даими авторыбыз, төбәкне өйрәнүче милләтпәрвәр, Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы Вячеслав Влас улы Данилов күптән түгел гомер бәйрәмен – 85 яшь тулуны билгеләп үтте. Аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек белән хәерле озын гомер һәм игелекле хезмәтендә уңышлар теләп калабыз! ■

Рамил Гали фотосы

Уби риваятьләре

Айзилә Сабирова

Бирегә байлык эзләүчеләр махсус җиһазлар алып килә һәм төрле тикшеренү эшләре алып бара. Балалар көзге бакча эшләрендә борынгы тәңкәләр таба. Борынгы җирләү урыннарына керсәң, техника ватылып кала яки кинәт һава торышы үзгәрә. Өч юл кисешүгә килсәк, ул да аерым бер сер йөртә... Юк, сүзебез борынгы Мисыр яки Вавилон, тарих китаплары буенча безгә яхшы таныш булган кабиләләр, җирлекләр турында бармый. Серле, риваятьләргә тиң бу авыл безгә күпкә якын булып чыкты. Әлеге сәяхәтебез Чүпрәле районының Уби авылларына багышланыр.

Уби авыл җирлегенә кергән 5 авылда бүген 1879 кеше яши. Татар һәм чуаш халкы авыл тормышын үзара дустанә мөнәсәбәт белән алып бара, хуҗалык белән шөгыльләнә, мәдәният һәм сәнгать белән кызыксына. Катнаш гаиләләр дә әлеге җирлектә еш очрый. Андый гаиләләрдә балалар ике телдә сөйләшә, милләтләр, телләр арасында көндәшлек, узыш бөтенләй сизелми. Ике мәктәп, мәдәният йорты, музейлар, балалар йорты, хастаханә – барысы да авыл халкы өчен үз эшен бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Гомумән, авыл гөрли. Тик аның бүгенгесе генә түгел, ә үткәне, тарихы, риваятьләре дә зур кызыксыну уята.

Уби авылының килеп чыгышы турында күптөрле риваятьләр саклнган. Шуларның берсенә мөрәҗәгать итсәк, Уби авылы халкы аларның тамыр җепләре чуаш батыры Убига тоташуына ышануын күрәбез. Уби Батыр ул – XIII-XIV гасырларда яшәгән хәрби җитәкче. Борынгы бабайлар сүзләренә таянсак, Уби авылы урынында элек куе урман шаулаган. Батый хан җитәкчелегендәге монгол сугышчылары Болгарга бәреп кергәч, Кама һәм Идел буенда яшәүче чуашлар бу урынга күченгән. XIV гасырда биредә туганнары, дуслары һәм батырлары белән Уби Батыр да тукталган. Ул Зур Цивиль елгасы буендагы, болынлыкта авылга нигез салган. Уби Батыр бик көчле һәм зирәк, үз халкын саклый-яклый торган җитәкче булып чыга. Соңыннан татарлар Уби халкын эзләп таба һәм Уби Батырга морза булырга тәкъдим итә. Ул исә, соңарып булса да, ризалаша. Уби авылында әлеге чордан сакланган җирләү урыннары бүгенге көнгә кадәр бар. Җирләү урыннарының мистик көче Уби авылы халкын әле дә борчый икән. Көзге уңыш җыю вакытында шул урыннарда техника туктап яки бөтенләй ватылып кала. Ахыр чиктә, бу җирләрдә эш башланса, һава торышы кинәт үзгәрә, җил йә давыл чыга. Борынгы көчләр шулай үзләрен белдертә дип саный халык.

Шулай ук Уби Батырның бу урыннарга Кама буйларыннан, Херле Çъыр дип аталган җирләрдән килүе турындагы риваятьләр дә очрый. Имеш, әлеге тарихи вакыйганы данлау йөзеннән, Уби халкы барлык изге урыннарына «Уби» кушымтасын өстәгән. Чыннан да, Уби җирлегендә бүгенге көнгә кадәр Çъыра дип аталган дога кылу урыннары сакланган. Шулай итеп, чуашлар истәлекле урыннарына «Уби» кушымтасын өстәп, яңа җирләргә көчүдән килеп чыккан яңа ватаннарына йөрәкләре белән якынаерга тырышкан. Өстәп шуны да әйтергә кирәк: чуаш милләтендә Уби кабиләсе иң дәрәҗәле булып саналган. Шуңа күрә киләчәктә Уби нәселе нигез салган авылларга да «Уби» кушымтасын өстәве артык гаҗәпләндерми.

Патшабикә Екатерина II өчен махсус күтәртелгән юл

Уби авылында табылган тарихи хәзинә



Уби базары урынында табылган бакыр төймәләр

Уби базары гөрләгән җирдә табылган тәңкәләрнең бер өлеше

Уби авылында Уби Батырга куелган һәйкәл

Уби авылындагы иң борынгы йортларның берсе

Уби базары территориясенең бер өлеше

Уби этнонимы да уйланырга мәҗбүр итә. Андый исем йөрткән халыклар бик борыңгыдан килгән. Алар Месопотамиядә яки Борыңгы Эламда яшәгәннәр һәм соңрак шул урыннарда чуаш этносына кергән кабиләләр белән очрашканнар. Шумерлар чорында исә Уби Аршак дип исемләнгән кала-дәүләт тә булган. Димәк, Идел Болгары сыман, йә халык калага багышлап исемләнгән, йә кала халыкка карап атама тапкан. Тормыш әлеге халыкны кая гына илтмәсен, алар үз тамырларын онытмаган, борыңгы бабаларының дәрәҗәсен, тарихта алып торган зур урынын истә тоткан.

Икенче версиягә колак салсак, авыл халкы бу урыннарга Чуашстан Республикасында урнашкан Уби авылыннан күченгән дигән риваятьләр йөри. Көчле рухлы һәм батыр халык, үзгә мәдәният, тел, милләт вәкиле булса да, бөтенләй икенче урынга матур-рәхәт тормыш артыннан юл тоткан. Биредә алар кеше кулы тимәгән җирләрне эшкәртә, яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерә, хуҗалык төзи башлаган. Акрынлап Чиркәү Убие һәм Базар Убие төп сату-алу үзәгенә әверелгән, соңыннан административ-сәяси үзәк булып саналган.

Уби базары турында 200-250 чакрым ераклыктагы җирлекләрдә, шәһәрләрдә бик яхшы белгәннәр. Авыл үзе дә базар, ярминкә урыны буларак кабул ителгән. Аның бер почмагында терлек сатсалар, икенчесендә камыр ризыклары белән сыйлаганнар, бер урамда тукыма, тегү өчен җиһазлар тәкъдим итсәләр, икенче якта көзге уңыш сатканнар. Уби авылының зур базары турында белмәгән-ишетмәгән кеше булмагандыр да, чөнки бирегә, дөяләргә утырып, хәтта Урта Азиядән, Кытайдан да сәүдәгәрләр килгән. Әлбәттә, ярминкәдә катнашыр өчен читтән килүчеләр базар хуҗасыннан рөхсәт сорарга тиеш булган. Шунысы кызык: базар хуҗасының йорты бүгенге көнгә кадәр сакланган. Убида күпчелек сәүдәгәрлек белән шөгыльләнгән, үз продукциясен дөрес һәм үтемле итеп тәкъдим итә белгән. Мәсәлән, шул ук Уби авылы базары хуҗасының үзенең трактиры булган һәм ул якын-тирәдә иң тәмле, сыйфатлы сыра саткан. Уби ярминкәсе авылны яшәткән, үстергән һәм киңәйткән, шул рәвешле тагын сигезгә якын авыл барлыкка килгән.

Уби авылы нигезендә зур, танылган базар булу сәбәпле, аның җирлегендә бүгенге көнгә кадәр төрле тарихи хәзинәләр табылуы гаҗәп тоелмый. Бу бигрәк тә табылган тәңкәләргә, кәгазь акчаларга кагыла. Сату-алу процессында еш кына тәңкә акчалар югалган. Бүгенге көндә аларның күбесе Уби авылының урта мәктәбе укучылары яки әлеге урыннарга казылмалар эзләп махсус килүчеләр тарафыннан табылып тора. Мәктәп музеенда сакланган тәңкә-акчалар нинди генә патшаларның идарә итү чорларына карамый: Петр I, Николай II, Александр I, Екатерина II һ.б. Иң кызыгы – шул тәңкәләр арасында Явыз Иван идарәсе вакытында (1530-1580 нче еллар) кулланылышта булган «тәңкәле» тиеннәр дә бар.

Россия патшалары турында сүз киткәч, Екатерина IIнең дә Уби авылы белән таныш булуын әйтеп узарга кирәк. Авыл турындагы борыңгы язмалар буенча, Уби авылы аркылы әби патша Чуаш иленә чыккан, икенче юл аша Казанга юл тоткан. Патшабикәгә уңайлы булсын өчен, Уби авылының осталары җирне махсус күтәртеп, сыйфатлы юл ясаганнар. Бу юл бүгенге көнгә кадәр сакланган, тик хәзер инде ул үлән-үсентеләр белән капланган.

Уби авылларында хәзерге заман тормышы борыңгы чорның тарихи корылмалары, истәлекле урыннары һәм җиһазлары белән «тату яшиләр». Авылда иң борыңгы агач йорт күбебезгә таныш булган материаллардан төзелгән заманча өй белән янәшә тора. Яхшы асфальттан ясалган юллар күп гасырлар дәвамында сәүдәгәрләр таптаган юлларга тоташа. Менә шундый бәйләнештә Уби авылының үзенчәлеге, сихрилеге һәм гүзәллеге чагыладыр да. ■

Чүпрәле – үткән заманнарда

Иршад Гафаров



«Сембер өязенең Ввальный Ыстаны Иске Чүпрәле авылы йомышлы татарлары...» турында тарихи чыганак. 1762 ел. РГАДА, 30 нчы фонд, 2 нче тасвирлама, 3147 нче эш, 563 б.

Борынгы бабайлар

Археологик эзләнүләр вакытында Чүпрәле районында берничә дистә болгар дәверенә караган, хәтта аннан да алдарак чорга нисбәтле торак урыннары табылган. Шулар арасында Городище, Чуаш Бизнәсе янәшәсендәге шәһәрчек урыннары, Татар Бизнәсе, Иске Ишле, Матак, Татар Шатрашаны, Яңа Чәке тирәсендәге борынгы болгар авыллары эзләрен, бронза чорына караган Чуаш Шәйморзасы курганнарын искә алырга кирәк. Татар Бизнәсе зиратында рун билгеләре (чөй язу) белән язылган, ә Иске Шәйморзада XIV-XV гасырларга караган кабер ташлары да табыла.

Е.А.Малов хезмәтеннән күренгәнчә, чүпрәлеләрнең ерак бабалары 1580 нче елларда Рязань губернасының Төмән округыннан яки Касыйм өязеннән күчеп килгән. Каракитә авылына беренче булып күчеп утыручының исеме – Габдулла, ә Төке авылына килүченеке Кудыкай Абыз булган. Хәзерге вакытта әлеге авылларда яшәүчеләр үзләрен 11 нче буын кешеләре итеп санныйлар. Моның белән килешә алмыйбыз, чөнки Е.И.Чернышевның «Селения Казанского ханства» исемле хезмәтендә шул чорда ук Чүпрәле төбәгендәге 15 авылның атамасы китерелә.

Элек заманнарда кешеләр, ирекле һәм ирексез рәвештә, төрле төбәкләргә күчерелеп утыртылганнар. Шуңа да якташларыбызның тамырларын шактый күп җирләрдә табып булыр иде. Мәсәлән, без 1760 елда Мансур авылына (хәзерге Баулы районы) Сембер өязенең Шатыршан һәм Югары Чапкастан, Башкортстанның Богдан авылына Яңа Ишле авылыннан күчеп утыручылар турында мәгълүмат таптык. Шулай ук 1803 елда Түбән Чәке, Шатыршан, Каракитә, Иске Чәке, Кушкувай авылларыннан 32 ир-атның күчеп утыруы хакында укыдык. Мондый мәгълүматларны тагын китереп булыр иде. 1811 елгы җанисәп мәгълүматларыннан күренгәнчә, 16 ел эчендә Иске Чүпрәле авылыннан 61 ир-ат (гаиләләре белән) бүтән төбәкләргә күчереп утыртылган.

Чүпрәле төбәгендәге авылларның борынгылыгын алардагы халык санының күплеге дә раслый. Мәсәлән, 1897 елгы җанисәп кәгазьләреннән билгеле булганча, бу җирлектә 500дән артык кеше яшәгән 41 торак пункт булган.

Саннар белән сөйләшүне дәвам итик...

Бу урында 1911-1913 нче елгы йортлар буенча үткәрелгән җанисәп мәгълүматларына тукталырга кирәк дип саныйбыз. Алардан күренгәнчә, 11 461 хуҗалыкта 31 115 ир-ат, 30 029 хатын-кыз – барлыгы 61 516 кеше яшәгән. 1913 елның 1 гыйнварына Кече Чынлы авылында гына да 906 хуҗалыкта 4701 кеше, шул исәптән, 2441 ир-ат, 2260 хатын-кыз булган. Авылда 8 мәчет, 3 мәдрәсә эшләгән.

Хуҗалыкларда 10 645 ат, 7696 сыер саналган. Шул ук вакытта 2005 хуҗалыкның аты да, сыеры да булмаган. Төбәктә 10 848 хуҗалыкның җире булган. 6651 гаилә исә бары тик 4 дисәтинә генә җиргә ия. Алар барысы да диярлек татар авыллары.

Тормышның очын-очка ялгап барыр өчен, ир-атлар, чит төбәкләргә китеп, хезмәткә ялланган. Мәсәлән, Чүпрәле төбәгеннән барлыгы 1662 кеше шахтер булып эшләгән. Моңардан башка 1197 кеше – «кара эшче», 324 кеше – завод-фабрикада, 109 кеше – нефтьче, 159 кеше – урман хуҗалыгында, 10 кеше алтын приискасында тир түккән. 37 кеше диңгезче булып хезмәт иткән.

Бу елларда төбәктә 61 авыл һәм поселок булган. Кызганыч, хәзерге чорда аларның дистәсе урынында бары зиратлар һәм ялгыз агачлар гына утырып калды. Чүпрәлеләрнең өлкән буыны Эштәбән, Кушкуак, Рус Бизнәсе һәм Рус Дуваны авылларының, Яңа Саплык, Кече Элмәле, Северный һәм Федоровка поселокларының атамаларын ишеткәндер. Аларның кайберләре заманында шактый зур булган. Мәсәлән, Кушкуакта 1941-1942 нче уку елында 42 укучы белем алуы турында әйтелә.

Ул чор авыл хуҗалыгындагы кайбер әйберләрнең күләме, бәясе укучыларыбызда кызыксыну уятыр дип уйлыйбыз. Сарык түшкәсенең бәясе 2,0 сумнан 5,5 (2,5-10) сумга кадәр булган. Сыер түшкәсен 18-50 (18-85) сумга сатканнар. Сыер тиресенә – 5-10 (5-15) сум, ат тиресенә исә 5-12 (4-15) сум сораганнар.

Ул вакытта бер олы кешенең ашау күләме менә болай булган: төрле он – 29,6 кг, шул исәптән, арыш оны – 22,08 кг, төрле ярма – 1,5 кг, бәрәңге – 18,72 кг. Әлеге саннар Городище авылының хәлле крестьяны Кузьма Егорович Егоров хакындагы мәгълүматтан алынды. Бу күрсәткечләр якынча губерна күрсәткечләренә туры килә. Торак йортның бәясе – 300 сум, сыер – 70, үгез бозау – 20, сарык – 5, бәрән – 3 сум, тавык исә 40 тиен торган.

Бу урында кайсыбер хезмәткәрләрнең айлык хезмәт хакларын да күрсәтеп үтәргә кирәк дип саныйбыз. Мәсәлән, шахтерлар айга – уртача 20,9 сум, нефть промысельләре эшчеләре – 23,1 сум, алтын приискаларындагылар – 25,5 сум, балыкчылар – 19,5 сум, завод-фабрикалардагы эшчеләр 19,2 сум акча алган. Столярларга, мебель ясаучыларга, такта яручыларга 9,7 сум түләнсә, авыл хуҗалыгы эшчеләре, батраклар, көнлек эшчеләр (көнлекчеләр) айга нибары 7 сум гына алган. Шул чорда укытучыларның айлык хезмәт хакы 29,2 (!) сум тәшкил иткәнен дә ассызыклап үтәргә кирәк.

Шуны да искәртәсе килә, якташларым Россиядәге барлык чараларда да катнашкан. Мәсәлән, 1797 елда әлеге төбәктән 54 кеше үзләренең атлары белән кораблар төзү өчен урман әзерләргә җибәрелгән. Шуннан инде йомышлы татарлар лашманнар сословиесенә күчерелгәннәр.

«Потлап алабыз, кадаклап сатабыз»

Чүпрәле якларының бер үзенчәлеге: ул да булса – авылларда һөнәр ияләренең күп һәм төрле булуы. Мәсәлән, Иске Чокалы авылы кешеләре эретеп ябыштыру һөнәрен яхшы белгәннәр. Алар, үзләренең эш коралларын күтәреп, авылдан-авылга йөреп, хәтта Самара өлкәсенә кадәр барып җиткәннәр, искергән, тишелгән җиз комган һәм самавырларны эретеп ябыштырып төзәткәннәр, шуның өчен бераз акча яки иген, бәрәңге юнәткәннәр.

Иске Кәкерле авылы үзенең такта яручылары белән дан тоткан. Бу эшне ир-атлар гына түгел, хәтта хатын-кызлар да оста башкарган. Алар үзләренең махсус пычкылары белән Россиянең бик ерак төбәкләренә кадәр барып җиткәннәр. Чуаш урманнарыннан нарат агачлары алып кайтып, аны ярганнар һәм базарга сатарга чыгарганнар. Алар тактаны шундый нечкә итеп ярганнар ки, хәтта базарга алып чыкканда, таралмасын, дип, башсыз кадаклар белән кадаклап та куйганнар. Шуңа да Иске Кәкерле халкында: «Потлап алабыз, кадаклап сатабыз», – дигән әйтем сакланып калган. Туры мәгънәсендә кулლансаң, бу әйтем 16 кило (бер пот) алып 400 граммлап (кадак) бүлеп сатуны аңлатырга тиеш, ләкин чынында ул тактаны кадак белән кадаклап сатуны аңлата. Соңрак әлеге авыл кешеләре, чит җирләргә китеп, балта остасы эшләрен дә башкарып йөрделәр, чөнки бу авыл зур, кешеләре күп булып, колхозда ир-атка эш булмый иде. Дөрес, язгы кыр эшләре һәм урак вакытында алар, туган якларына кайтып, колхоз эшендә дә катнаштылар.

Яңа Кәкерле авылында мич һәм морҗа чыгарыр өчен яндырылмаган кирпеч бастырдылар, моның өчен елга яры буендагы махсус балчыкны файдаландылар. Алар кирпечне күп вакытта базарга да алып чыкмадылар, чөнки кирәк кешеләр үзләре үк килеп алалар иде.

Задур авылыннан базарларга мич һәм морҗаларны, йорт стеналарын агарта торган акшар алып килделәр. Сатучылар аны йомшак чагында кабартма зурлыгында ясап киптерсә, ә инде сатып алган кешеләр аны ваклап, суда сыек масса хасил булганчы җебетеп файдаланалар иде.

Шеланга авылында әле үткән гасырның 60 нчы елларында да тәгәрмәч, чана, арба, күчәр, дуга, мичкә һәм агачтан башка хуҗалык кирәк-яраклары ясау комбинаты эшләп килде.

Болардан башка, кайбер авылларда юкәдән мунчала төшерү, чабата ясау (тугу), бау ишү эше киң таралган иде, ә Чуаш Чүпрәлесе авылы кешеләре бал-



1723 елгы 1 нче ревизиядә Һади Атласиның ерак бабалары: Мостафа Кондрат улы, утыз яшь; аның балалары: Усман – ике яшь, Али – 1 айлык; Мостафаның энеләре: Мортаза – 25, Абдулла – 15 яшь һәм Кондратның балалары. РГАДА, 350 нче фонд, 2 нче тасвирлама, 3108 нче эш, 352 б.

чыктан ясап яндырылган чүлмәк сатты. Шунысын да әйтәсе килә: ул заманнарда һәр гаиләдә агач савыт-саба, йорт кирәк-яраклары күп була иде: табак, кашык, чүмеч, туку ыстаны, киле, кисап, гөбе, май һәм бал савытлары (тәпән), күәс (куашна), тарак, йон эрләү җайланмалары (кензәлә) һ.б.

Городище авылында, чыбыктан үреп, кәрзин һәм бүтән әйберләр ясаганнар, тире эшкәрткәннәр, киез итек басканнар, палас тукыганнар.

Чүпрәле төбәге шулай ук мич чыгаручылары белән дә атаклы иде. Әле дә хәтеремдә, район үзәгендәге пекарнядагы мичләрне әнинең әтисе Кәрим бабай чыгарды, төзәтте. Ул мичләр зур булып, гөмбәзле иде. Бервакыт, Кәрим бабай авырып киткәч, кайберәүләр мичләрендә ипи пешерә алмый тордылар, чөнки якын-тирәдә аны төзәтә белүче кеше табылмады.

Базар сату-алу урыны гына түгел

Район халкының тормышында элекке заманнарда базарлар зур роль уйнады. Төп базарлар булып Уби, Иске Чокалы, Иске Чүпрәле һәм Матак авылындагылар саналды, аларның һәркайсы билгеле бер көндә генә уза иде. Мәсәлән, якшәмбе көнне Уби базары булып, аңа күрше Ульяновск өлкәсе һәм Чуашстаннан да байтак кеше җыела, алар куна киләләр иде. Базарларда хуҗалык кирәк-яраклары, төзү материаллары, шул исәптән, такта, бүрәнә, мүк, кадак һәм тимерчелектә ясалган башка металл әйберләр, атланмай, яшелчә, иске нәрсәләр һ.б. сатыла иде.

Базар сату-алу урыны гына түгел, бәлки, бер үк вакытта, кешеләрнең, дусишләрнең очрашып сөйләшү урыны да булып саналган. Кайберәүләр, аласы әйбере булмаса да, базарны бер әйләнеп чыгуны кирәкле эш итеп санаган. Сатып алучылар янына кызыксынучылар җыелып, сатулашырга да ярдәм иткәннәр, аларның бер өлеше, танышлар булсалар да, үзләрен чит кешеләр итеп күрсәтә торган булган. Мәсәлән, Яңа Чокалы кешеләре бергәләшеп, озын арбаларга утырып, Иске Чокалы авылына кадәр барганнар да, арбалардан төшеп, базарга кадәр аерым барып, базарда чит кешеләр кебек күрешеп исәнләшкәннәр, таныш сатып алучылар янына килеп, әйберләрнең бәясен сорашып йөргәннәр. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

Зирәк чуаш хатыны күлмәге

Айзилә Сабирова

Күлмәккә тукыма нәкъ шушы ыстанда тукылган.

Чуаш күлмәгенең бизәге — вак шакмаклы орнамент

Чуаш милли киемнәренең орнаменты

Милли киемнең үзендә һәрвакыт аңа гына хас тарихны, халык холкын һәм үзенчәлеген йөртүе күбебезгә мәгълүмдер. Чыннан да, милли күлмәктә, аның детальләрендә, бизәү орнаментларында милләтнең ни күргәнен, нәрсә олылаганын, нинди гореф-гадәтләргә өстенлек бирүен күрергә мөмкин. Бу күренеш чуаш милли киемнәренә дә хас. Билгеле булганча, чуаш сөйләме 3 диалектка бүленә: югары, түбәнге һәм урта түбәнге. Аларның һәрберсе бер-берсеннән аерылып тора, милли киемнәре дә деталь, төс ягыннан үзгә. Бу үзгәлекне төгәл мисаллар нигезендә тикшерер-ачыклар өчен, без Чүпрәле районындагы Уби авылының урта мәктәп музее җитәкчесе, тарих укытучысы Наталия Куракина белән сөйләштек.

Чуаш халкы һәрвакыт чиста-пөхтә генә түгел, матур һәм зәвыклы итеп тә киенергә омтылган. Шуңа күрә хатын-кызлар гардеробы күлмәк белән генә чикләнеп калмаган, анда бизәнү атрибутлары да шактый булган. Сурпан дип аталган хатын-кыз яулыгы һәр чуаш кызының бизәге, аның осталыгын күрсәтеп торучы билге булып саналган. Сурпан ул – аркага яки иңбашына кадәр төшеп торган очы бизәкле юка киндер тукымадан тегелгән ак яулык. Кызлар кечкенәдән

җеп эрләргә, ә аннары махсус ыстанда (станокта) шул җепләрдән тукыма тукырга өйрәнгән. Иң мөһиме – бу процесс кыз кешегә сурпанны әзерләр вакыт җитте дигәнне аңлаткан. Оста куллы кызларның гына катлаулы бизәкләре килеп чыккан. «Сурпанның үзәгендә күпчелек очракта сайланулы тукучылык ята. Анда кабатланмас бизәк ясар өчен үзенчәлекле туку техникасын кулланганнар, эшләнмәне зияк, чигү һәм челтәр белән матурлаганнар», – дип искәртеп узды Наталия.

Алда әйтелеп узганча, чуашларда барлыгы өч диалект бар һәм алар бер-берсеннән аерылып тора. Бу милли киемнәрдә дә чагыла. «Безнең як чуашларын анатри диалектына кертәләр. Алар аяк киеме буларак тала дип аталган ак сукно оеклар кигән. Ә югары диалектлы чуашлар таланы кара тукымадан эшли торган булган. Милли күлмәкнең тышкы кыяфәте дә бик нык аерылып торган. Югары диалектлы чуашларның күлмәкләре караңгы төстәге тукымалардан тегелсә, түбәндәгеләрнеке чуар, төрле төстә булган», – дип аңлатты Наталия. Бу мәгълүматны тагын да ныграк дәлилләү өчен каенанасының музейга бүләк иткән күлмәген карап китәргә булдык.

Наталия Куракинаның каенанасы яхшы тегүче булганлыктан, әлеге күлмәкнең тукымасын да ул үзе чиккән, аны сеңлесе белән теккән. Ул аны олы хатын-кыз чорында кияргә яраткан. Күлмәк мозаика сыман берничә тукыма кисәгеннән җыелган. Ник дигәндә, станокның үлчәме хуҗабикәсенең параметрларына туры килеп бетмәгән. Шуңа зирәк хатын бу проблеманы шундый кызыклы ысул белән чишкән һәм тиешле үлчәмдәге күлмәкне төрле тукыма кисәкләрен тоташтырып, җеп белән кысып теккән.

Күлмәкнең төсләре дә аерым игътибарга лаек. Түбән диалектлы чуашларга хас әлеге күлмәк алтыдан артык төстән тора. Ләкин бу күлмәкне артык чуар дип әйтергә тел әйләнми, чөнки алар барысы да бер-берсен тулыландырып тора. Күлмәкнең орнаменты вак шакмаклардан гыйбарәт, ә аскы өлеше чәчәкле тукымадан эшләнгән. Шакмак бизәгенә мөрәҗәгать итү очраклы түгел – чуаш милли киемнәрендә һәрвакыт геометрик орнаментлар өстенлек иткән. Киемне тагы да матурлау максатыннан, хуҗасы һәр шакмакның эченә аерым бизәк тә чигеп куйган.

Чуаш хатын-кызларының көндәлек киемнәре бик универсаль һәм уңайлы булган. Наталия Куракинаның каенанасының әлеге күлмәге дә – шундыйлардан. Хатын-кыз чорында ул бу күлмәкне бала имезгәндә кияргә кулай күргән. Күлмәкнең изү урынында махсус төймәләр белән уем ясалган. Шуның ярдәмендә ул, үзенә кыенлык тудырмыйча, төймәләрне чишеп, баласын имезә алган. Татар хатын-кызлары андый уемны изү белән капласа, чуаш кызлары аны йә төймә, йә төрле бизәнү әйберләре белән каплаган. Кияүгә чыгар алдыннан яшь чуаш кызлары булган барлык бизәнгечләрен үзенә таккан һәм аларны якынча бер ел дәвамында салмый киеп йөргән. Авыр бизәнү әйберләрен алар нибары йоклар алдыннан гына салган. Бала тапкач, әлбәттә, бу бизәнү әйберләрен кию мәҗбүрилеге беткән һәм алар яулык бәйләгән.

Чуаш халык киеме һәм бизәнү әйберләре – үткәндәге матди һәм рухи мәдәниятнең бай хәзинәсе ул. Меңьеллык традицияләрдә Азия һәм Европаның төрле географик төбәкләренең вакыты, кабилә-халыклары, аларның мәдәниятләре бәйләнеше тупланган. Чуаш халкының мәдәнияте, милли киемнәре җир эшкәртү, игенчелек белән тыгыз бәйләнгән. Шуңа табигыйлык, орнаментлар күптөрлелеге, киемнең күпфункциональлеге, төсләр байлыгы бу факторлар аша ачык күренә. Бигрәк тә хатын-кыз киемнәрендә! ■

100 ел элек татар дөньясы

Казандагы Крестовниковлар заводы

Казанның эшче төбәкләрендә театр

Элекке Крестовников заводы төбәгендәге татар эшчеләре өчен татар драма түгәрәге төзелә. Бу түгәрәк Крестовников төбәгендә атнага бер спектакль биреп барачак. 7 нче ноябрьдә Октябрь бәйрәме мөнәсәбәте белән татар эшчеләре өчен спектакль ясалып, тамашага Коләхмәтовның «Яшь гомер» исемле драмасы куелачак.

«Татарстан». – 1922. – 5 ноябрь.

Авыл хуҗалыгы мәктәбе

Иптәш Казаковның хәбәр бирүенә караганда, иптәш Ленин исемендә ясалган тәлинкәләрне сатудан җыелган акчага Җир эше халык комиссариатының беренче номерлы Совет хуҗалыгы янында авыл хуҗалыгы мәктәбе ачыла. Мәктәптә укучы шәкертләргә паек – Ачлык нәтиҗәләре белән көрәш комиссиясеннән, кием-салым әйберләре Татарстан Җир эшләре халык комиссариатыннан сорала.

«Татарстан». – 1922. – 5 ноябрь.

Ач балаларның саны

Комиссия рәисе Исхак иптәш Казаковның җыйган мәгълүматларына караганда, хәзерге көндә Татарстан Җөмһүриятендә атасыз-анасыз калган 30 мең ятим, атасыз яки анасыз калган 135 мең яртылаш ятим бала бар. Аларның һәммәсенә дәүләт тарафыннан ярдәм бирергә кирәк.

«Татарстан». – 1922. – 5 ноябрь.

Хөсәен Ямашев исемендә көтепханә ачу

7 нче ноябрьдә Октябрь бәйрәменең 5 нче елгы бәйрәме ителгән көндә кичке сәгать 4тә Яңа бистәдә Үтәмешев заводы ишегалдында сәяси аң-белем тарату баш идарәсе тарафыннан татар большевикларыннан Хөсәен Ямашев исеменә көтепханә ачыла. Көтепханәдә татарча һәм русча әсәрләр булачак. Пролетариат оешмаларының вәкилләре көтепханәне ачу мәҗлесенә чакырылалар.

«Татарстан». – 1922. – 6 ноябрь.

Казан университеты эшче факультеты татар студентлары арасында

Бу ел Казан университеты эшче факультеты татар студентлары арасында эшләр үткән еллардагыга караганда бөтенләй башка. Бу ел, бердән, татарлардан укучылар да күбрәк. Бу ел рабфакта бик күп төрле түгәрәкләр бар.

Бу түгәрәкләрдә татар студентлары якыннан иштиракь итәләр. Татар әдәбиятын өйрәтү түгәрәге дә төзелергә күптән карар кылынып куелган булса да, түгәрәкне алып барырлык руководитель тапмаганлыктан, түгәрәк хәзергә кадәр эшкә башлый алмый тора әле. Октябрь бәйрәменә багышлап татарча кульязма «Кызыл студент» журналы чыгарылды. Журналда рабфактагы эчке тормыштан башка гомуми мәүзугъка язылган мәкаләләр һәм хикәяләр дә күп.

«Татарстан». – 1922. – 13 ноябрь.

Матбугат тирәсендә

Вакытында гөрләп торган Оренбургның татар матбугатыннан аерылганына байтак вакыт үтте. Үткән елның ахырларына кадәр аксап-аксап кына вилаять партия комитеты хозурында «Юксыллар сүзе» газетасы дәвам итеп килгән иде. Ләкин ул дәвам итә алмады, шул ел ахырларында тукталып калды, шуннан соң Оренбурда татар вакытлы матбугаты тәмам сүнде.

Гали мәктәпләрдәге яшь татар укучыларының бу күңелсезлеккә тик кенә карап каласылары килмәде бугай, аз-маз булса да гали уку йортларында «әдәбият кружогы тарафыннан» диелеп, әдәби нәрсәләр язгалаштырырга омтылу исләре килә башлады.

Шушы арада югарыда әйтелгән «Оренбур артистлары коллективы» тарафыннан «Яшерен серләр» исемендә кулъязма журнал чыгарыла башланды. Бу журнал кульязмасы матбагада басылып, халыкка таратылмыйча, әдәби концерт, уен кичәләрендә тамашачыларга кычкырып укыла.

Муса Җәлил. «Безнең байрак». – 1922. – 21 ноябрь.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

Кадыкай абыз

Иршат Закиров

Кадыкай абыз җирләнгән зираттагы намаз йорты

Дин эзәрлекләнгән чакларда да бирегә халык килде

Татарстанның Чүпрәле районында рәсми рәвештә Татар Төкесе дип аталучы җыйнак кына бер авыл бар. Районның көнбатышында, Чуаштан Республикасының Шомыршы районына терәлеп үк урнашкан бу авыл халкыбыз мәдәнияте өчен шактый ук дәрәҗәдә билгеле төбәкләрдән санала. Биредә 1921 елда татарның күренекле шагыйре, фронтовик-партизан, Татарстан Язучылар берлеген җитәкләгән Зәки Нури дөньяга килгән. ХХ гасыр башында татар милләтенә тугрылыклы хезмәт иткән дин галимнәре, язучылар бертуган Шәйхелислам (1869-1911) һәм Шакирҗан (1880-1933) Хәмидиләр дә шушы авылдан.

Ә менә соңгы берничә дистә елда Татар Төкесе авылы тирә-яктагы күпсанлы диндар милләттәшләребезнең, ислам тарафдарларының елга бер мәртәбә җыйналу, корбан чалу, гыйбадәт кылу урынына әверелде. Монысы җәсәде шушы

авыл янында динебез кануннарына туры китереп җирләнгән, исеме берсеннән-берсе серлерәк һәм гыйбрәтлерәк риваять-легендаларга төренгән **Кадыкай абыз** шәхесе белән бәйләнгән. Ел саен май аеның соңгы җомгасында биредә зур әзерлек белән дини-милли чара үткәрелә: намаз укыла, вәгазьләр, дин тарихына кагылышлы чыгышлар сөйләнелә, дистәләгән корбан чалына, хәләл сый-хөрмәт тулы өстәлләр артында олы мәҗлес оештырыла. Районның барлык татар авылларыннан кала, бу җыенда елның-елында Казан һәм Сембер шәһәрләреннән, Чуашстаннан, Ульяновск өлкәсеннән мөселман кардәшләребез катнаша. Дин белгечләре, имамнар, милләт тарихын зурлаган бик күп кеше биредә күңелен тынычландырып, рухын сафландырып китә.

Әлеге чаралар хакында сүз башлаганда, без «соңгы берничә дистә елда», дидек. Бу элек халык Кадыкай абызны искә алмаган, мондый җыелулар булмаган дигән сүз түгел. Эш шунда ки: соңгы елларда әлеге җыеннар аерата зур оешканлык, күтәренкелек белән үтә башлады. Ул, район һәм әлеге авылны үз эченә алган Иске Кәкерле авыл җирлеге җитәкчеләренең ихлас ярдәме һәм турыдан-туры катнашы белән, олы дини бәйрәмгә әверелде.

Ә бит бүген динебез өчен дә, милләтебез өчен дә зур әһәмияткә ия саналырлык Төке җыеннарының тарихы чынлыкта бик еракларга барып тоташа. Совет чорында, дин эзәрлекләнгән чакларда да, халык бирегә килде, Абыз бабай рухына догалар кылды, сәдакалар өләште. Авырулар, бирегә килеп, Кадыкай кабере тирәсендәге сафлыктан, тынычлыктан сырхауларына дәва тапты. Шифалы сулышлары белән тирә-юньдә дан тоткан өшкерүчеләр, халык табиблары, Аллаһы Тәгаләнең чиксез рәхмәте белән, мөселман кардәшләренә югалган саулыкны кире кайтарырга булышты.

Кадыкай абыз тирә-яктагы милләттәшләребез өчен изге шәхес саналды. Дини бәйрәмнәрдә һәм мәҗлесләрдә аның рухына аерым дога кылына иде. Татар Төкесе авылының күп кешеләре абыз каберен карап торуга, аның әйләнә-тирәсен тәртиптә тотуга үз өлешен кертеп яшәде.

Хәзер Кадыкай абызга багышланган чаралар елдан-ел күркәмрәк төс ала; динне, милләтне олылап, бәйрәм кунагы буларак килүчеләргә барлык уңайлыклар да тудырыла. Абыз бабай каберенең тирәсе җыйнакландырылган, ул тимер койма белән әйләндереп алынган. Кечкенә генә мәчеткә кереп намаз укып чыгарга, төзекләндерелгән күл суында бит-кулларны юарга, аның иркен һавасын суларга мөмкинлек бар. Килүчеләр өчен күптән түгел кунакханә дә булдырылды.

Кадыкай абызның реаль шәхес булганлыгына шигебез юк

Әмма бирегә килүчеләрнең күңелләрен бер әйбер борчый. Ул да булса – Кадыкай абыз хакында төгәлрәк, системалы, нигезле мәгълүматны белү теләге һәм бу теләкнең бүгенгәчә тулысынча тормышка аша алмавы. Реаль шәхес булганмы ул яки халык хәтере буразналарында гасырлар буена җыелып, сакланып килгән аерым эпизодлардан тупланган җыелма образмы? Реаль булса, аның тормышы кайсы чорларга карый? Нинди милләт, кайсы халык кешесе ул? Аны безнең якларга нинди язмыш китергән һәм монда мәңгелеккә калырга дучар иткән? Ни өчен ул халык тарафыннан изгеләштерелгән? Һәм башка бик күп сораулар…

Халык авыз иҗатында яшәп килгән Кадыкай абыз турындагы риваять-легендалар бу сорауларның кайберләренә җавап та бирә сыман. Ләкин риваятьне

тарих дия алмыйсың. Мәсәлән, бер легенда Кадыкайны «Әби патша» заманында яшәгән һәм татарларны көчләп чукындыруга каршы хәрәкәткә җитәкчелек иткән дип аңлатса, икенчесе аны данлыклы Идегәй батырның ерак бабасы белән бертуган булган дип тасвирлый.

Кадыкай абызның реаль шәхес икәнлегенә шигебез юк. Моны язмабызда исбат итәргә тырышачакбыз. Озак еллардан бирле күңелдә йөргән хыялны – Төке каһарманы Кадыкай хакында мөмкин булган барлык төр материалны җыйнап, хәлдән килгәнчә системалаштырып, архивларда, китапханәләрдә, интернет челтәрендә табарга мөмкин булган, төбәгебез тарихына кагылган документаль чыганакларны файдаланып, күләмлерәк бер язма әзерләү теләге кулга каләм алырга мәҗбүр итте. Төп максатыбыз – бу язманы галимнәргә, чын тарихчыларга җиткереп, аларда фәнни тикшеренүләргә кызыксыну уяту, Кадыкай абыз хакында гына түгел, тулаем Тау ягының гафу ителмәслек дәрәҗәдә начар өйрәнелгән урта гасырлар тарихы турында капиталь фәнни хезмәтләргә өмет итү.

Кадыкай абыз хакында риваятьләр

Халыкта буыннан-буынга тапшырылып килгән риваять-легендаларда күпмедер дәрәҗәдә тарихи чынбарлык чагылыш тапкан. Шуңа күрә, халык авыз иҗатының бу төренә карата илтифатсызлык күрсәтү, әкият кенә итеп карау дөрес булмас иде.

Риваятькә күчкәнче, ике нәрсәгә генә тукталып алыйк. Беренчедән, Кадыкай абыз хакындагы мәгълүматларны озак еллардан бирле үз хәтерләрендә саклаган, кайбер кыйммәтле мизгелләрне кәгазь битләренә дә теркәп куйган фидакяр шәхесләребезнең исемнәрен күрсәтик, аларга олы рәхмәтебезне белдерик. Иске Кәкерле авылында яшәгән «аяклы энциклопедия», һәвәскәр тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, күптән түгел арабыздан киткән **Рифкать ага Иматдинов**ның үз авылы һәм тирә-як авыллар тарихы буенча туплаган бай материаллары арасында Кадыкайга караганнары аерым урын алып тора. Рифкать абыйның калын-калын дәфтәрләрендәге язмалары Абыз бабайга тирән хөрмәт-ихтирам белән сугарылган.

Татар Төкесе авылының мөхтәрәм кешесе **Нурулла ага Шәрәфетдинов** узган гасырның алтмышынчы елларында авыл халкының Кадыкайга күрсәткән хөрмәте турындагы инде кызыклы тарихка әйләнгән мәгълүматларны, шул чакларда йөргән сөйләкләрне бүгенге буынга тапшыруда зур хезмәт куя.

Шул ук авылдан **Сәлимә Ибраһим кызы Хәйретдинова** сөйләгәннәр дә үтә кызыклы, тирән һәм бай эчтәлеккә ия.

Районыбызның олуг тарихчысы, язучы, танылган журналист, хәзер инде мәрхүм булган **Рафаил ага Субаев**ның Чүпрәле тарихына багышланган китапларында да Татар Төкесенең горурлыгы – Кадыкай абыз хакындагы мәгълүматлар тиешле урыннарын алган.

Иске Кәкерле авылы җирлеге, шул исәптән, Татар Төкесе авылы турында да бай мәгълүматлар тупланган, 2017 елда Казанда басылып чыккан «Тирән хәтерле Иске Кәкерле» китабының автор-төзүчесе, күренекле журналист һәм язучы **Нәсим Акмал** да үз хезмәтендә Кадыкай абызга аерым бер бүлек багышлады.

Кадыкай абыз хакында сөйләгән чакта халык аны төрлечә атый. Минем Яңа һәм Иске Кәкерле, Яңа Ишле һәм Иске Чүпрәле авылларында дини мәҗлесләрдә

әрвахлар рухына дога багышлаган чакта аңа атап аерым дога кылынганга күп тапкырлар шаһит булганым бар. Бу вакытта авыл имамнары аны *Абыз бабай* дип кенә атыйлар. Кадыкай яки башка төрле исем өстәлми. Риваятьләрдә исә әлеге шәхес бер җирдә – *Абыз Кадыкай* дип, икенче-өченчеләрендә *Абыз Кадекай, Абыз Кудыкай, Абыз Кудекай, Абыз Кудюкай* дип исемләнә. Кайсысы дөресрәк икән соң?..

Беренче чиратта, «абыз» сүзенең «мулла, имам», «дини юлбашчы», «җитәкче, яклаучы» мәгънәләренә ия титул икәнен искә төшереп китәргә кирәк. Димәк, татар теле кануннары буенча «Абыз Кадыкай» дип түгел, «Кадыкай абыз» дип әйтү дөресрәк (мәсәлән, гадәттә, «мулла Габдулла» дип түгел, ә «Габдулла мулла» дип әйтәләр). Ә «Кадыкай» сүзенә килгәндә, без алдарак биредә нәкъ шушы вариантның дөрес булуын, һәм, иң кызыгы – бу сүзнең дә язмабыз героеның үз исеме түгел икәнлеген исбатларга тырышырбыз.

Димәк, сүзебезне бары тик **«Кадыкай абыз»** турында гына алып барачагыбыз турында килештек дип саныйк! Ә хәзер риваять укыйбыз.

«Кайчандыр Төке авылы җиде мәчетле бик зур авыл булган. Зурлыгына карап-тыр инде, авылны Өфе каласы дип тә йөртәләр.

Шушы авылдагы бер байга батрак булып яшь кенә егет килеп яллана. Ул йорт тирәсендәге эшләрне башкарырга, урманга утынга йөрергә тиеш була. Бай хуҗа бу егетнең һәрвакыт урманнан эшен бик тиз башкарып кайтуына игътибар итә. Көннәрдән беркөнне ул, сиздерми генә, батракның артыннан урманга китә һәм аның ничек эшләгәнен күзәтә башлый. Анда күргәннәре байның һушын ала.

Урманга кергәч, егет юан-юан агачларны бик җиңел аударып, бер дә көч куймыйча диярлек арбага төйи. Әйтерсең лә, агачлар үзлегеннән киселеп, үзлегеннән арбага өеләләр.

Бай, шыпырт кына һәм тиз генә кайтып, бу хәлне хатынына сөйләп бирә. Алар үзләрендәге ялчының гади кеше булмавына төшенәләр һәм, әлбәттә, куркуга төшәләр. Ир белән хатын, ялчының изге кеше икәнлегенә ышанып, аңа карата киләчәктә гел яхшы мөгамәләдә генә булырга кирәк дип сүз куешалар.

Тора-бара бу батрак авыл мулласы булып китә. Аны Кадыкай абыз дип йөртә башлыйлар. Аның гаиләсе булмый, гомере буе ялгыз яши. Кадыкай абыз Төкле Түбә исемле изге кеше белән бертуган булган. Төкле Түбә Әстерханда җирләнгән. Аларның тагын бер туганнарының кабере хәзер Чуашстан Республикасына керә торган Торын авылы янында. Бу шәхесләр бирегә Пенза якларыннан килгән булганнар.

Кадыкай абыз тирә-якта үзенең авыруларны терелтү сәләте белән дан казана. Ул авыл халкын төрле үләннәр белән һәм догалар укып дәвалап тора. Бервакыт аңа патшадан вәкил килә һәм, каты авырудан җәфа чигүче патша кызын дәвалап карау өчен, Кадыкайны башкалага алып китәргә тели. Кадыкай бармый, кызның үзен янына китерергә куша. Башка чара калмагач, шулай эшлиләр дә, өметсез саналган авыру кыз берничә көндә терелеп китә. Бу хезмәте өчен патша Кадыкайга 800 гектар урман һәм 90 гектар печәнлек җир бүлеп бирә. Кадыкай урманны да, җирне дә Төке авылы халкы исеменә яздыра. Ул урман хәзер – «Төке урманы» дип, ә печән аланлыгы «Быталой» дип йөртелә.

Төкедән ерак түгел Зөлкарнәй елгасы бар. Бу елганың исеме шушы тирәләрдә яшәгән изге Зөлкарнәй белән бәйле. Менә шул елга буйларында кайчандыр зур сугыш була. Авылның бик күп кешесе шул сугышта үтерелә. Монда әле дә кеше сөякләре табыла дип сөйлиләр.

Кадыкай абыз үзе Иске Кәкерле белән Яңа Кәкерле арасында урыслар белән көчле бәрелештә үтерелә. Патша гаскәрләре халыкны чукындырырга дип килгән булалар. Мөселманнар бирешми, әмма күбесе әлеге көрәштә башын сала. Исән калучылар абызның җәсәден үзе яшәгән Төке авылы янына кайтарып җирлиләр».

Халыкта Кадыкай турында менә шундый сүзләр йөри. Аларның чын тарих белән бәйләнеше бармы икән соң? Чынбарлыктан алынып, буыннар хәтеренә кереп калган вакыйгаларга соңрак кешеләр үзләреннән дә өстәми калмаганнардыр, әлбәттә. Әйтик, элек тә бик зур булмаган, бүген исә бөтенләй кечерәеп калган Татар Төкесендә кайчандыр җиде мәчет булуына ышануы кыен. Төке авылы исеме беренче мәртәбә А.Зерцалов төзеп калдырган «Приходо-расходная книга г.Симбирска и уезда 1665-67 годы» дигән җыентыкта[1] телгә алына. Анда бу авылда ул чакта 4 бөтен йорт (двор) һәм 4 ярымйорт (полудвор) булганлыгы күренә.

1780 елда Сембер наместничествосы чикләрендә Буа өязе төзелә. Сембер өязеннән күчереп, яңа өяз составына йомышлы татарлар яшәгән Төке авылы да кертелә. Ул чакта авылда барлыгы 27 ир-ат яшәгән. Димәк, унҗиденче гасыр ахырында да, унсигезенче гасырда да Төкенең җиде мәчетле авыл булуы турында сүз алып барып булмый. Бары тик соңгы, унынчы ревизия нәтиҗәләре буенча төзелгән «Симбирская губерния. Список населенных мест по сведениям 1859 года» белешмәлегендә генә[2] без лашманчы татарлар авылы Татар Төкесендә 330 кеше яшәгәнлеген һәм анда бер мәчет булганлыгын күрәбез.

Иң мөһиме (яки «иң кызганычы» диикме?) – Төке авылына кагылышлы безгә билгеле документларның берсендә дә «Кадыкай» исемле яки «Кадыкаев» фамилияле кешеләр күренми. Йорт хуҗаларының исем-фамилияләрен күрсәткән, югарыда телгә алынган «Приходо-расходная книга»да да, Төке авылы буенча ревизияләр материалларында да юк алар.

Риваятьтәге Төкле Түбә образы

Риваятьтәге тагын берничә җөмләне искә төшерик: *«Кадыкай абыз Төкле Түбә исемле изге кеше белән бертуган булган. Төкле Түбә Әстерханда җирләнгән»*. Менә монысы кызыклырак момент! Чөнки мөселманнар тарафыннан изгеләштерелгән, Төкле кушаматын йөрткән шәхес хакында легендалар фәнгә яхшы билгеле. Хәзер бу хакта берничә сүз.

Аерым изгеләр, әүлияләр төрле төрки кабиләләрнең, ыругларның юлбашчылары, Аллаһы Тәгалә каршында яклаучылары, таянычлары булып саналган. Бу затлар хакындагы легендалар, риваятьләр алар турындагы тылсымлы сюжетларны үз эченә алган. Мондый риваятьләрнең барысында да диярлек әүлияләрнең тиңдәшсез көчкә ия икәнлекләре, аларда авыруларны терелтү сәләте булу һ.б. турында сөйләнелә. Ләкин шулай да һәрбер изге затта үзенә генә хас аерымлыклар, индивидуальлек булу турында да әйтелә. Шуңа күрә

[1] Материалы для истории Синбирска и его уезда : (Приходо-расход. кн. Синбир. приказ. избы. 1665-1667 гг.) / [Публ.] А.Н.Зерцалов. – Симбирск: Симбирск. губ. учен. архивная комис., 1896.
[2] Списки населенных мест Российской империи, составленные и издаваемые Центральным статистическим комитетом Министерства внутренних дел. – СПб.: изд. Центр. стат. ком. Мин. внутр. дел, 1861-1885. Вып. 39. Симбирская губерния: ... по сведениям 1859 года / обраб. ред. А.Артемьевым; сост. и изд. Центр. стат. ком. М-ва внутр. дел. – 1863.

легендалардагы әүлияләрне бер-берсе белән бутап булмый, алар төрле шәхесләр буларак күзаллана.

Шундыйлардан безне аеруча кызыксындырганы – бүген дә Түбән Иделдә, Әстерхан мөселманнарында бик популяр булган изге Төкле баба образы. Абдерахман хаҗи Төкле баба – төрки-кыпчаклар этномәдәниятендә бик тә билгеле, дан казанган әүлия. Төрле төрки халыклар (нугайлар, казакълар, каракалпаклар, башкортлар) аны үз телләренә яраклаштырып, төрлечәрәк, әмма охшаш исемнәр белән атыйлар. Кайдадыр ул *Баба Туклес,* кайдадыр *Чәчле (Шашлы) баба, Хаҗи Әхмәт Төкле, Төкле Азиз, Төкле Түбә* һ.б. Төрки халыкларның героик эпосларында Төкле баба данлыклы Идегәйнең бабасы буларак телгә алына. Ул нугай халкын һәм Алтын Урда ханы Үзбәкне ислам диненә күндергән дип исәпләнә.

Әстерхан татарларында бүген дә шундый легенда яши. Түбән Иделдә гомер иткән мәҗүси төркиләрне исламга өндәгән чакта бервакыт ул мәҗүсиләрнең шаманнарын ярышка чакыра. Ике зур чокыр казытып, бу чокырларга көчле ут салдыра. Янган уттан чыккан эсселектән чокырларның янына да килергә мөмкинчелек булмый. Төкле баба шаманнарга, үз догаларын укып, чокырларның берсенә төшәргә тәкъдим итә, икенче чокырга үзенең төшәсен белдерә. Берничә шаман, чокырга төшеп, шунда ук янып бетәләр. Ә Төкле баба чокыр янында дога укый һәм кинәт аның бөтен тәне йон (төк) белән каплана. Шул килеш чокырга төшеп, ул анда утырып тора, күпмедер вакыттан соң, бернинди зарар алмыйча, чокырдан чыга. Тәнен каплаган йон аны уттан саклап кала. Моны күреп, күпчелек исламны кабул итә. Халыкның беришесе исә Төкле бабаны шайтан дип таный һәм күргәндә аннан кача башлый. Ләкин алар азчылык була.

Күпчелек төрки халыклар авыз иҗатының безгә кадәр килеп җиткән үрнәкләрендә, эposларда Төкле баба көчле, батыр, баласыз гаиләләрне балалы итүдә булышкан изге зат, мәрхәмәтле яклаучы, күзгә күренмәс игелек иясе буларак тасвирлана.

Тарихчы галим В.М.Жирмунский хәзерге вакытта Төкле баба рухына аеруча нык табыну җирлекләре итеп Казакъстанның Җамбул өлкәсен һәм Русиянең Әстерхан өлкәсен күрсәтә. Җамбул өлкәсендәге Каратау тирәсендә Төкле баба исемен йөрткән шифалы чишмә дә бар икән. Ә Әстерхан шәһәренең Ленин районына караган Мошаик бистәсендәге изгеләр зиратында Төкле баба үзе җирләнгән дип санала. Аның кабере тагын дүрт әүлия (Шәех Маслетдин Замана-хаҗи Бухари, Абдерахман Сәйхаҗи, Ямгурчы ишан, Мәхмүт ишан әл-Алмалы әд-Дагыстани) каберләре белән янәшәдә. Биш изгенең кабере үзенә бер комплекс тәшкил итә.

Төкле баба хакында шул кадәресе җитеп торыр. Бу турыда күбрәк Әстерхан шәһәреннән тарихчы галим Андрей Вячеславович Сызранов хезмәтләреннән[3] укып белергә мөмкин.

Ә хәзер Кадыкай абыз хакындагы күптөрле риваятьләрне, безгә кадәр язылган һәм азмы-күпме бу образга кагылышы булган әдәбиятны җентекләп анализлаганнан соң җыелган бар мәгълүматны, шушы мәгълүматтан чыгып, үзебездә барлыкка килгән фикерләрне, кыскача гына итеп, укучыларыбызга җиткерик.

[3] Сызранов А.В. Культ мусульманских святых в Астраханском крае. Этнографическое обозрение №2, 2006 г.

«Кадыкай абыз укулары»нда катнашучылар

Кем ул Кадыкай Абыз?

Ул – бүгенгә чаклы Татарстанның Чүпрәле районындагы, күрше Чуашстан һәм Ульяновск өлкәсендәге мөселман-татар авыллары кешеләренең хәтерендә яшәүче легенда һәм риваятьләр персонажы. Халык ышануы буенча, Кадыкай абыз – ислам динен таратуга, дин өчен көрәшкә үзеннән зур өлеш керткән, чиктән тыш зур көчкә һәм сәләткә ия булган мөселман лидеры. Кадыкай абыз ислам динен эзәрлекләүче көчләргә каршы үзе җитәкләгән яуда һәлак булган һәм Татар Төкесе авылы янында җирләнгән.

Кадыкай абызның бу дөньяда чынлап та яшәгәнлегенә шигебез юк. Аныкы кебек күп яктан конкретлаштырылган образны, бер җирлексез, халык үзе генә уйлап чыгара алмый. Танылган рус миссионеры һәм тюркологы Е.А.Малов үзенең «Сведения о мишарях» (Казань, типогр. Императорского Казан. ун-та, 1885) дигән китабында болай дип язган: *«Первый поселенец… в деревне Тюкы Кудокай абыз (или Худайбирды). В настоящее время мишари этих деревень считают себя в 11-м колене от… Кудюкая»*. Бу сүзләрдән нинди нәтиҗә ясарга мөмкин? Иң беренчесе, Малов язганга да, аңа Төке кешеләре сөйләгәннәргә дә ышанмый мөмкин түгел. Аларның берсенә дә ялганлауның һич тә кирәге булмаган бит. Димәк, Кадыкай абыз дигәнебез Ходайбирде исемле кеше булган. 1885 нче елларда яшәгән кешеләр «без аның унберенче буыны» дигәннән абызның уналтынчы гасыр урталары кешесе булганлыгын исәпләп чыгарырга мөмкин (бер буынны 30 ел дип алсаң, 11x30=330 ел, 1885-330=1555 ел).

Ә ни өчен бер кешедә ике исем – Ходайбирде һәм Кадыкай? Без бу хакта болай уйлыйбыз: Ходайбирде абыз нугай кешесе булгандыр һәм ул бу ха-

лыктагы «Кадыкай» нәселеннән чыккандыр. Казан ханлыгы чорында Нугай Урдасы вәкилләренең Идел бассейны, шул исәптән, Зөя һәм Карлы елгалары буйларында яшәп, тарихка үзләренең эзләрен калдырганлыгы фәнгә яхшы билгеле. Казан дәүләтенең этносоциаль тормышында нугайларның роле турында галим Б.Хәмидуллин да тәфсилләп яза[4]. Безнең якларның топонимикасында да моны дәлилләүче билгеләр бар. Элек Иске Задур авылының бер урамы «Нугай очы» дип йөртелгән. Каракитә (русчасы – Каракитан), Дуван һәм Кырык Садак авылларының исемнәре заманында бу авылларга нигез салган нугай ыруларының исемнәреннән калуы турындагы фикер дә шик тудырмыйдыр. Күрше Ульяновск өлкәсендә Нугай, Нугай иле һәм Канлы авылларының булу факты да әлеге фикер файдасына сөйли. Нугай төркемнәрен бирегә кадәр җитәкләп алып килгән морзалар, бәкләр (биләр) уңдырышлы кара туфракка кызыкканнардыр. Аларның акрынлап утрак тормыш рәвешенә күчүләре дә, бәлки, безнең якларда башлангандыр. Би дигәннән, төбәгебездәге Уби (Уй би?), Биштерле (Би Стәрле?), Бизнә (Би Сина?) атамалары да нугайларга, йә булмаса, тагын да элеккәрәк китеп, кыпчак кабиләләренә бәйледер дип уйлыйбыз. Әлбәттә, бу хакта ныклырак эзләнүләр кирәк әле.

Язмабызны төбәгебездә «рәсми рәвештә Татар Төкесе дип йөртелә торган» дип башлап җибәргән идек. Биредә «Татар Төкесе» атамасы белән авторның килешеп бетмәве сизелгәндер. Чөнки бу авылның исеме дә «Теке» дигән (Түке, Тәкә, Туки, Тукю – әдәбиятта төрлечә язылышы очрый) төрки кабилә исеменә бәйледер дип фикер йөртәбез. Шулай булса, унҗиденче гасыр урталарында бу якларга йомышлы татар-мишәрләр килеп утырганчы ук әлеге авыллар булган (һәм, бәлки әле, зур булып, гөрләп яшәгәннәрдер дә) дип уйларга нигез бар дигән сүз. Кем белә, җиде үк булмаса да, берничә мәчетле дә булгандыр әле Төке авылы.

Теке яки Тәкә – Табын кабиләсенең бер ыруы. Төрекмәннәрдә үзләрен шушы ырудан санаучылар әле дә бар. Бер очрашуыбызда күренекле тарихчыбыз Дамир Исхаков миңа: «Сезнең төбәкнең төрекмән, угыз кабиләләре белән бәйләнеше бар», – дигән иде. Шул ук вакытта угызларның, шул исәптән, Теке ыруы кешеләренең дә, нугайларның этногенезында катнашы барлыгы билгеле. Аерым алганда, бу хакта нугай тарихчысы Әмирхан Мәҗитов яза[5].

Кадыкайлар ыруыннан булган Ходайбирденең, биредә үзенең турыдан-туры кардәшләре булмагач, тугандаш текеләләр янына килеп урнашуы бик мөмкин. Бәлки әле, ул берәр морза даирәсендә булгандыр. Тарихчы А.В.Беляков үзенең «Абызы (хафизы) в московском государстве XVI-XVII веков» дип исемләнгән хезмәтендә[6] тарихи чыганаклардан, аерым алганда, Нугай Урдасыннан Мәскәү дәүләтенә килгән илчелек документларыннан, абызларга кагылган берничә цитата китерә. Шуларның берсе безнең өчен аерата кызыклы булып күренде: *«...приехали, государь, ко царевичю из Болших Ногаев Атай мирзин сын, Исмаил ева роднова брата Ак-мирза а с ним Ак-берди князь да послы Уруса князя и Што-ру-Багатыр, Караходин посол, Кудайберди абыз сеит...»* (РГАДА, ф.127, оп.1, 1586 г., д.1, л.9-10). Әгәр дә биредә безне кызыксындырган Ходайбирде абыз турында

[4] Хәмидуллин Б.Л. Казан ханлыгы халыклары. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2008.
[5] Амерхан Межитов. Тайны Ногая – хана кыпчакского ханства. Самиздат, 2018. *https://avidreaders.ru/book/tayny-nogaya-hana-kypchakskogo-hanstva.html*
[6] Беляков Андрей Васильевич. Абызы (хафизы) в московском государстве XVI-XVII веков. Журнал «Средневековые тюрко-татарские государства». Институт истории им. Шигабутдина Марджани АН РТ. №7, 2015.

сүз барса (моңа бик тә ышанасы килә!), Кадыкай абызның нәсел җепләре Төкле бабага гына түгел, ә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу гәләйһи вәсәлламнең үзенә үк барып тоташа түгелме соң?! Китерелгән цитатадан Ходайбирде абызның сәет булганлыгы ачык күренә. Моннан Кадыкай абызның легендаларга кереп калган бар үзенчәлекләре – тиңдәшсез көчкә ия булуы, дәвалау сәләте аңлашыла инде. Мөгаен, Ходайбирде Төкегә килгәндә яшь егет булмагандыр инде, белемле дин эшлеклесе, суфи булгандыр. «Бер байга килеп урнашкан», – дигән сүзләр аның шул тирәдәге җирләрне биләгән морза яки би карамагына килгәнлеген аңлатадыр.

Абызлар хәрәкәте XVI-XVIII гасырларда Идел буе һәм Урал алды төбәгендә яшәгән төрки халыклар арасында киң тарала. Аның вәкилләре ислам гореф-гадәтләрен һәм мөселман мәгарифен авылларда аерымланып яшәгән мөселман җәмәгатьләре шартларында саклап калырга омтылалар. Алар мөселманнарның үз хокукларын яклап чыгуын алга сөрә. Явыз Иван Казан ханлыгын яулап алган 1552 елдан алып XVIII гасыр ахырында «Әби патша» карары белән Оренбург мөселман Диния нәзарәте оештырылганчыга кадәрге чор – мөселман татарлар тормышында иң катлаулы, авыр вакытларның берсе була. Бу чакларда Россиядә исламның бернинди дә дәүләт статусы булмый, мөселманнар аяусыз эзәрлекләүләргә дучар ителә. Нәкъ шушы вакытта ислам тарафдарлары җәмгыятьләренә лидерлар булып абызлар килә. Абыз (гарәпчә «хафиз» – «Коръәнне яттан белүче» сүзеннән) – дин эшлеклесе, мулла, миссионер, җәмгыятьнең аксакалы. Абызлар хәрәкәте вәкилләре ислам традицияләрен киңрәк җәелдерү һәм саклау, мәгърифәтчелек өчен көрәшкәннәр, мөселманнарның үз хокукларын яклау буенча баш күтәрүләрендә идеологик көч, күп очракта җитәкче буларак катнашканнар. Мондый баш күтәрүләр, әлбәттә, безнең төбәктә дә булмый калмаган. Мөгаен, Кадыкай абыз турындагы риваятьләрдә шундый сугышлар турында сүз барадыр.

Кадыкай абызның Иске Кәкерле белән Яңа Кәкерле авыллары арасында үтерелүе дә чынбарлыкка туры килә кебек. Бу урыннардан элек олы юл – яңа төзелгән Алатырьдан Казанга таба тракт үткән. Гаскәриләрнең шушы юлдан килгәнлеге шик тудырмый. Мин үзем тумышым белән Яңа Кәкерледән. Безнең авылда: «Авылның Иске Кәкерлегә чыгып китә торган җирендә, хәзерге яңа зираттан ерак түгел урында, дин өчен бик көчле сугышлар булган», – дигән хатирә буыннан-буынга күчеп килде.

Унҗиденче гасырның икенче яртысында йомышлы татар-мишәрләрнең безнең якларда үзләренә бирелгән җирләрне рәсмиләштерү документларында урыс чиновниклары бу җирләрнең «на Диком поле» булуларын күрсәткәннәр. Алар әлеге урыннар мәңге буш яткан дип уйлаганнардыр. Әмма, безнең карашка, төбәкне Дикое поле – Кыргый далага әверелдерүче Мәскәү дәүләте үзе була. Һәм ул моны, нигездә, Казан ханлыгын буйсындырган чакта эшли. Уңдырышлы кара туфраклы, яшәү өчен бар яктан да уңайлы урман-дала зонасына кергән төбәкнең моңа чаклы да «Дикое поле» булуына һич тә ышанып булмый. Казан ханлыгы оешканчыга кадәр Иделнең уң ягында кыпчак кабиләләре яшәгәнлеген раслаучы тарихи чыганакларны искә төшерик. Аларның бирелә бик теләп күчмәлектән утрак тормышка күчкән булулары ихтимал. Болгар чорында бу якларда «сувас» кабиләләре рәхәтләнеп яшәгән. Болгар җимерелгәннән соң, алар төньяккарак, куе урманнарга таба күчеп китәргә мәҗбүр булган. Ә унҗиденче гасыр урталарында алар яңадан элеккеге җирләренә кайтып төпләнәләр. Ә менә Казанны

«Кадыкай абыз укулары»ннан бер мизгел

алганнан соң изелә, куркытыла башлаган мөселманнарның бу яклардан Агыйдел елгасы аръягына, Урал буйларына, хәзерге Башкортстан территориясенә күпләп китүләре әле унтугызынчы гасыр урталарына кадәр дәвам иткән.

Язмамны шушы әйтелгәннәргә бер дәлил булган, бер үк вакытта Кадыкай абызга да кагылган истәлек белән тәмамлыйсым килә. Бер очрашуыбызда Иске Кәкерле авылының алда телгә алынган мөхтәрәм кешесе Рифкать ага Иматдинов сөйләгән иде аны миңа.

Заманында Рифкать абый Иске Кәкерле Авыл Советында сәркатип булып эшләгән. Шул елларның берсендә Авыл Советы исеменә Уфадан бер хат килеп төшә. Анда мондыйрак сүзләр язылган була: *«Безнең нәселдә ерак буыннардан килеп ирешкән бер хатирә саклана. Сезнең Иске Кәкерле авылыннан ерак түгел Теке дигән авыл булган икән. Бик зур авыл булган ул, җиде мәчете булган. Авылда тирә-якларга изгелекләре, тылсымлы эшләре белән даны чыккан бер мулла яшәгән. Аны «Абыз» дип йөрткәннәр. Бервакыт ул якларны, шул исәптән, Текене дә Мәскәү патшасы басып ала. Халыкка тиз арада чукынырга, урыс диненә күчәргә кушыла. Безнең борынгы бабаларыбыз аннан качып өлгерәләр. Соңрак аларга Теке авылының тулысынча диярлек тар-мар ителгәнлеге, күп кеше, шул исәптән, теге авыл мулласының да һәлак булганлыгы турындагы хәбәр килеп ирешә. Безнең соравыбыз шул: ул Теке авылы әле яшиме, яшәсә, андагы кешеләр үзләренең тарихын беләләрме?»*

Җавап язган булгандыр Рифкать ага. Авылның әле дә яшәп торуын, Кадыкай абызның якты истәлеге халык күңелендә әле дә булса саклануын язгандыр. Бәлки, нәкъ шул мизгелләрдә аның күңеленә узган тарихны барлау һәм өйрәнү теләге дә килгәндер... ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

Марат Гафаров: «Күп тел белгән кешенең рухи дөньясы баерак»

(Чүпрәле муниципаль районы башлыгы Марат Ринат улы Гафаров белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон әңгәмәсе)

– Сез – Нурлат, Азнакай һәм Балык Бистәсе районнарында җитәкче вазыйфалар башкарган кеше. Димәк, чагыштырырдай тәҗрибәгез бар. Чүпрәле районының төп үзенчәлеге нидә?

– Чүпрәлене Татарстанның көньяк-көнбатыш капкасы, диләр. Районда 52 авыл исәпләнә, алар 19 авыл җирлегенә берләшкән. Барлыгы 20 мең 700 кеше яши. Шуның 56 проценты — татарлар, 43 проценты — чуашлар, 1 проценты — руслар һәм башка милләт вәкилләре.

Азнакай районында нефтьчеләр булгач, социаль мәсьәләләрне хәл итәргә уңайлырак иде. Ә биредә тормыш тулысынча авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, эшкәртү һәм сату белән бәйле. Чүпрәле халкы бик тырыш һәм булдыклы. Безнең бурыч мөмкин булганча авыл хуҗалыгы үсешенә ярдәм итү.

– Кеше саны кимү сезнең төбәктә дә күзәтеләме?

– Бу проблема Татарстанның барлык районнарын да борчый инде. Чүпрәлегә иң якын кала – Ульяновск. Совет чорында анда заводлар төзелә башлаган икән, биредәге халык авыллары белән шунда агылган. Чагыштыру өчен бер мисал китерәм: заманында Иске һәм Яңа Задур авылларында ике меңгә якын кеше яшәгән. Ульяновскида «Авиастар» заводы төзелә башлагач, фатирга, шәһәрдәге эшкә кызыгып, авыл кешеләре шунда күченгән. Анда хәтта чүпрәлеләр генә яши торган урам да барлыкка килгән. Хәзер исә ике авылда яшәүчеләрнең саны йөзгә дә тулмый. Дөрес, элек китүчеләр соңгы ике елда туган нигезләренә кайта башлады, җирләрне рәсмиләштереп, йорт салырга теләүчеләр дә бар. Шулай ук УАЗ заводына, Ульяновск өлкәсе совхозларына да Чүпрәле кешеләре күпләп киткән. Заманында анда яшәү икътисади яктан уңайлырак булган.

Шөкер, соңгы елларда Казаннан, Ульяновскидан кайтып фермерлык белән шөгыльләнүче гаиләләр дә бар. Ринат Айзятов Ульяновскидан гаиләсе белән туган авылы Татар Шатрашанына кайтып фермерлык эшен җәелдереп җибәрде. Бүген исә хуҗалыгында 300гә якын баш терлек асрый, 1600 гектарга якын чәчүлек җирен эшкәртә. Мунчәли авылы егете Марс Хәйретдинов та Казаннан кайтып бәрәңге үстерү белән шөгыльләнә. Ә җирдә эшләргә теләгән кешегә барлык мөмкинлекләр дә бар, тырышсыннар гына...

Кушкуак авылында нибары бер кеше тора. Андагы җирләрне дә Казаннан бер егет алып, бакчачылык белән шөгыльләнмәкче була. Соңгы 2-3 елда халыкның шәһәрдән авылга тартылуын күзәтәм. Авыллардагы элекке йортларны сатып алу турындагы хәбәрләр ишетелә, яңа йортлар салына. Әмма демография мәсьәләсе проблема булып кала. Элек бирედә яшәүче татар гаиләсендә 5-6 бала булса, хәзер, күп дигәндә, өч, уртача ике бала. Бу бик аз!

– Икътисади өлкәдә нинди яңалыклар бар?

– «Государев Амбар» җәмгыяте – Татарстан Республикасының иң алдынгы ашлык кабул итү һәм эшкәртү предприятиеләренең берсе. Ул Яңа Борындык авыл җирлеге территориясендә урнашкан. Икмәк, сөт эшкәртү заводлары, сугым цехы яңа гына булдырылды. Киләчәктә ит эшкәртү (колбасалар) цехы ясарга уйлап торабыз. Каз үстерү юнәлешендә ике фермерыбыз аеруча тырышып шөгыльләнә. Чүпрәле казларын иң тәмлесе, диләр. Беләсезме, ни өчен? Чөнки алар су күрмичә үсә. Районда кечкенә генә Чынлы елгасы ага, күлләр дә күп түгел. Әмма казлар бик тиз сатылып бетә, хәтта Яңа ел бәйрәменә дә калмый диярлек.

Җиләк-җимеш, алма үстерүче «Дуван бакчалары» кооперативы соңгы елларда бик уңышлы эшләп килә. Кооператив житәкчесе Альфред Хәйруллин да заманында, мәктәпне тәмамлагач, дус-ишләренә ияреп Казанга киткән иде. Бездә үскән жиләк-жимешне, алмаларны федераль һәм республика сәүдә челтәрләрендә күреп була. Җиләк-җимештән ясалган төрле кайнатмаларга да ихтыяҗ зур.

Быел исә районга яна инвестор да керде. Алар фермаларны үзгәртеп кору эшенә алынды, тиздән яңа токымлы мөгезле эре терлек кайтарачаклар. Дөрес, күбрәк игенчелек белән шөгыльләнәләр, әмма терлекчелекне дә онытмаска вәгъдә бирделәр. Киләсе елда районыбызда сөтчелек буенча да үсеш булырга тиеш дип уйлыйм. Республикабызда танылган «Цильна» хуҗалыгы да үзенең

уңышлы эшчәнлеген дәвам итә. «Бикчуров Р.А.», «Мәхмүтов И.Ф.», «Низамов А.А.» фермер хуҗалыкларының эшләре дә аерым игътибарга лаек.

Киләсе елда көнбагыш, рапс, борай һәм карабодайга да өстенлек бирергә уйлыйбыз. Карабодайның данлыклы «Каракитә» («Каракитянка») сорты 1988 елда бездә чыгарылганын беләсезме икән? Карабодай – бик яхшы культура, бездәге һәр хуҗалыкта игелә, әмма аңа ихтыяҗ ел да яхшы була дип әйтеп булмый. Шунлыктан киләчәктә карабодай эшкәртү цехын үзебездә төзергә уйлыйбыз. Киләсе елда ул эшләп китәр дип уйлыйм. Элиталы көнбагыш маен да үзебездә җитештерергә ният бар.

Акатуй бәйрәменнән бер күренеш

Районыбыз уникаль табигый мирасы – цеолит ятмаларына бай булуы белән дә үзенчәлекле. Татар Шатрашаны авылы чикләрендә Россиядәге барлык табигый цеолитларның 13,3 проценты тупланган. «Цеолиты Поволжья» компаниясе җитештергән продукция Казакъстан, Беларусь, Бәһрәйн, Согуд Гарәбстаны кебек чит илләргә дә китә. Ул авыл хуҗалыгында, су чистарту җайланмаларында, атом сәнәгатендә, нефть һәм газ химиясендә, төзелештә файдаланыла. Компаниянең җитештерү куәте елына 320 мең тонна әзер продукция тәшкил итә.

Мордовиядәге татар эшкуарлары белән тыгыз элемтәдә торабыз. Аларның ит продукциясен җитештерүдә һәм көнбагыш эшкәртүдә тәҗрибәләре зур. Гомумән, эшмәкәрләрне татар дөньясы белән гел таныштырып торам. Мордовиядән кала, Самара өлкәсе, Чуашстан һәм Удмуртия республикаларында да булдык. Башка төбәкләрдәге милләттәшләребезнең дә эш-тәҗрибәсен өйрәнеп, аны үзебездә файдаланабыз. Хәләл продукция җитештерүне үзебездә дә арттырырга ниятлибез, моңа ихтыяҗ елдан-ел арта.

Район үзәген дә заманча итеп төзекләндерергә уйлыйбыз. Районда урман барлык җирләрнең 2-3 процентын гына алып тора. Бу – Республика буенча иң аз күрсәткеч, шуңа күрә ерганаклар бик күп. Шуларны ныгыту, тирә-ягын яшелләндерү эшен дә башлап җибәрдек. Әлеге урыннар да киләчәктә матур булырга тиеш.

– Чүпрәле төбәге элек-электән җырга-моңга бай. Ул кабатланмас талантлары белән дә танылган...

– Габдулла Рәхимкулов исемендәге җыр фестивален, Зәки Нури исемендәге әдәби премия бирү тантанасын оештырып киләбез. Рафаэль Ильясов, Ринат Таҗетдинов кебек талантларыбызны да онытмыйбыз. Кече Чынлы клубын төзекләндергәч, аңа Ринат Таҗетдинов исемен бирергә уйлыйбыз. Зәки Нуриның туган авылында яңа клуб салынгач, әдипкә багышланган истәлек тактасы куячакбыз. Анда шагыйрь исемендәге аллея да булырга тиеш.

– Зәки ага бик яхшы юморист, кыска, сатирик шигырьләр яза иде. Өстәвенә, бик күп чит ил шагыйрьләренең әсәрләрен тәрҗемә итеп чыгарды ул. Моны бөтен кеше дә булдыра алмый. Дөрес, Язучылар берлеге рәисе буларак, ул күп йөргәндер. Әдәбият аша халыклар арасындагы дуслыкны урнаштыруга үзеннән зур өлеш кертте Зәки ага.

– Туфан Миңнуллин да бирегә бик еш килә торган булган. Атаклы «Мунчәли укулары»на ул нигез салган. Шундагы мәктәпне төзүдә дә аның ярдәме бик зур.

– Татарлар – бөтен милләтләрне дә ярата торган халык. Берәүне дә дошман күрмибез. Биредә чуашлар бик күп яши икән! Мөнәсәбәтләрне ничек корасыз?

– Чуашлар – татарлар кебек үк, бик тырыш, уңган һәм булдыклы халык. Көндәлек тормышта бергә булган кебек, милли бәйрәмнәрне дә бергә уздырабыз. Сабан туенда һәр халык үзенең милли киемнәрен, этнографиясен, гореф-гадәтләрен тәкъдим итсә, чуашларның милли бәйрәме Акатуйны да шул ук рухта үткәрәбез. Моннан тыш, һәр чуаш авылының үзенең милли бәйрәмнәре бар: авыл көннәре, «Петров день», «Троицкие напевы», һ.б. «Троицкие напевы» православие фестивале районыбызның милли брендына да әйләнеп бара. Бу бәйрәмгә күрше төбәкләрдән дә бик теләп киләләр. «Авылым кичләре» – «Уллах касе» фольклор, «Милләтләр дуслыгы» фестивальләре дә уңыш казанып килә. «Хелхем» чуваш халык фольклор ансамбле дә мактауга лаек. Әлеге ансамбль быел 10 еллыгын билгеләп үтә. Шөкер, районыбыз сәнгать коллективларына бик бай. Ә иң мөһиме: биредә яшәүче һәр татар кешесе чуаш телен аңлый, ә һәр чуаш татарчаны яхшы белә. Күбрәк тел белгән кешенең рухи дөньясы баерак, матуррак була.

«Троицкие напевы» православие фестивале

– Бер районнан икенчесенә күчеп эшләгәнсез. Әле бит гаилә дә бар. Төрле районда эшләгәндә алар да Сезнең беләнме?

– Декабристлар кебек йөриләр инде. Һәр районга күчеп килгән саен, алар өчен яңа мохит туа, үзләренә яңа дуслар, танышлар табалар. Кызым Камилә Норлаттагы балалар бакчасына йөрде, Азнакайда мәктәпкә керде. Хәзер ул Казанда программист һөнәрен үзләштерә. Улым да төрле мәктәпләрне күрде, хәзерге көндә Казандагы лицейда белем ала. Биредәге укытучылар «глава малае» дип якламасыннар, өстенлекләр бирмәсеннәр өчен, аны махсус шәһәргә җибәрдем. Ә инде өченче балабыз биредә дөньяга аваз салды.

– Әңгәмәгез өчен рәхмәт, игелекле башлангычларыгызда һәм гамәлләрегездә уңышлар насыйп булсын! ■

Мунчәли – бай тарихлы һәм мәдәниятле авыл

Илмир Измайлов*

ТАССРдагы дүрт җидееллык мәктәпнең берсе Мунчәлидә булган

«Мунчәли укулары»н уздыру 2008 елдан башланды. Дини җыен булып башланып киткән чара быел 15 нче мәртәбә үтә. Аның нигезе Туфан абый Миңнуллин белән очрашудан соң барлыкка килде. Туфан ага исән вакытта Мунчәлигә еш кайта, халык белән бик теләп очраша иде. Менә шул бер очрашу вакытында Мунчәли авылы бик борынгы тарихи авыл, аның бер үзенчәлекле чарасы булырга тиеш, дигән фикерне җиткердем. «Әйе, Мунчәли авылы бит ул заманында төбәгебезнең иң зур мәгърифәт һәм мәдиният үзәге булган. XX гасыр башында ук мәдрәсәдә арифметика һәм география укытылуы, ТАССРдагы тәүге дүрт җидееллык мәктәпнең берсе Мунчәлидә ачылуы, әлеге мәктәптә Шәрәф Мөдәррис белән Зәки Нури кебек күренекле шәхесләребезнең белем алуы гына да ни тора! Шагыйрь Роберт Рәкыйпов та биредә директор вазыйфасын башкара. 1942 елда Ржев шәһәрен бомбага тоткач, ятим балалар йортының Мунчәлигә күчерелүе – тарихыбызга алтын хәрефләр белән язылырдай факт. Мин Сезнең белән, һичшиксез, килешәм, Мунчәлинең үзенең бер бәйрәме булырга тиеш. Ул чара халкыбызны, милләттәшләребезне берләштерә торган, тирә-якта танылган, көтеп алынган, якташларның, дусларның очрашу урынына һәм районның брендына әйләнерлек булсын иде», – дип, хәер-фатихаларын бирде Туфан ага. Чарада аны һәр елны искә алабыз. Ул төзергә ярдәм иткән мәктәп бинасы диварында драматургның барельеф белән эшләнгән мемориаль тактасына чәчәкләр салабыз, аның рухына дога кылабыз.

Россиядә җиде Мунчәли авылы бар

Россиядә бүген Самара, Түбән Новгород, Пенза һәм Новосибирск өлкәләрендә җиде Мунчәли авылы бар. Элеккеге картларның сөйләвенә караганда, бу авыллар-

---

* Илмир Расыйх улы Измайлов – Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш, финанслар һәм авыл хуҗалыгы буенча урынбасары, Чүпрәле районының Мунчәли авылы тумасы, авылның якташлар оешмасы рәисе.

Туфан Миңнуллин «Мунчәли укулары»ның мөхтәрәм кунагы иде.

га килеп утыручы ерак бабаларыбызның барысы да Түбән Новгород өлкәсендәге Мочәли елгасы буена урнашкан Иске Мунчәли авылыннан булган. Тарихи документларга килсәк, Сембер губернасы гыйльми архив комиссиясе басмасында 1665-1667 нче елларда Мунчәлидәге 23 йорттан ясак алынуы күрсәтелгән документлар бар. «Татар энциклопедиясе» сүзлегендә исә Мунчәли авылының Казан ханлыгы чоры авыл атамаларын санаган исемлектә булуы әйтелә. Димәк, Мунчәли авылының 500 елдан артык тарихы бар.

Төрле риваятьләрдә Мунчәли авылына нигез салган нәселләрнең берсе башында Тәкәш бабаның торуы билгеле. Субаевлар нәселеннән булган Тәкәш бабай – 1565 елда Касыйм ханлыгында, «Мещерские леса», «Мещерские болота» исеме белән тарихка кергән Мишәр кара урманнары, сазлыклары эчендә урнашкан бер утарда дөньяга килеп, 1605 елда сазлыктан чыгып, хәзерге Татарстандагы Мунчәли авылы урнашкан җиргә җитеп, шунда тукталып калган кеше. Алты гаилә килә алар. Тәкәш баба вафатының елы безгә билгеле булмаса да, Мунчәлидә җирләнүе, аның улы Ирәйнең (Гәрәй) 1615 елда Мунчәлидә тууы билгеле. Гәрәйнең улы – Тәкәшнең оныгы Сыбай (Субай) 1662 елда Мунчәлидә туган.

Шәхесләргә шәрехләр

Мунчәли – Ватан сугышы каһарманы Нурулла Фазлаевны һәм Социалистик Хезмәт Герое Абдулла Сабирҗановны биргән авыл. Күренекле дәүләт эшлеклесе,

Республика Прокуроры һәм Конституция суды рәисе Сәйфихан Нәфиев, олуг галим, филология фәннәре докторы һәм шагыйрь Нурмөхәммәт Хисамов, рационализатор-уйлап табучы Инкыйлаб Әмирханов, мәшһүр җырчы Венера Шәрипова, Татарстанның халык артисты Алсу Гайнуллина, Татарстанның атказанган артисткасы Алсу Әбелханова, шагыйрь Рәмис Аймәт тә – Мунчәли авылыннан. Биредән чыккан йөздән артык якташыбыз төрле оешмаларга җитәкчелек итәләр.

Иллешәр ел кайтмаган авылдашлар кайта башлады

Еллар уза торды, әлеге бәйрәм төбәкара статус алды. Быел Мунчәлигә Россиянең 8 төбәгеннән дин әһелләре, иҗтимагый эшләр башкаручы активистлар, балалар килде. Ә иң әһәмиятлесе – кунаклар, бездән күреп китеп, үзләрендә дә шуны ук үткәрәләр. Кызганыч ки, Сабан туен уздырырга барлык авылларның да мөмкинлеге юк. Ә менә дини җыеннар форматындагы бәйрәмнәрне һәр авылда үткәрергә мөмкин. Бирегә якташлар, туганнар, авылдашлар кайта, очраша. Хәтта иллешәр ел кайтмаган авылдашлар кайта башлады. Кайберләренең инде монда туганнары, нигезләре юк, әмма җир-су тартканга кайталар. Ата-бабаларын искә алып, рухларына дога кылып, туган нигез урыннарын карап, мәктәп елларын, балачак сукмакларын искә төшереп китәләр.

Шәкертләр бәйгесе – «Гыйлемпиада»!

Соңгы елларда балаларга аеруча игътибар бирә башладык. Төрле мәчет-мәдрәсәләрдә дин сабакларын өйрәнгән балаларны бирегә җыеп, шәкертләр бәйгесе – «Гыйлемпиада» исемле конкурс оештырабыз. Балалар гыйлемдә ярыша, уку вакытында аңлап бетермәгән нәрсәләргә төшенә. Көннең икенче яртысында Шәкертләр Сабан туе уза, ә кичен исә авыл бәйрәме татар эстрадасы артистлары катнашындагы концерт белән дәвам итә. Шулай итеп, «Мунчәли укулары» көн дәвамында бара торган дини, милли, әдәби-мәдәни чарага әйләнде.

Авыл яңа сулыш ала

Шушы чараларны үткәрә башлагач, якташларыбыз, мәрхәмәтле, изге җанлы шәхесләр дә авылга карашларын үзгәртеп, төрле яклап булыша башладылар. Әйтик, кемдер коеларны чистартып төзекләндерсә, олы йөрәкле ханым Дания Әсхәт кызы Тулованың матди ярдәме белән, мәдәният йорты бинасы заман таләпләренә туры китереп яңартылды. Моннан тыш, Мунчәли урамнарына 3 километрдан артык аралыкка таш салынды, ике автомобиль күпере, бер җәяүлеләр кичүе тулысынча капиталь төзекләндерелде, авыл аша уза торган Буштерлә елгасы агачлардан чистартылып, ярлары күтәртелде, зират капкасы яңартылды, мәчет бинасына тулысынча капиталь ремонт үткәрелде.

ИншәАллаһ, «Мунчәли укулары» киләчәктә дә дәвамлы булыр дип өметләнәм. Әлеге чараларны үткәрү өчен мәчет каршындагы мәйдан инде кечкенә. Шуңа авыл уртасында бер заманча парк булдыру, авылны тулысынча төзекләндерү, яшьләрне авылга тарту, дини-әхлакый тәрбияне ныгыту хыяллары белән яшибез. Әлеге эшләрне башкарырга Аллаһы исәнлек-саулык, озын гомерләр бирсен иде. ■

Ильяс хәзрәт Җиһаншин: «Өстебезгә бик зур җаваплылык алдык»

Без, татарлар, җир йөзендә бик күп булсак та, башка күпсанлы, мәсәлән, урыс яки инглиз халкына карата без – азчылык. Безнең кебек милли һәм дини азчылыкны тәшкил итүче халыкка, үзебезнең милли үзенчәлекләрне, үз динебезне вә мәдәниятебезне саклау бигрәк тә мөһим. Аеруча әһәмиятле булган бу мәсьәләләргә татар имамнары вә зыялылары, дәүләт җитәкчеләре җитәрлек игътибар бирмәсә, халык югалыр.

Совет елларына гына сылтап булмый...

Шагыйребез: «Сөй халыкның дөньясын!» – дип милләтебезне якларга һәм сакларга, ягъни аның яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен, телен, мәдәниятен, әдәбиятын һәм сәнгатен кабул итәргә, буыннан-буынга күчеп килгән традицияләрне, гореф-гадәтләрне саклап яшәргә васыять итеп калдырган. Үз халкыңнын дөньясын яратыр өчен, иң элек, аны белергә, шул мохиттә үсәргә, тәрбияләнергә тырышырга кирәк. Халыкның язылган һәм язылмаган кануннары, әдәпләре, гореф-гадәтләре кечкенәдән баланың канына, аңына сеңдерелергә тиеш, шул рәвешчә һәр милләтнең, халыкның үз мәдәнияте, милли йөзе барлыкка килә. Бер үк вакытта совет чорында булган милли-дини тәрбиядәге тайпылышлар эзен бетерү, ягъни урта һәм өлкән буын вәкилләре арасында да агарту эшләрен киң алып барырга кирәк.

Һаман совет елларына гына сылтап булмый, әлбәттә, бу яраклы эш түгел. Хәзерге заман яңа шаукым алып килде. Соңгы елларда яшьләрнең күпләп шәһәрләрдә төпләнеп калуы, шәһәрләрдә генә түгел, авыл мәктәпләрендә дә ана теле дәресләренең кыскартылуы, укытылмавы, балалар аз санлы булган мәктәпләрнең ябылуы, озак еллар ил күләмендә алып барылган атеистик тәрбия, авыл өчен имамнарның тәрбияләнмәве, мәчет-мәдрәсәләрнең җитәрлек эшләмәве – берничә яшь буынны дин исламнан, татар теленнән, әдәбиятыннан, милли мәдәнияттән читләштереп өлгерде. Соңгы елларда, кызганыч ки, татар балалары бер-берсе белән рус телендә аралаша башлады, әби-бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләргә игътибар кимеде. Элек гөрләп торган авыллар бетүгә

таба бара, авылларда инде элек-электән уздырыла торган халык бәйрәмнәре, өмәләре үткәрелми, яшьләр мәчеткә йөрми.

ИншәАллаһ, яңадан торгызылган гореф-гадәтләребез дә җитәрлек. Монда шул ук гошер сәдакасын җыеп, аннан мохтаҗларга өлеш чыгару, зиратларга барып өлкәннәрнең каберләрен барлау, җыеннар уздыру кебек дини дә, милли дә булган матур йолаларыбызны мисал итеп китерергә була. Бүгенге авыл җыеныбыз да моңа бик матур мисал.

Татар түбәтәен салмаган

Дин әһелләре гомер-гомергә телне, гореф-гадәтләрне саклаучылар булган. Әгәр без милли мохитне, рухны диннән аерабыз икән, аның киләчәге юк. Ислам динебез – бу дөньядагы иң изге сыйфатларны сугаручы илаһи бер чишмә. Алай гына да түгел, ул, барлык халыкларның юлын яктыртучы нур итеп, аларны караңгылыктан яктылыкка чыгару өчен җибәрелгән. Динсез кеше – юлсыз кеше, динсез милләт – юлсыз, киләчәксез милләт. Динле булу – зур хезмәт ул, көндәлек тырышлык, бертуктаусыз тәнеңне һәм җаныңны пакьлектә тоту дигән сүз. Дин кешене әхлакка, вөҗданга, иманга, сафлыкка, матурлыкка, тынычлыкка илтә. Изге ана телен төп терәгеннән – динебез ярдәменнән дә мәхрүм итмик, мөхтәрәм җәмәгать. Милләтне, дин исламны савыктыру өчен, халыкның милли һәм дини аңын уятырга, рухын ныгытырга кирәк. Үзенең кемлеген — кем нәселеннән, нинди нәселдән, кавемнән булуын белгән кеше диненнән, теленнән, милләтеннән беркайчан да ваз кичмәячәк, чит тәэсирләргә бирелмәячәк.

> **«Әби-бабаларыбыз, бүтән халыктан аерылып тору өчен, яулыкны да үзләренчә бәйләгәннәр, түбәтәйләрен дә салмаганнар, сакалны да матур итеп кыркып-кыскартып, үзләренчә күркәм-матур йөрткәннәр.**

Бу юлда маяк булып үзебез торырга тиеш, җәмәгать! Әби-бабаларыбыз, бүтән халыктан аерылып тору өчен, яулыкны да үзләренчә бәйләгәннәр, түбәтәйләрен дә салмаганнар, сакалны да матур итеп кыркып-кыскартып, үзләренчә күркәм-матур йөрткәннәр. Ул вакытларда: «Татарның башта башы төшә, аннан соң гына түбәтәе», – дигән әйтем йөргән. Никадәр горурлык һәм үз-үзеңне хөрмәт итү бар бу гадәттә. Татар кешесе элек түбәтәен бер дә салмаган. Ә бу гадәт әле дә бетмәгән бит, аны тагын да яңартырга гына кирәк. Әгәр без онытылган, ташланган традицияләребезне көндәлек тормышка яңадан кайтарсак, балаларга шуны өйрәтсәк, яхшы булыр иде, чөнки үз халкының рухи һәм матди мирасын сакламаган

«Мунчәли укулары»нда катнашучылар

милләт беркайчан да алдынгы була, үткәнен, ата-бабай мирасын кадерләп тотмаган халык берничек тә алга бара алмый.

Үз милләтенең үзенчәлекләре, дине, теле, киеме, бәйрәмнәре, ризыгы белән горурлана белмәгән адәм баласы тулы канлы булмый. Шуның өчен гаиләдә, мәдрәсәдә, мәктәптә, гомумән, татарлар яшәгән һәрбер мәхәлләдә тәрбия эшен алып барганда бу турыда бер дә онытырга ярамый.

Мәхәллә системасы – милләт үсешендә яңа чор

Әйе 21 нче йөзне мәгълүмат гасыры диләр. Замана бик нык үзгәрде. Безнең заман татар-мөселман өммәтенә яңадан-яңа таләпләр куя. Без, әлбәттә, гасырлар буенча килгән дини белем бирү традицияләребезне саклап, замана казанышларын кулланып, милли вә дини тормышыбызны, яшәешебезне, алга омтылышыбызны баетырга тиешбез. Әгәр без татар-мөселман өммәтебезнең яшәеш кырын сугарып, игеп тормасак, дини һәм милли рухыбыз сүнәчәк-сүреләчәк.

Бүген, Аллаһыга шөкер, моның әһәмиятен аңлау бар һәм милләт үсешендә яңа чор күзәтелә. Татар милли-дини яшәеш системасы, ягъни мәхәллә идеологиясе дә бүген акрын-акрын Русия төбәкләренә тарала башлады. Бу уңай агымнарны нәтиҗәле итәр өчен, өлкәннәрнең тәҗрибәсе, яшь буынның бердәм тырышлыгы сорала. Аллаһыга шөкер, яшьләргә милләт, дин эшләрендә юл бирү, халыкны дини вә мәгърифәти агарту юнәлешендә тырышлыклар куябыз. Шунысы шатландыра: бу юнәлештә без ялгыз гына эшләмибез. Мондый чаралардан Чистайда – Мөхәммәдзакир Чистави укуларын, Тәтеш районындагы Әтрәч укуларын, Мәчкәрә укуларын, Ульяновскида – Кулаткы укуларын, Зәйдә – Таҗетдин Ялчыгол укуларын, шәркыят белгече Равил Үтәбәй-Кәримине искә алу чараларын атый алабыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) әйтә: «Кем исламда күркәм бер эшне башлап җибәрде исә, башлаучысына да, шуны дәвам итүчесенә дә өзлексез әҗерләре булачак», – ди. Әмин!

Болгар чорыннан башлап татар авылларында бер яки берничә мәхәллә, һәр мәхәлләнең исә аерым мәчете, имамы, мәзине булган. Ә кайбер авылларда аерым мәдрәсәләр дә эшләгән. Ата-бабаларыбызга бердәмлекне сакларга һәм үзара мөнәсәбәтләрне ныгытырга, социаль институт буларак, мәхәллә системасы ярдәм иткән. Бу милли-дини үзидарә системасы Россия империясендәге татар халкына тулы канлы җәмгыять булып яшәргә, икътисади-мәдәни бәйсезлекне сакларга, шул ук вакытта ватанының тугры балалары булып калырга мөмкинлек биргән. Октябрь инкыйлабыннан соң беренче декретлар чыккач (аеруча ЗАГС оештыру декреты), мәхәллә институты әкренләп юкка чыгарыла. Ул заманда мәхәллә урынына Советлар оештырыла. Совет чорында мәхәллә системасы бетерелү татарның дини һәм милли позицияләрен нык какшатты.

Хәзерге вакытта мәхәллә – татар авылларындагы, татарлар яшәгән шәһәрләрдәге дини оешмалар. Аларның үзәге булып җирле мәчетләр тора. Без мәхәллә системасының күпгасырлык эшчәнлегенә таянып, хәзер тулыканлы иҗтимагый үзидарә системасын булдыру зарурлыгы өлгереп җитте дип саныйбыз. Хәзерге заман мәхәллә системасын торгызу һәм үстерү мәсьәләсен Бөтеньдөнья татар конгрессы көн кадагында тотарга тиеш дип уйлыйбыз һәм ул бу юнәлештә эзлекле карарлар кабул итәр, аларны тормышка ашырырга бергәләп хезмәт куярбыз дип ышанабыз.

Үәссәләмәгаләйкүм үә рахмәтүллааһи үә бәрәкәтүһү. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

Үрдә

Миләүшә Талипова

Мөхәммәтгали Арсланов. 2016 ел

Ул биектән аска карап тора. Моннан барысы да уч төбендәгедәй күренә икән. Яшеллек, хозурлык! Әнә тегендә җырлап-уйнап үскән чишмә буйлары. Казлар-үрдәкләр чупырдашкан буа. Еракта – шаулый-шаулый куерган урман. Бер якта – чиксез даланы ерып офыкка кадәр сузылган юл. Аның ахыры күренми. Икенче якта – һәрбер юлчы табачак сыену урыны. Анда – әтисе Гыйльмегали, әнисе Нәгыймә, туган-тумачасы... Ул аларны яд итәргә кайтты.

Дөньяның үзәге бу. Түмерҗә. Актаныш төбәге. Кеше өчен туган нигез, туган йорт, кендек каны тамган җир генә дөньяның үзәге була ала.

Авылны XVII-XVIII гасырлар чигендә Нугай Урдасы хакиме Гәрәй хан торыннары нигезләгән, диләр. Арслановларның шәҗәрәсе дә, тарихи чорларны, соңгылларны кичә-кичә, шушы нәселгә барып тоташа: Гәрәй хан – Чарлук Диван – Чарлук углы Уязы Гәрәй илүе – Йабанчы би – Кунакхуҗа – Мәмдәле – Әҗкә – Бакыткилде – Бимәт – Бикмәт – Күзәй... Әйткәндәй, Күзәй (Хөсәен, документта Кузюмка Бекмянин[1]) – 1701 елда патша Алексей Михайловичтан Түмерҗә-Такталачык җирләрен биләү өчен грамота алучыларның берсе. Ары таба: Күзәй – Уразмәт – Әсәкәй – Сәйфулла – Насыйбулла – Арслангали – Гыйльмегали – Мөхәммәтгали...

Татарстан Җөмһүрияте Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Халыкара төрки академия академигы, озак еллар буе Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеген җитәкләгән галим, сәнгать фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Мөхәммәтгали (Гали) Гыйльмегали улы Арсланов 1947 елның 6 октябрендә туа. Түмерҗә – 50-60 йорттан торган кечкенә авыл. Шуңа күрә аңа сигезьеллык мәктәпне – күрше Теләкәйдә, урта мәктәпне Такталачыкта укып тәмамларга туры килә.

Үскәндә ул да, ихтимал, очучы яисә капитан булырга, күкләрне, суларны гизәргә хыяллангандыр, үзенә, ким дигәндә, колхоз рәисе урынын тәгаенләп куйгандыр. Әмма бер вакыйга аны бөтенләй «харап итә».

– Тәүге спектакльне 4 нче сыйныфта укыганда, Такталачык авылына барып карадым, – дип искә алачак ул соңрак. – Әлмәт театрының «Ул кайтты» драмасы иде. Әнгам Атнабаев әсәре буенча. Артистларның исем-фамилияләренә кадәр истән җуясым юк: Барый Гатауллин, Әхмәт Галиәкбәров, Камилә Игъламова, Рәйсә Гобәйдуллина, Камил Сәетгәрәев…

[1] ЦГИА РБ, 2 нче фонд, 2 нче тасвирлама, 473 нче эш, 66 нчы бит.



Әлмәт театр студиясендә укыган чак. Сулдан уңга: Ә.Әмирханов, Д.Кузаева, М.Арсланов. 1965 ел

Шул сәгатьтән кечкенә Галигә театр җене кагыла: акрынлап үзешчәннәр концертларында күренгәли, җырлый, бии, шигырьләр сөйли башлый. Озакламый баянны да кулга ияләштерә: элгәре киреләнеп, яшелле-күкле тавыш чыгарып маташкан инструмент, үҗәт холыкка каршы тора алмыйча, бирелә – бармак орынуга, искиткеч аһәңнәр тарата башлый. Ямьле хисләрдә янып, милли моңнар, милли рух белән сугарылып үскән җилкенчәк алдында миллион юлдан берәү генә кала: татар халкына, татар сәнгатенә хезмәт итү. Юк, ул вакытта, билгеле, аның хыял-максаты мондый ук яңгыравык булмый әле. Анысын отыры язмыш үзе шулай борып куячак. Әлегә ул бары тик көнкүрешенә матурлык өстәргә, гомерен сәнгатьле итәргә генә тели.

Беренче тапкыр авылдан чыгып киткән чагы да һаман хәтерендә, билгеле: иңнәрдә – апасыннан калган плащ, дымлы уч төбендә – әнисе күрше әбекәйдән бурычка сорап торган юл акчасы (пенсияседер, мөгаен)... Атаклы режиссер Габдулла Йосыповның Әлмәттә театр студиясе оештыруын ишеткән үсмер, һич икеләнмичә, шунда юнәлә. Рәхәтләнеп баштанаяк яңа дөньяга чума, чалкан ятып, иҗатта йөзә. Дөрес, кырыс чынбарлык аны җәһәт кенә айныту җаен таба: Ватан алдындагы бурычыңны түлә, ди. Гали өч ел буе (1966-1969) кирза итек кия, башта – Мәскәүдә, аннары Чиләбе өлкәсенең Каргалы шәһәрендә хезмәт итә. Әмма көндәлек солдат тормышы, бертуктаусыз муштра да күңеленә кереп оялаган гүзәл коткыны баса алмый. «Дембель билеты»н кулга төшерүгә, ул туп-туры туган ягына кайта һәм... Актаныш комсомол комитетына инструктор булып урнаша.

– Анда да эшем сәнгать белән бәйле иде, – ди тагын үзе.

Хәер, шушы урында янә бер хатирәне яңартмый калырга ярамый. Яшь кеше беренче хезмәт хакына яхшы кәчтүм-чалбар, күлмәк, ялт иткән туфли алып кия, өс-башын бөтәйтә. Ишек бусагасында кияү егетедәй фырт улын күреп, Нәгыймә абыстай күңеле тулудан елап җибәрә...

– Берничә елдан соң, Казанда Ленинград мәдәният институтының филиалы (хәзерге Казан дәүләт мәдәният институты) ачылуын ишеткәч, шунда киттем, – дип искә төшерә галим. – Курс җитәкчесе профессор Ширъяздан ага Сарымсаков һәм ассистент Роберт Батуллин (булачак халык язучысы, аксакал Рабит Батулла) кул астында дүрт ел укып, диплом алуга ирештем.

Бу вакытта Гали Арсланов Габдулла Тукай яшен тутырган була инде. Тырышып туплаган теоретик белемнәрен практикада тормышка ашырыр өчен, ул яңадан Актанышка юл тота. Халык театры режиссеры вазыйфасында җиң сызганып эшкә керешә, бер-бер артлы Аяз Гыйләҗевнең «Көзге ачы җилләрдә», Әнгам Атнабаевның «Мәхәббәт турында җыр» пьесаларын сәхнәләштерә. Әлеге спектакльләрне гади тамашачы да, белгечләр дә яратып кабул итә, Актаныш театры төрле конкурсларда, смотр концертларында катнашып җиңү яулый, данлана.

Гадәттә, адәм заты, ниндидер бер дәрәҗәгә җиткәч тә, басынкылану ягын карый: шөгыль бар, абруй бар, акчасы тамып тора, дигәндәй... Димәк, нигә артыгын изаланырга, тырышырга, эзләнергә?! Дөресен әйткәндә, бернинди дәрәҗәгә ирешмичә дә мондый фикердә нык торучылар хәттин ашкан. Гали Арсланов исә башка юл сайлый. Режиссер эшенең зурлыгын аңлапмы, шул турыда дөньяга оран салырга теләпме, әллә бу һөнәрнең һәммә нечкәлекләренә төшенергә омтылыпмы, аны тарихи яссылыкта тикшерергә, өйрәнергә уйлапмы, 1975 елда ул Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага керә.

Аның әлеге адымын тулаем бәһаләр өчен игътибарны шуңа юнәлтик: бу, беренчедән, театрны драматурглар тота дип саналган чор, анда режиссер роленә бик аз әһәмият бирелә; икенчедән, Урта Идел буенда сәнгать, шул исәптән, театр, бигрәк тә милли театр теориясе һәм тарихы буенча белгечләр юк дәрәҗәсендә була.

Гали Арсланов шушы көннән гомерен фәнгә багышлый.

Ихтимал, әлеге көннән ул Түмерҗә Галиеннән олпат Мөхәммәтгали Арслановка әверелә башлыйдыр.

Аспирантурада аның белән бергә укыган, аннары институтта эшләгән галим Рәшит Ягъфәров бер мәкаләсендә болай дип яза: *«Мөхәммәтгали әфәнде... баштан ук фәнни эшнең «мөгезеннән алды». Баян ага Гыйззәтнең яраткан шәкерте иде. Көн-төн китаплар өстендә утырды, архивларда казынды, сәнгать кешеләреннән истәлекләр җыйды һәм өч ел дигәндә артист, режиссер Хөсәен Уразиков иҗаты турында кандидатлык диссертациясен тәмамлап та куйды[2]. Аны яклыйм дип ничәмә-ничә еллар Мәскәү юлын таптады, чөнки Казанда сәнгать буенча яклау советлары юк иде. Аны яклагач, фәнгә тагын да тирәнрәк чумды, «Татар театры режиссурасы эволюциясе (1906-1941)» дигән тема буенча эзләнүләрен дәвам итте. Аны тәмамлагач, янә Мәскәү юлларын таптап, анда докторлык диссертациясен яклауга иреште[3]. Шул фәнни эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, «Хөсәен Уразиков» (Казан, 1986) һәм «Татар режиссура сәнгате» дигән ике монографик хезмәт (Казан, 1992, 1996) бастырып чыгарды. Соңгы ике китап татар режиссурасы тарихының 1906 елдан 1958 елга кадәрге чорын үз эченә ала. Хәзер Мөхәммәтгали Арсланов татар театры режиссурасының 1956 елдан бүгенге көнгәчә тарихын язу белән мәшгуль».*

Габдулла Тукайның 125 еллыгына багышланган конференциядә. Төркия, Анкара. 2011 ел

Алга китеп әйтик: Рәшит Ягъфәров телгә алган хезмәт, «Татар режиссура сәнгате (1957-1990)» дип исемләнеп, 2002 елда дөнья күрәчәк һәм, аңарчы ба-

[2] Мөхәммәтгали Арсланов «Хөсәен Уразиков иҗаты һәм татар сәхнә сәнгате. 1930-1940 нчы еллар» дигән темага кандидатлык диссертациясен 1984 елда яклый. – *М.Т.*
[3] Галим, 1993 елда «Татар театры режиссурасы эволюциясе (1906-1941)» темасына докторлык диссертациясен яклап, сәнгать фәннәре докторы исемен ала. – *М.Т.*

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гыйльми советы әгъзалары. Уңнан икенче (баскан) – М.Арсланов. 2015 ел

сылган «Татар театры режиссурасы эволюциясе (1906-1941)», «Татар режиссура сәнгате (1941-1956)» җыентыклары белән бергә, гаҗәеп зур фәнни полотно хасил итәчәк.

Бу эшнең барча авырлыгын автор үзе генә белә торгандыр: эзләнгән кеше аерым спектакльләрнең куелу тарихы, актерлар уены турында матбугат битләрендә азмы-күпме хәбәр яисә белешмә очратырга мөмкин әле, әмма режиссер эше хакында кайдан, нинди мәгълүмат табарсың? Кем өйрәнгән, кем теркәп калдырган аны? Шуңа күрә галимгә Мәскәү һәм Ленинград архивларында, музейларда актарынырга, төрле кешеләр белән очрашып сөйләшергә, алардан хатирә-истәлекләр җыярга кирәк була. Еллар зилзиләсендә туздырылмыйча, исән-имин калган язмалардан, фотосурәтләрдән, аерым детальләрдән чыгып, режиссер һәм аның иҗатташлары (рәссамнар, композиторлар, актерлар) эшен җаны аша үткәреп, спектакльне тулаем тергезергә, күз алдына бербөтен итеп бастырырга туры килә. Бик күп белгечләр искәргәнчә, Мөхәммәтгали Арсланов булган материалларны коры анализлап кына калмый, эзләнү-тикшеренү нәтиҗәләрен, үзенең табышларын матур әдәби тел белән тасвирлап, иҗади сурәтләп тә бирә.

Фәннәр докторы дәрәҗәсен алгач, аңа Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының сәнгать бүлеген җитәкләүне тапшыралар. Монда ул 2016 елга кадәр, ягъни лаеклы ялга киткәнче хезмәт куя: фәнни тикшеренүләр алып бара, аспирантлар әзерли, милли театрга, иҗат әһелләренә багышланган конференцияләр, юбилей кичәләре оештыра, һәммә чараларда үзе дә актив катнаша, чыгышлар ясый.

Мөхәммәтгали Арслановка әле аспирантлык чорында ук остазы Ширъяздан Сарымсаков чакыруы буенча Казан дәүләт мәдәният институтында ике курс студентлар укытып чыгару бәхете тия. Сәхнә яуларга алгысынган яшь-җилкенчәкне алар икәү бергә режиссура, актерлык осталыгы серләренә төшендерә. Галимлек янына мөгаллимлек тә өстәлә. Берникадәр вакыт өзелеп торганнан соң, туксанынчы еллар башында ул яңадан бирегә (үзенә дә белем биргән газиз йортка) әйләнеп кайтачак, татар мәдәнияте турында лекцияләр укыячак әле.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының сәнгать бүлеге. 2007 ел

Мөхәммәтгали Арслановның тагын бер гаять җаваплы вазыйфасын билгеләп үтү зарур: ул, фикердәшләре белән бергә, 1993 елда «Актаныш» якташлык җәмгыятен төзеп, 2012 елга чаклы аның рәисе (президенты) булып тора. Бу хакта бер мәзәк кенә вакыйга да бар. Туксанынчы елларда Актанышта җәмгыятьнең күчмә утырышы уздырыла. Кичке мәҗлестә сүз алган рәис, фикерен түгәрәкләгәнче, илбашы Минтимер Шәймиевкә (якташлар бит) мөрәҗәгать итә:

– Сез дә – президент, Минтимер ага, мин дә – президент. Нишләрбез икән?

Җөмһүрият башлыгы кычкырып көлеп җибәрә дә:

– Сыешырбыз, – ди.

Мөхәммәтгали Арсланов – сәнгатьнең байтак тармагына йогынты ясаган күпкырлы шәхес. Галимнең хезмәт җимешләрен мәдәният, әдәбият әһелләре, журналистлар, тарихчылар да үз итә, китапларыннан, монографияләреннән татар театры тарихы мөгаллимнәре, халык театрлары һәм драма коллективлары да файдалана.

Фән (иҗат кебек үк) – вак эш. Аның нәтиҗәсе беркайчан да түккән көчкә, куйган тырышлыкка бәрабәр булмый. Айлар, еллар буе архивларда, китапханәләрдә казынуның әҗере еш кына 5-10 битлек мәкаләгә сыешырга мөмкин. Берни тапмыйча, ниятеңә бөтенләй ирешмәгән чаклар да сирәк хәл түгел. Мөхәммәтгали ага – татар сәхнәсенә багышланган 1000нән артык фәнни һәм фәнни-популяр язма авторы. Алар арасында, бая телгә алынганнардан тыш, «Режиссер Ширъяздан Сарымсаков» (Казан, 2004), Хөсәен Уразиков шәхесен һәм иҗатын ачкан «Актер. Режиссер. Драматург. Педагог» (Казан, 2006) сыман саллы-саллы басмалар, татар театрының Ильяс Кудашев-Ашказарский, Вәлиулла Мортазин-Иманский, Мохтар Мутин, Кәрим Тинчурин кебек алтын баганаларына аталып язылган мәкаләләр дә бар. «Шәхесләр» сериясендә дөнья күргән «Габдулла Кариев» җыентыгы (Казан, 2011) да аерым игътибарга лаек. Күренекле артист һәм режиссерга кагылышлы бихисап материалдан торган әлеге китапның төзүче-авторы шулай ук Мөхәммәтгали Арсланов.

Арслановлар гаиләсе. 2013 ел

Ул бүген дә, лаеклы ялда кәеф-сафа корып утыру форсаты чыгуга да карамастан, эзләнүләрдән, фәннән, эштән бушанмый: әлегәчә татар театры тарихын барлый, милли сәнгатебезнең бүгенгесен күзәтә, киләчәген күзалларга омтыла. Галим, беренче чиратта, үзе төзеп, 2015 елда «Заман» нәшриятында бастырган «Татар театры» энциклопедик сүзлек-белешмәсен тулылындыру белән мәшгуль. Анда – халкыбызның системага салынган мәдәни байлыгы, татар театрына бәйле шәхесләр, аларның иҗатлары, мәдәниятебездәге урыннары... Шуңа өстәп, һәркемне гомер буе озата барган «Кем мин? Кайдан? Кая барам?» сорауларына җавап табарга омтыла: җентекләп туган төбәген, нәсел-нәсәбен, шәҗәрәсен өйрәнә. Бу темаларга багышланган язмалары матбугатта да очрый.

Аңа бүген 75 яшь. Үзе:

– Кай арада?! – дип гаҗәпләнә. – Югыйсә кичә генә әле...

Әйе, бүген ул 75 еллык биеклектән карап тора. Моннан барысы да уч төбендәгедәй күренә икән: яланаяклы балачак та, Актаныш комсомолы да, мәдәният институты да... докторлык та, профессорлык та... том-том китаплар да. Барысы, барысы! Әтисенең кәгазьләре арасында тәгәрәп үскән оланнар – Азат белән Алмаз – хәзер ир урталары инде. Икесе дә башлы-күзле. Икесе дә урында. Ил-көнгә хезмәт итәләр. Шөкер, җәмәгате дә янында, исән-сау. Ни кирәк тагы?!

Күз алдында – даладай киң тормышны ярып узган гомер юлы. Офыкка кадәр. Аның ахыры юк әле. Чалбар балагы нәрсәгәдер эләктеме, дип, артына борылган иде, берни тапмады, берни күрмәде. Ишетте генә:

– Бабай, Дөнья, чыннан да, түгәрәкме?

Күренекле галим һәм остаз Мөхәммәтгали ага Арсланов күптән түгел үзенең күркәм гомер бәйрәмен – 75 яшь тулуны билгеләп үтте. Аны ихластан котлап, саулык-сәламәтлек, иминлек, тигезлек белән хәерле озын гомер һәм игелекле олы хезмәтендә уңышлар теләп калабыз! ■

Без – Иманкол бабай оныклары

Ирфан Халитов

«Мунчәли укулары»нда катнашучылардан бер төркем

*«Мунчәли укулары» вакытында шәҗәрәләргә багышланган зур күргәзмә оештырылган иде. Иң зур шәҗәрә Халитовлар нәселенеке булып чыкты. Анда 300дән артык кешенең исеме бар. Хәзерге вакытта аларның 200е исән һәм яңа исемнәр өстәлеп тора икән. Без шушы шәҗәрәнең күренекле бер вәкиле, Татарстан Республикасының атказанган урманчысы, төбәкне өйрәнүче, Татарстан Диния нәзарәтендәге Аксакаллар Шурасының Тәтеш бүлекчәсе җитәкчесе **Ирфан Исмәгыйль улы Халитов** белән ата-бабаларның мирасын саклау, нәсел шәҗәрәләре турында сөйләштек. Әлеге шәҗәрә төрле төбәктә яшәгән туганнарны бергә җыярга һәм авылда «Халитовлар мәҗлесе» оештырырга сәбәп булган.*

Редакциядән

Бу җиргә иң беренчеләрдән булып Иманкол бабай күчеп утырган

Шәҗәрәдә иң ерак бабабыз Иманкол бабай. Элекке заманнарда Мунчәли авылы иске мәктәп тирәсендә – Тепәй тавы дип аталган урында урнашкан була. Ул чорда өй янында бакча һәм ындырлар

булмаган, каралты-кура бер-берсенә терәлеп, авыл бик тыгыз урнашкан. XVII гасыр ахыры-XVIII гасыр башында халык саны арткан һәм авыл мәйданы әкренләп зурая башлаган. Шул вакытта безнең ерак бабайлар авылыбызның «Кече авыл» дип аталган өлешенә нигез салган. Иң беренчеләрдән булып бу җиргә Иманкол бабай күчеп утырган булырга тиеш.

Шәҗәрәгә күз салсак, авылыбызның Кече авыл дип аталган өлешендә яшәүчеләр – Халитовлар, Ильязовлар, Хисаметдиновлар. Хисаметдин бабай Рәхимкол бабай оныгы булса, Халит һәм Ильяс бабайлар – Малик бабайның уллары. Рәхимкол – Иманкол бабайның улы, Малик исә аның оныгы булган. Шулай итеп, шәҗәрәдән күренгәнчә, Кече авылга Иманкол бабай нәселе нигез салган дип әйтергә тулы хокукыбыз бар. Исмәгыйль бабайның әйтеп калдырган сүзләрен искә алсак, Халитовларның төп йортындагы кое XX гасырның 30-40 нчы елларына кадәр Кече авылда бердәнбер кое булган.

Элек урамны ике йорттан соң тыкрык кисеп төшә иде. Әлеге тыкрыкны Малик бабай землемердан үзе кистереп калдырткан булган. Бу исә безнең бабайларның заманында үзләре яшәгән җирлектә сүзләре үтәрлек дәрәҗәле кешеләр булуларын искәртә. Алар моны йортлар тыгыз урнашмасын, балаларыбыз иркенлектә яшәсен дигән максат белән эшләткән.

Бабайлар укымышлы кешеләр булган

Исхак бабай 1874 елда туган. Калган бабайларның кайсы елларда яшәгәнлеге турында төгәл мәгълүмат юк. Әгәр, шәҗәрәгә күз салып, һәр өч бабай бер гасырга якын яшәгән дип санасак, Иманкол бабай якынча XVII гасыр ахырларында гомер иткән булырга тиеш. Шулай итеп, без үзебезнең Иманкол, Рәхимкол, Малик, Халит, Исхак һәм Исмәгыйль бабайларны беләбез. Безнең фамилиябез Халит бабайдан калган. Халит бабайның ике улы булган: Исхак һәм Мөшәррәф. Алар бик оста куллы кешеләр саналган, балта эшен бик яхшы белгәннәр. Заманында Халит бабай һәм аның уллары мәчетләр төзеп йөргәннәр. Бабайның өендә агачтан эшләнгән карават, өстәл, диван (без аны эскәмия дия идек), бик матур урындык бар иде. Ул урындык әле дә үзенең матурлыгын югалтмаган. Аңа, ким дигәндә, 100-120 ел.

Борынгы осталарның кул җылысы

Безнең бабайлар шулай ук бик дини һәм укымышлы кешеләр булган. Тормышларын Аллаһ юлыннан тайпылмыйча, дөрес итеп алып барырга тырышканнар. Мөшәррәф бабайны Сембер губернасыннан мөгаллим итеп Иске Кулаткы районына җибәргәннәр. Бу илдә барган үзгәрешләр, революция елларына туры килгән. Ул шунда 1922 елда вафат булган.

Безнең нәсел чылбырын бабаларыбыз язып калдырган. Аны беренчеләрдән булып Халит бабайның улы Мөшәррәф бабай төзи башлаган. Башта ул гарәп имлясында булган, Исхак бабайның улы Нургали абый 1947 елда аны кириллицага

күчереп язган. Бабайларда зур гына «Записная книга» да сакланып калган. Анда да нәселебез турында бай мәгълүмат тупланган.

«Бабай оҗмахтан кайта!»

Әтием Исмәгыйль 1902 елда туган. Ул армиядән кайткач, Мунчәлидә төпләнеп калган. Аны Авыл Советы рәисе итеп билгеләп куйганнар. Исмәгыйль авылыбызның чибәр кызы Нурләдәгә өйләнгән. Аларның сигез балалары туган: Рафика, Васил, Наил, Надыйр, Шамил, Камил, Ирфан һәм Гөлфикә.

Әти беренчеләрдән булып колхозга кергән һәм склад мөдире булып эшләгән, сугыштан яраланып кайткан. Яралары төзәлә башлауга колхоз эшенә йөргән. Сугыштан соңгы елларда исә, әтиебез – яшелчәчелек бригадиры, Авыл Советы рәисе, сыйфат комиссиясе рәисе булган. Ул бик таләпчән, уңган һәм туры сүзле кеше иде, эшне җиренә җиткереп башкарганны гына яратты. Яшелчәчелектә бригадир булып эшләгәндә тәмәке, кәбестә утырткан вакытта барысын да күзәтүдә тоткан һәм бик таләпчән булган.

Рәсемдә: Ирфан Халитовның әтисе Исмәгыйль (сулда) хәрби хезмәттә вакытта

Әти җомга намазын бервакытта да калдырмады. Ул заманда мәчетләр юк, шуңа күрә дә намазны ир-атлар Солтангәрәй абый өендә укый иде. Намаздан кайтышлый әтинең балаларга унар тиен сәдака өләшкәне хәтердә. Шунлыктан балалар, аның җомгадан кайтканын түземсезлек белән көтеп: «Бабай оҗмахтан кайта!» – дип, шатланып каршы алалар иде.

Бабайлар коесын әти теләгәнчә төзекләндердек

Бабаларыбыздан калган коеның өске өлеш бурасы черегән иде. Әти бу хәлгә бик борчыла башлады. Бензин пычкысы белән чыршы агачларын урталай ярып, бура өчен материал әзерләдем. Шул материалдан әти белән бергәләп бура бурадык. Бөтен материаллар әзер булгач, коены сүтәргә керештек. Булышырга Васил абый, Наил абый һәм күрше Харис абый керде. Коеның черегән өлештәге бурасын һәм өстәге бүрәнәләрне алдык. Коедагы бөтен суны чыгардык. Коега төшеп, төпкә җыелган ләмне алырга кирәк иде. Мин, аякка – резин итекләр, өскә кожан киеп, коега төшеп киттем. Ләмне чиләккә тутырып биреп торам, өстәгеләр тартып

чыгаралар. Хәтердә, коеда ике кизләү бар иде, шуларны чистарттым. Өстәгеләр мине ашыктыра: «Әйдә, тизрәк чык», – диләр. Эшемне бетергәч, чыгам, дип хәбәр бирдем, тизрәк тартып алдылар. Баксаң, абыйлар минем өчен курыккан икән. Чишмәне ачкач, су бәреп чыгар да, батар дип шикләнгәннәр. Шуңа ашыктырганнар. Эш беткәч, барыбыз да төшке ашка кердек. Әти дә кое чистартудан бик курыкып торган. Шушы коены чистартып бирүчегә күчтәнәч бирер идем, дип нәзер дә әйтеп куйган булган. Ул күчтәнәчен миңа бирде. Бу хәл – 1980 нче еллар истәлеге. Буыннардан килүче әлеге коены киләчәктә дә саклап тотсак иде.

Мәдрәсәләрдә – китап киштәсе

Мәдрәсәнең кичке бүлек шәкертләре. 2022 ел

Ислам динен тирәнрәк өйрәнү теләге мине Исламны кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәгә алып килде. Ильяс хәзрәт Җиһаншин мәдрәсә, уку класслары, йокы бүлмәсе, китапханә, ашханә, музей, намаз бүлмәсе белән бик теләп таныштырды. Бар да кызык һәм бик мавыктыргыч иде. Мөгаллимнәрнең дәресне саф татар телендә аңлатулары күңелне җәлеп итте. Алар барысы да югары дини һәм дөньяви белем алган, гарәп илләрендә укып, гарәп телен камил рәвештә үзләштергәннәр. Шулай ук мәчетләрдә дә имам булып эшләү тәҗрибәләре бар. Дәресләр беткәч, кичләрен көндезге бүлектә укучы шәкертләр безнең белән шөгыльләнеп, дөрес итеп Коръән уку, азан әйтү буенча белемнәребезне чарладылар. Шулай итеп, без, читтән торып укучылар, тәүлек буе гыйлем алдык. Остазларыбыз имам вазыйфаларының нечкәлекләрен дә өйрәттеләр.

Ильяс хәзрәт Җиһаншин көн саен диярлек төрле шәхесләр белән очрашулар оештырды. Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчеләре, Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм аның урынбасарлары, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Дәүләт Советы депутатлары, язучылар, күренекле шәхесләр белән очрашу аеруча зур тәэсир калдырды. Остазларыбызга һәм уку йортының ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншинга бик рәхмәтлебез.

Исмәгыйль Халитов көндәлегеннән өзек:

«1930 елның башында безнең авыл общий колхозга берләшә. Шул ук елның март аенда колхозыбыз туза башлады. Колхоздан чыгу өчен авылның бөтен ирләре һәм хатын-кызлары правлениегә заявление китереп бирделәр. Шул вакытта ирләр һәм хатын-кызлар: «Без колхозда тормыйбыз, безгә колхоз кирәкми, без колхозда эшләмибез», – дип, бик каты тавышландылар. Әлеге елның 10-11 апрелендә колхозчылардан фуражга дип җыелган салам, печән һәм башкалар хуҗаларына кире кайтарып бирелде. Язда халык үзенә тигән җирне үзе чәчә башлады. Шул чәчүне июнь аенда корт ашап бетерде. Корт ашаган җиргә, Ульяновскидан карабодай орлыгы китереп, яңадан чәчтеләр. 1930 елның ноябрь аенда җиде йорттан торган колхоз ядросы оештырылды. 1931 елның апрель аенда яз башына чәчүгә 40 йорт булды. 40 хуҗалык белән авыл башындагы җирләрне кисеп чәчтеләр. Шул ук елны безнең авылга район уполномоченный итеп иптәш Кәбировны җибәрде. Ул халыкка парны общий сукаларга куша. Халык, парны общий сукаламыйча, карышып торды. Шуннан соң иптәш Кәбиров үзе, Авыл Советы председателен алып, урамның башыннан төшеп, халыкның өеннән сука, сабанын җиктереп, пар сукаларга чыгардылар. Халык куркып кына сукаларга чыкты. Аерым хуҗалыклар кырга сукаларга барган вакытта колхоз җире яныннан узып йөриләр иде, шулай узып йөргән вакытта Кәбиров, колхоз председателе Шаһиев Ишмөхәммәт һәм башка правление членнары, бер төркем халыкны туктатып: «Колхозга керәсезме-юкмы?!» – дип куркытып, күп кешене колхозга керттеләр. Шул куркыту белән колхоз 140 хуҗалыкка җитте. Каташлык игенен эшләгән вакытта бик күп иген әрәм иттеләр. Карабодайны чапмадылар, виканы чапкан төштә калдырдылар. Андрей кырына барып та карамадылар. Ул вакытта колхоз председателе Шаһиев Ишмөхәммәт, колхозның плауты Әмирханов Ибрай, приемщик Мөдәррисов Идрис иде. Шул игенне эшләгән вакытта өчәү 30 пот борчак урлаганнар. Борчак урлаганны колхоз членнары беләләр дә председательнең өенә бик тиз барып, борчакны табалар. Бер олау борчак төяп алалар өеннән. Күрсәтммә суд ясадылар. Суд карар чыгарды: председатель Шаһиев Ишмөхәммәткә 3 елга төрмә, Әмирханов Ибрай белән приемщик Мөдәррисов Идрискә икесенә 6 шар ай принут (принудительный труд, эшләп түләргә. – И.Х.) ясадылар...»* ■

* Ул вакытта иген кырларын каташлык дип йөрткәннәр. Каташлыкка арыш, бодай, солы, карабодай кырлары кергән.

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – әдипләр, галимнәр һәм сәнгать әһелләре ноябрь аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә.
Менә алар:

16 ноябрь – шагыйрә, журналист, Мөслим районының Метрәй авылы тумасы **Асия Минһаҗева**га (Асия Миръякут кызы Минһаҗевага) 70 яшь (1952);

25 ноябрь – скульптор, гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, РФнең һәм ТРның Рәссамнар берлекләре әгъзасы (1990), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2006), Б.Урманче исемендәге премия лауреаты (2007), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2010), Ленинград (Санкт-Петербург) шәһәре тумасы **Асия Миңневәли кызы Миңнуллина**га 70 яшь (1952);

26 ноябрь – математик, физика-математика фәннәре кандидаты, СССР дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь, 1981 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның Яшел Үзән шәһәре тумасы **Камил Әхмәди улы Мостафин**га 90 яшь (1932).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов



Сингапур күренеше

Пароход хезмәткәрләре

Әйе, бу җаһиллектә гаепле итеп тагын да шул ук исламиятне күрсәтергә тырышалар. Берәү дә: «Инглизләрнең Һиндстанны басып алганнарына инде йөз ел бар. Мәдәният исеме астында Һиндстанга 50 процент салым салынган. Салымнан килгән табышны инглизләр үзләштерә, ә кимчелекләрне исламияткә сылтыйлар», – дими. Нишләмәк кирәк.

Нәмази җәнаплары миңа сорау бирде:

– Кытайда яшәгәндә, тел җәһәтеннән кыенлыклар күрмәдегезме?

– Бик зарланырлык булмады. Шулай да, табигый инде, мәҗүсиләр арасында калганда, тел белмәгәч, ачлыкка да түзәргә туры килде. Мөселманнар арасында көн күрү авыр булмады үзе.

– Мин кытай илендә бик күп йөрдем. Тел мәсьәләсе кешене мөшкел хәлләргә калдыра. Тик мин инглизчә белгән кешеләрне шактый очрата идем.

– Кай якларында йөрдегез?

– Мин гел көньягында булдым. Бигрәк тә Франция колонияләрендә. Ул җирләрдә инглизчә белүчеләр очрый иде.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Кытайда парламент

– Тиздән игълан ителер дип көтелгән парламентка Сез ничек карыйсыз? – дигән соравыма Нәмази җәнаплары болай дип җавап бирде:

– Әгәр милләт эчендә тулысынча уяну юк икән, минем фикеремчә, парламент белән генә мәмләкәт төзелә алмый. Дөрес, мин парламентны нигездән инкяр итмим, тик парламентка кешеләр кирәк. Алай гына, гади халык сайлап җибәрәчәк агайлар белән генә эш бармас ул. Рус думасы, Иран парламенты моны бик ачык күрсәтте. Инде менә карыйк, Госманлыда Вәкилләр мәҗлесе ни эш кылыр? Шулай да кытайлар бөтенләй үк төшеп калмаячак, чөнки Кытай иленә өч йөз студент җибәргәннәренә менә ике ел булды. Болар бер авылдан икенчесенә йөреп, бөтен Кытайны гизәчәкләр. Кулларында тәгълимат бар: сайлау ысулын, нинди кешеләр сайланачагын, сайланган вәкилләрнең милләт алдындагы бурычларын бар җирдә дә бәйнә-бәйнә аңлатачаклар. Хәтта сайлауларның ничек үтәчәген дә күрсәтә-күрсәтә, 5 елмы, әллә 3 елмы – анысы бик хәтеремдә юк – гел өйрәтәчәкләр. Фәкать, барыбер теләгәннәренә ирешә алмаслар дип уйлыйм, ник дигәндә, сайлауларның ысулын һәм кагыйдәләрен өйрәнерләр, ә сайларга кеше таба алмаслар.

– Кытай халкы бу мәсьәләгә ничек карый икән?

– Ничек булсын инде?! Һич кенә дә аңлый алмыйлар: «Богди Хан булмаса, мәмләкәт ничек идарә ителер?» – диләр, бик кабул итмиләр. Төп мәсьәлә ул түгел. Бүген эш башында торучы кешеләр үзләрен бераз кулга алып, бер ун ел гына булса да мәмләкәтләрен чит ил баскынлыгыннан саклый-яклый алсалар, аннары парламент та булыр, кешесе дә табылыр иде. Бүгенге көндә, укып белем алу өчен, дөньяның һәр тарафына киткән кытай студентлары шактый. Алар бигрәк тә Япониядә күп. Күбесе быел укуын тәмамларга җыена. Менә болар кеше булачак. Саннары елдан-ел арта бара. Шуның белән бергә, милләт бер ун ел нык торса, каршылык күрсәтә алса?!.

Без шул рәвешле Мөхәммәт Нәмази җәнаплары белән гел фикер алышабыз. Бу хөрмәтле затның каенатасы да әлеге өлкәдә икән, исеме – Хаҗы Зәйнәлабидин. Бу кешенең дә күпсанлы пароходлары бар, ди. Димәк, безнең дустыбыз һәр ике яктан да капитал иясе булып чыга.

Мин, мондый форсатлар чыкканда, файдаланып калырга тырышам. Беркөнне сүзне безнең флотка китереп ялгадым һәм ярдәм кирәклеге турындагы фикеремне белдердем. Шулвакыт Нәмази җәнаплары болай диде:

– Бу – чынлап та, зур вазыйфа, бөтен мөселманнар өчен бик мөһим мәсьәлә. Аллаһының ярдәме белән Бомбейга барып җитүгә, мин бу хакта сәүдәгәрләр мәҗлесендә сөйләрмен.

Без утырып барган пароход

Пароходның зурлыгында һәм башка якларында, бигрәк тә каюталарда шикаять итәрлек берни дә юк. Дөньяның иң зур ширкәте, ягъни фирмасының 417 263 тонналык пароходы. Бөтен пароходларының куәте – 443 922 ат көчендә. Иң зур пароходларының исеме – Макид.

Бу пароходлар Йокохама белән Лондон арасында йөреп тора. 11 628 мил юл үтәләр. Атна саен берсе китә, икенчесе килә. Мондый пароходларның бер дә кимчелекләре юкмы икән?

Сингапур. 1900 ел

Кимчелек дип тә атыйсым килми, тик шулай да әйтмичә дә кала алмыйм.

Билгеле булганча, Ханканнан Сингапурга барганда, 1440 мил ара туры сызык булып экваторга таба күтәрелә. Эсселек дәрәҗәсен дә бераз искә төшерик. Көне-төне 35-36 градус эссе тора. Кешеләр пароходта каютада да, палубада да утырып хәл алачак урын таба алмый. Югарыда, палубада юлчыларга йөрер өчен аталган урыннар бар-барын, ләкин кеше көне буе йөри алмый, бераз утырып торырга да тели. Кызганыч ки, анда юлчыларга утырып хәл алыр өчен бер җир дә юк.

Мин икенче дәрәҗәдә барам. Сингапурга кадәр 75 доллар түләдем. Ә монда эсседән качып утырырлык җир юк. Бичара Нәмази Бомбейга кадәр 400 доллар биргән, ул да нәкъ минем кебек үк утырып хәл алырлык урын таба алмый, эсседән куырылабыз. Пароход өстендәге киң мәйданда йөзләрчә кеше бар, тик утырыр урын юк. Теләсәң никадәр йөр.

Хуш, нишләргә кала? Әйе, син дә, 3-5 доллар түләп, бер урындык сатып аласың да өстенә исемеңне язасың яисә визиткаңны бәйләп куясың. Шуннан соң бу синең малың була. Аннары барып җитеп, пароходтан киткәндә, аны каюта хезмәтчесенә бүләк итеп калдырасың. Менә пароход хезмәтчеләре өчен бер төр табыш юлы. Мондый нәрсә безнең Көнчыгыш халыкларында булса, һәр сәяхәтче моны гаепләп язар иде. Тик үзләрендә бу бер төр мәдәнилек булып санала.

Сингапурга якынлашабыз

Иртәгә Сингапурга барып җитәчәкбез. Пароходта көтмәгәндә фаҗигале сызгы тавышлары ишетелде.

Кинәт ыгы-зыгы башланды. Матрослар сулышлары кабарлык булып йөгерешәләр иде.

Минем кебек тел белмәүче юлчылар да байтак. «Нәрсә бар? Ни булды?» – дип сорыйлар. Диңгез лә бу, ни генә булмас?! Матрослар кинәт һәр яклап суга көймәләр төшерә башладылар. Бар да югарыга ташланды.

Ниһаять, аңладык: пароходыбыз вакытыннан бер-ике сәгать алдарак кузгалган да, капитан җәнаплары, форсаттан файдаланып калырга тырышып, матросларның хәзерлек дәрәҗәләрен, кайсы җитәкче кул астындагы матросларның җитезрәк булуларын ачыклар өчен, диңгезгә бернәрсә аттырган да коткару сыбызгысын кычкырткан.

Җиде-сигез каек төшерелгән, һәр матрос, суда батмый торган киемнәр киеп, диңгезгә сикергән. Бөтен якны тикшерәләр, эзләнәләр. Пароход шул урында икеөч сәгать буе чайкалып торды. Боларның диңгез өстендә коткару хәрәкәтләре, ярышлары бик хуш манзара икән.

Диңгезгә атылган нәрсә табылды. Эчендә ун инглиз лирасы бар икән. Кайсы команда тапса, шул матрослар акчаны үзара бүлешә. Мондый имтиханнар үткәрелгәнгә, коткару эшендә берничә тапкыр уңышка ирешкән матрослар ширкәт тарафыннан да, хөкүмәт тарафыннан да бүләкләнә икән.

Бу юлы атылган нәрсәне табып алган матрос һинд кешесе иде. Бик зур осталык күрсәткән, чөнки пароходның ул булган ягына түгел, каршы ягына ыргытылган нәрсәне барыннан да алдарак эзләп тапкан. Мин диңгезләрдә бик күп йөздем, тик мондый имтиханны беренче тапкыр күрүем иде.

Икенче яктан, кайбер тынычсыз, авыру кешеләрне уйлап, кайгырып та куйдым. «Болай тота-каба, дөнья кубарып сыбызгылар кычкыртып, юлчыларны борчу нәрсәгә инде», – дип уйладым.

Ул арада Нәмази белән очраштык. Мин:

– Куркыттыларммы Сезне? – дип сорадым.

– Йоклаган идем, ул арада ыгы-зыгы, шау-шу башланды. Мин Сингапурга килеп җиттек дип уйладым. Минем күрше каютада бер хатын бар иде. Ул: «Батабыз!» – дип кычкырып җибәрмәсенме?! Мин дә курка калдым, тик зиһенем кабул итмәде. Әлеге капитан бу җирләрдә гел имтихан үткәрә, шул исемә төште. Бер тапкырында ханымнар мәхкәмә дәгъвасы да ачканнар иде.

Туганым Нәмази җәнаплары бу юлларда бик күп тапкырлар йөргән кеше, мондый хәлләрне белә. Минем белән бик ачык сөйләшә, милли хисе дә көчле. Миңа: «Аурупалы ни генә эшләсә дә, хуш күрәбез инде», – диде.

Рамазан Шәрифнең бер атнасы үтә дигәндә, Сингапурга килеп җиттек. Биредә туганым Нәмази җәнаплары белән саубуллаштык. Мәүлә сәламәтлекләр бирсен үзенә. Ул туры Бомбейга таба юлын дәвам итте.

Соңгы сүз

Юл истәлекләремне язуымны шушында туктатачакмын. «Галәме Ислам»ның беренче китабы менә шушыннан гыйбарәт.

Бирегә кадәр үткән юлым Русиядә, Владивостокка кадәр, чакрым исәбе белән 14 000 чакрым булды.

Аннары Япония, Корея, Кытайда Сингапурга кадәр 7346 инглиз миле булды.

Минем букадәр сәяхәт юлымда тотылган акчаның күләме чагыштырмача бик аз иде. Булса-булса, бер 100 лира кадәр акча тотканмындыр. Гомеремнең исә ике елын сарыф иттем. Бу вакыт арасында башкарган хезмәтләремнең иң мөһиме дә – сәяхәтем, чөнки Коръәне Кәримдә иң аз 13, бәлки дә, 15 җирдә:

«Җир йөзендә йөрегез...» – дип әйтелгән хәлдә, безнең мөселманнар бу фарызны бөтенләй диярлек онытканнар иде. Аллаһыга хәмд булсын, Аллаһы Тәгалә бу фарызның бер генә өлешен булса да башкару вазыйфасын миңа насыйп итте.

Икенче өлеше исә – бәлки, тагын да мөһимедер – бәлки дә, берәү тарафыннан да башкарылмаган бер форсат иде: ул чакыру, өндәү һәм белдерү эше. Әлхәмдүлилләһ сүммә әлхәмдүлилләһ, моны да Җәнабы Хак мин гаҗизгә насыйп итте. Минем кебек бер гаҗиз өчен бу ике вазыйфа да бик бөек иде. Моның өчен йөз мең телдә шөкер итсәм дә, аз булыр.

Ара сүз

Өндәү эше исламның башлангыч чорында дини вазыйфа булып торса да, соңгы вакытларда ул бөтенләй онытылып бара. Голәмәбезнең дә бу хакта берни сөйлисе килми.

Башкаларны дингә өндәү кая инде ул, гасырыбызның голәмәсе хак дин исламга һөҗүм итүчеләргә җавап кайтаруда да хәтта гаҗиз калды. Борынгыларыбыз һәр гасырда барлыкка килеп исламияткә ташланган төрле мәзһәп кешеләренә, читләргә билләти һийә аһсәнә [иң гүзәл рәвештә] (Әнъам: 52) җавап биреп, вазыйфаларын башкарганнар.

Гасырыбызда исә, чит-ятлар бер тарафтан һөҗүм итеп, ялганнар, ялалар язып тараталар, икенче тарафтан үз җаһилләребез – берни белмәсәләр дә, бары тик Аурупалыларга ияреп – әллә нинди мөнәсәбәтсезлекләр эшлиләр.

Бу кайгыга сала торган хәл һаман да арта барганга, соңгы елларда голәмә исеме белән танылган кайбер затлар, яңа белемнәр булдыра алмыйча, дәһшәт эчендә калганнар. Бичара Мөхәммәд Абдуһ Коръәндә аять белән ныгытылган фәрештәләрне һәм Иблисне дә инкяр иткән, акыллы һичбер кеше иман нигезләренең икенчесе булган фәрештәләрне инкяр итә алмас!

Белемгә сыймый икән. Белемгә сыймаган тагын күп нәрсәләр бар. Безнең голәмәбез диннең нигезләрен ике дә уйламыйча инкяр итә икән, җаһилләребезгә нәрсә әйтә алабыз?! Динебезгә һөҗүм итеп торучы чит-ятларга нәрсә әйтә алабыз?! Боларны күз алдына китерик, бераз инсаф күзе белән карап, хәлебезне тикшереп карыйк: безнең хәлебез бик кызганыч. Без, һич булмаса, үзебезне вазыйфага чакырыйк.

Читләрне, башкаларны чакырмасак, өндәмәсәк, һичьюгы, үз-үзебезгә: «Әй иман китерүчеләр! Иман китерегез!» (Ниса: 136) – дип әйтик.

Мин бу хакта «Галәме Ислам»ның икенче китабында тәфсилләп язачакмын. Мәүлә хәерле эшләргә ирешергә насыйп итсен!

Искәрмә

«Галәме Ислам»ның 162 нче битендә* язган идем: безнең белән вагонда бер ханым барган иде. Владивостокка килеп җиткәч, минем белән күрешеп, юлда күрсәткән бер татар егетенең кем икәне турында әйтәчәк иде. Владивостокта ханым белән кабат күрешәчәгебезне әйткән идем. Тик, ни кызганыч, бу хакта берни теркәлмәгән.

---

* Бу – әсәрнең госманлы-төрек телендә басылып чыккан төп нөсхәсендәге бит саны *(тәрҗ.иск.)*.

Моның төп сәбәбе шул: без ул ханым белән кабат күрешә алмадык. Ханым берничә тапкыр мин яшәгән кунакханәгә килгән, бер тапкырында өстәлдәге кәгазьгә карандаш белән язып: «Сезгә исемем, кем булуым билгеле түгел, бары тик үземне генә күреп беләсез. Өч тапкыр килсәм дә, күрешү насыйп булмады. Кабат килә алмыйм. Билгеле киртәләр бар. Шәһәребездә идарә тарафыннан тикшерүләр бара», – дигән язу да калдырган иде.

Ул ханым белән күрешә алмавыбыз сәбәпле, бу язма хакында да вакытында язылмаган, күрәсең. Шуңа бәйле рәвештә, «Галәме Ислам»ның алда күрсәтелгән битендә дә төгәлсезлек килеп чыккан.

«Галәме Ислам»ның икенче китабы

Аллаһыга хәмд булсын, беренче китабыбыз тәмам булды. Өч айдан соң икенче китапны бастыра башлыйбыз.

Икенче китап сәяхәтебезнең мөһим өлешен тәшкил итәчәк. Һинд океаны утрауларында һәм Малака борынында булган 37 мөселман әмирлегенең үткәндәге һәм бүгенге көнебездәге хәлен; Җава, Малайа кавемнәренең тормышын һәм Голландия дәүләтенең боларга күрсәткән золымын, төрле утрауларда яшәүче Хиҗаз һәм Хадрамут гарәпләренең хәлләрен, Англия хөкүмәтенең ул җирләрдә алып барган изү сәясәтен тәфсилләп аңлатканнан соң, Һиндстанга күчәчәкмен.

Һиндстанда мөселманнарның үткәне һәм киләчәге, бүгенге хәлләре турындагы мәгълүматтан соң, Һиндстанда ел саен, бәлки дә, ай саен диярлек барлыкка килеп торган төрле мәзһәпләрнең бар булу сәбәпләрен, аларның хакыйкате һәм нигезләрен аңлатканнан соң, Браһимә, Парсы һәм Будда мәзһәпләре хакында да бераз мәгълүмат бирәчәкмен. Һиндстан мәмләкәтендә булган 300дән артык хөкемдарның бүгенге хәлләре һәм киләчәктә тотачак урыннары турында да, Хайдарабад Дәкканда минем зинданга эләгүем турында да сүз булачак. Бөтен Һиндстанда ислам мәдрәсәләренең хәле турында да язачакмын.

Англия хөкүмәтенең Һиндстанда һәм Басра (Фарсы) култыгында йөрткән сәясәте.

Һиндстанда гарәпләр, әфганнар, татарлар, фарукиләр, накшиләр. Мәҗүсиләрнең үлеләрен яндырулары. Ганга (Ганҗ) елгасының изгелеге.

Бомбей шәһәренә Япониядән Үмәр Әфәнде Йамаоканың килүе. Бомбейда, Һиндстанның башка төбәкләрендә миссионерларның эшчәнлеге, эш ысуллары, мөселманнарны бүлгәләүдәге уңышлары. Боларның барысын да тәфсилләп аңлатачакмын.

Аннары, *Гадәндәге мөселманнарның хәле, инглизләрнең тоткан урыны, Камрандагы карантин, биредәге хаҗиларның хәле, мөселман хаҗиларга Госманлы докторлары тарафыннан күрсәтелгән кардәшчә мөгамәлә һ.б.*

Ярлыкау тулы Хиҗаз җирләре һәм, ниһаять, Сүриядән Истанбулга кадәр безнең юлыбыз «Галәме Ислам»ның икенче китабын тәшкил итәчәк.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Бертуган Хәмидиләр мирасы

Назыйм Мәхмүтов

Алгы рәттә идәндә утыручылар арасында уңнан икенче – Шакирҗан Хәмидуллин (1878-1932)

Шәйхелислам Хәмиди

1907 елда сәүдәгәрләр Мортаза хаҗи һәм аның улы Гыйрфан Мусиннар Минзәлә өязенең Яхшыбай авылында ике катлы мәчет салдыралар. Аның беренче каты мәдрәсәнең уку сыйныфлары өчен тәгаенләнеп төзелә. Мәдрәсәдә укытыр өчен, Казаннан, елга 365 сум түләү шарты белән, Шәйхелислам Хәмиди чакырылган була инде. Аның тулы исеме – Шәйхелислам бине Әсәдулла бине мелла Хәмидулла бине Сәйфетдин бине Морзабулат. Ул 1869 елның 20 сентябрендә Сембер губернасының (хәзерге Татарстанның Чүпрәле районы) Татар Төкесе авылында (Д.Гарифуллин «морзалар нәселеннән булган гаиләдә» дип ассызыклый) туган. Шәйхелислам башлангыч белемне авылында, Хәмидулла бабасыннан ала. Буа мәдрәсәсендә, Казанда «Мәрҗани» мәдрәсәсендә 5 ел, аннары Г.Барудиның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, Уфада «Госмания» мәдрәсәсендә белемен күтәрә. Берара бертуган Кәримовлар типографиясендә дини басмаларны тикшерүче булып эшли, Уфада «Госмания» мәдрәсәсендә хәлфәлек итә, Әстерхан якларында да укытып ала. Имам-хатыйб һәм мөдәррис дәрәҗәсендә Уфа губернасының Минзәлә өязендәге (хәзерге Сарман районы) Яхшыбай авылы мәчет-мәдрәсәсендә исә 1904 елның 2 мартыннан, «Мәрҗани» мәдрәсәсендә имтихан тотып һәм 1184 нче таныклык алганнан соң, эшли башлый.

Аның белән бергә мөгаллимнәр Салих Садыйков – Карашай-Саклаудан, Сәлим Галиев – Зөя өязеннән, Фатыйх Сәйфи Казаннан килә. Төрле елларда Яхшыбай мәдрәсәсендә Камил Вахитов (Минзәләбаштан), Кәрам Шәрәфетдинов (Чукмарлыдан), Зәки Зарипов (Куҗактан), Хәйрулла Гарифуллин (Яхшыбайдан), Хөснимәрдән Фәхретдинов (Яхшыбайдан), Латыйф Закиров (Нөркәйдән, бу авыллар хәзер Сарман районына карый) һәм башкалар белем бирә. 1913 елда анда 120 шәкерт белем алган, укыту яңача ысул белән алып барылган. Шулай ук монда Шәйхелислам Хәмидинең энесе Шакирҗан Хәмиди дә укыткан.

Икенче кат гыйбадәт кылу өчен файдаланылган. Мәчетнең берничә керү юлы, ике залы, манарасы булган. Төп керү юлы аның төньяк өлешенә урнашкан. Беренче катка төньяк һәм көньяк яклардан керү юллары ясалган, икенче каттагысы зур тәрәзә белән яктыртылган, декорацияләп, фигуралап эшләнгән мәчет була ул. Аны төзегәндә бер ватык кирпеч тә кертмәгәннәр, измәсен, тирә-яктан җыеп, йомырка кушып изгәннәр, дип сөйлиләр. Түшәмнәрендәге матча урынына рельс куеп, шуңа дугалап, кирпеч тезгәннәр. Алар бүгенге көндә дә матурлыкларын югалтмыйча сакланган. Бу мәктәп-мәдрәсәне Мортаза һәм Гыйрфан Мусиннар үз хисапларына тотканнар, мөгаллимнәргә дә хезмәт хакын үзләре түләгәннәр. Шәйхелислам Хәмидине укытырга чакыргач, аңа торырга ике катлы йорт салдырганнар. Алар шунда хатыны Камалетдин улы Фәсхетдиннең кызы Зәйнәп абыстай һәм әнисе Вәсфикамал абыстай, балалары белән яшәгәннәр. Габделсамат исемле малайлары 1905 елның 27 гыйнварында туа, 1906 елның 28 гыйнварында ул вафат була. 1907 елның 23 мартында Хәмзә исемле малай дөньяга килә, тик бер елдан – 1908 елның 24 февралендә – ул да вафат. 1908 елның 30 ноябрендә Шәймә исемле кызлары туа. Шәйхелислам Хәмиди 1911 елның 9 июлендә вафат булгач та, алар әле Яхшыбайда яшәп торганнар.

Ш.Хәмиди шәкертлек чорыннан ук гарәпчә китапларны татарча аңлатмалар белән бастыра башлый. Бу шәрехләү дип атала. Мисал өчен, ул Кодури Әхмәт бине Мөхәммәт әл-Багдадиның (972-1037) мөселман хокукый белеменә багышланган хезмәтен татарчалаштыра, «Кодури» китабы төрки телле имамнарның өстәл китабына әйләнә. «Бохарзадә», «Әмали», «Тәрикаи Мөхәммәдия», «Төхфәт әл-Мөлек», «Фикъһе Кидани» китаплары татар халкына туган телләрендә барып җитә. Шәйхелислам Хәмидинең зур хезмәте – «Әл-иткан фи тәрҗемәтел Коръән» дигән ике томлык Коръән тәфсире (1909-1911). Башта аерым аять һәм сүрәләрне шәрехләп аңлату белән башланган эш «Һәфтияк»не (Коръәннең җидедән берен) аңлатып чыгу белән тәмамлана. Шәйхелислам Хәмидинең сәламәтлеге начарлануга карамастан, тулы тәфсирне дә эшли. Әлеге тәфсирнең беренче томы үзе исән чакта басыла, икенче томы Хәмиди вафат булганнан

Надеждинск мәдрәсәсендә дәрес барган мизгел. 1913 ел

соң дөнья күрә. 1911 елда ук хезмәтнең икенче басмалары нәшер ителә башлый. Бу китап Токиода (1950), Истанбулда (1984), Катарда (1985) яңадан басылган. Төрки халыклар өчен бүген дә иң абруйлы, иң аңлаешлы, иң әһәмиятле тәфсир бу. Коръәннең әлеге аңлатмасы (комментарий) нигезенә Җәләледдин әс-Сүютинең (1445-1505) Коръән экзегетикасы (беренчел мәгънәләре югала барган дини текстларга аңлатма бирү турындагы тәгълимат) өлкәсендәге хезмәтләре кергән. Тәфсир Коръәннең тулы тематик күрсәткечен тәкъдим итә. Изге китап белән бәйле бик күп гарәп аңлатмаларына таянып, Ш.Хәмиди Коръән мәгънәләрен бирүнең иң кулай вариантларына туктала. Тәфсирнең төп үзенчәлеге – аның гадилегендә, киң катлам укучыларга аңлаешлы булуында. Ә исеме исә Җәләледдин әс-Сүютинең «Әл-Иткан фи үлүм әл-Куръән» хезмәте белән үзара охшашлыклар булу турында сөйли. Шул ук вакытта, Коръән аңлатмасын язган Шәйхелислам Хәмиди, экзегеза проблематикасына яңача якын килеп, үз чоры үзенчәлекләрен чагылдырырга тырышкан. Аның Коръән тәфсире Урал-Идел буе төбәгендә киң кулланылган. Бүгенге матбугат та шушы хезмәткә таяна.

Шәйхелислам Хәмиди хакында язучылар искә алып үтә торган тагын бер момент бар. Бу – галимнең Галиәсгар Камал белән дуслыгы. Атаклы драматург Шәйхелисламны остазы санаган, китапларын бастырып чыгару чыгымнарын (хәраҗат) да күтәргән. Ш.Хәмидинең Г.Тукай белән дә таныш булуы бик ихтимал. Ни өчен дисәң, телгә һәм сүзгә бик усал шагыйрь Хәмидине, аның хезмәтләрен бер вакытта да яман итеп искә алмый. Аның үзен дә Татар зиратында Шәйхелислам белән янәшә җирлиләр.

Шакирҗан Хәмиди

Шакирҗан Әсәдулла улы Хәмиди (29/30.08.1878-1932) – мөгаллим, җәдиди дәреслекләр авторы, Казан өязенең Чуаш иле, Юртыш авылларында мөдәррис, имам-хатыйб (1903), инкыйлабчы, язучы, мөхәррир. 1878 елда хәзерге Чүпрәле районының Татар Төкесе (Зәки Нури да шуннан) авылында «морзалар нәселеннән булган» гаиләдә туган. 1932 елда Казанда вафат. Язып үткәнемчә, абыйсы Шәйхелислам Хәмиди – дин галиме.

Тормыш юлы искиткеч катлаулы бу шәхеснең. Башта ул үз төбәгендә, аннары 1896 елга кадәр Казандагы «Госмания» мәдрәсәсендә белем ала. Шакирҗан Хәмиди 1897 елның 1 декабреннән 1899 елның 8 мартына кадәр Татар укытучылар мәктәбендә ирекле тыңлаучы була. 1899-1903 нче елларда Чуаш иле һәм Юртыш авылларында (хәзерге Биектау районы) җәдиди мәктәпләр ачып укыта, аларда ел саен 45 малай һәм 30 кыз укый. Соңрак Юртыш авылы икенче мәхәллә мәчетендә имам-хатыйб була, соңыннан Казанга күчеп, бертуган Кәримовлар типографиясендә корректор булып эшли, «Азат», «Азат халык» газеталарында фанатизм һәм кадимчелеккә каршы мәкаләләр бастыра башлый. Кызыклы гына бер факт китереп үтәм. Ул, активлыкка Тукайдан калышмыйча, Коръәнне татарчага тәрҗемә иткән Муса Бигиевне дә чеметеп ала:

«...Мусаның бер сүзенә биш-ун җавап,
Бәрәкалла, Хәмидигә йөз мең савап...»

Шакирҗан Хәмиди, татар теленнән башка, гарәп, фарсы һәм рус телләрен дә яхшы белә, күп кенә дини китапларны тәрҗемә итеп бастыра, дәреслекләр дә яза.

1900-1910 нчы елларда ул төрле догалыклар, тәгъбирнамә, йолдызнамә кебек китаплар төзеп нәшер итә. Шакирҗан Хәмиди шулай ук «Әхтәри кәбир» исемле («Бөек йолдызлык») мең битле гарәпчә-төркичә сүзлекне төзүдә катнаша, дин турында «Һәдият, әл-Хәмиди», «Җәннәт әһеле кемнәр?» дигән китаплар яза. 1907 елда чыккан «Һәфтияк сүрәләре» җыентыгында Шакирҗан Хәмидинең аңа кадәр басылган 26 китабы турында мәгълүмат бирелгән. Моннан тыш, бу зыялы шәхес әдәби иҗат белән дә мавыккан, фәнни эшчәнлек тә алып барган. Аның «Төштәге 5 сум», «Бәхет хикәясе», «Яшь ана вә үги кыз хакында», «Шәригать һәм заман» һ.б. әдәби әсәрләре, «Гарәп теле синтаксисына кереш», «Аваз ысулына бәйләнешле әлифба» кебек уку-укыту әсбаплары булуы мәгълүм. Үз язмаларында патша хәзрәтләренә, хөкүмәткә, казак гаскәрләренә тел тидергән өчен хөкем ителә (1907 елгы стена календареның арткы ягындагы бер мәкалә), үз әсәрләрен бастырып чыгару хокукыннан мәхрүм кала. Аптырагач, Уфа губернасының Минзәлә өязендәге (хәзерге Сарман районы) Яхшыбай авылына абыйсы янына китә (1910), аннан Пермь губернасының Надеждинск шәһәренә (1910-1912) юнәлә. Монда мулла (3152 нче указ, 30.04.1910 ел) һәм мөгаллим була. Шакирҗан Хәмиди биредә үзенә генә хас активлык белән эшли башлый: кызлар һәм малайлар өчен ике русча-татарча укыта торган мәктәп оештыра, аларда 100 бала укый, рус телен укытырга энесе Садыйкны чакырта. Шәһәрнең байларын уку-укыту эшенә ярдәмгә тарта, нәтиҗәдә, мәктәпләргә кирәкле яңа төр җиһазларга уку-укыту кирәк-яракларына аптырап тормый башлыйлар. Шакирҗан шәһәрнең иң актив кешесе булып китә, аның өчен губернатор И.Ф.Кошкога шәхси хатлар юллау гадәти хәлгә әйләнә. Ул руслар һәм татарлар өчен уртак «Җәмгыяте хәйрия» идеясе белән янып йөри башлый, православие динендәге рус хатыннарының исламга күчүләренә дә каршы чыга. Мулланың активлыгы, әлбәттә, көнчелек хисләре уятмыйча калмый. Шәһәрнең мөселманнары икегә бүленә: бер якта – Ш.Хәмиди һәм алдынгы карашлы татар сәүдәгәрләре; икенче якта – заводның подрядчигы Саттар Идрисов, мәзин Тимершаһ Ильясов. Кадимче бу төркем Шакирҗанны мөселманнар арасында «урыска сатылган» дип сүгә, ә хөкүмәткә юллаган хатларында исә аны панисламизмда гаепли. 1911 елның 16 июлендә мулланың, аның дуслары һәм туганнары өйләрендә, мәчет һәм мәктәпләрдә тентү үткәрелеп, 38 китап, 193 брошюра, 4 блокнот, 166 бит язмалар алына. Дөресе, алар, тикшерелгәннән соң, хуҗаларына кире кайтарыла. Хәмидинең үзе тарафыннан язылган «Мең дә бер хәдис» китабы иң зыянлысы дип табылып, 1032 данә китап сатудан алдырыла. 25 сентябрьдә яңа



Надеждинск мәчетенең проекты

Шәйхелислам Хәмиди кабере

тентү нигезендә күпләгән китап-язмалар конфискацияләнә, шул ук көнне мулланың үзен дә Югары Тура өяз төрмәсенә ябалар. 27 октябрьдә суд була: завод эшчеләре арасында ислам идеяләре таратучы төркемне җитәкли дигән донос нигезендә, Шакирҗан эшеннән бушатыла һәм өч елга Олонец губернасына (хәзерге Петрозаводск) сөргенгә җибәрүгә хөкем ителә. Фикердәшләре Мирхәйдәр Хәбибуллин белән Сабирҗан Волковка икешәр ел бирәләр. Шакирҗан Хәмиди, үзенең гаепсезлеген расларга теләп, губернаторга, Эчке эшләр министрлыгына хатлар юлласа да, алар җавапсыз кала. Ул хатларында «14 айга 73 мәртәбә патшага, аның гаиләсенә иминлек теләп, мәхәллә халкы белән гыйбадәт кылуын, аларда 50дән алып 1200гә кадәр кеше катнашуын», «1911 елның 6 сентябрендә П.А.Столыпинга исәнлек теләп гыйбадәт үткәрүен, аның белән бергә 200 мөселманның күзләреннән яшь агуын» искә алып үтә. Шакирҗан үзен: «Россия дәүләте улы», – дип атый.

1914 елда сөргеннән кайткач, ул яңадан укыту эшенә тотына. Минзәлә өязенең Яхшыбай авылындагы мәктәптә 1917 елның 6 мартына кадәр 300 кеше укуы хакында документлар сакланып калган. Февраль революциясеннән соң, Шакирҗан Хәмиди өязкүләм атаклы кешегә әйләнә. Ул «Гражданлык хокукларын тарату комитеты»н һәм өязнең 26 волостенда Советлар оештыра, Өяз крестьяннар Союзында тора. 1917 елның 10 октябрендә ул, Уфа губернасы өязләре арасында беренче булып, «Минзәлә иле» газетасын чыгара башлый. Ш.Хәмиди моның өчен үзе элек эшләгән Кәримовлар типографиясеннән гарәп шрифтлары алып кайта. Шрифтлар атаклы оста Мөхәммәт Идрисов (1882-1948) тарафыннан ясалган була. Газета өчен эпиграф итеп сул эсерлар лозунгысы алына: «Хокукыңны көрәштә генә табарсың, көрәш!» («Только в борьбе найдешь свое право, борись!»). Газетаның тиражы 5-6 меңгә җитә, ул өязнең 33 волостенда да тарала. Аның беренче 50 номеры 1918 елның июленә кадәр шул исем белән чыга. Ак чехларны куганнан соң, шул ук елның октябреннән газета яңадан 5000 тираж белән чыга башлый, тик исеме генә үзгәргән була. 1919 елның мартында башланган Колчак гаскәрләре һөҗүме

вакытында, әлбәттә, газета кайгысы булмый. Газета шул елның июленнән башлап кына, «Кызыл әләм» исеме белән кире кайта. Тик бу вакытта Шакирҗан Хәмидуллин Көнчыгыш фронты хәрбиләре карамагында бөтенләй икенче төрле йомышлар башкара. И.Рәмиевнең «Вакытлы татар матбугаты. (Альбом.) 1905-1925» исемле 1926 елда дөнья күргән атаклы хезмәте бар. Анда «Минзәлә иле» хакында болай язылган: *«Бу газета үзенең эчтәлеге, техник эшләнеше, теленең үтемлелеге ягыннан өязләрдә чыгарыла торган үзе кебекләр арасында иң яхшысы иде, губернаның күп газеталарына бирешми иде... Крестьяннар өчен чыгарыла торган газеталар арасында иң өлкәне, гади, матуры шушы газета. Мондый газеталар сирәк очрый. Авыл белән элемтә яхшы куелган. Монда редакция язмый, ә күпчелеге крестьяннар. Бәлки, менә шуңа күрәдер, аңарда крестьянга аңлашылмый торган бер сүз дә юк».* Шакирҗан Хәмидуллин 1917 елның 14 декабреннән Крестьян депутатлары Минзәлә өяз Советының рәисе. Гражданнар сугышы елларында Көнчыгыш фронтта ак чехларга, колчакчыларга каршы сугышларда катнаша, Казанда, Сарапулда, Әгерҗедә эшли, агитатор да була, газеталар да чыгара. 1918 елда ул РКП(б) сафларына керә. 1918 елның августына кадәр Минзәлә өяз башкарма комитеты әгъзасы, Мөселман эшләре буенча өяз комиссариаты рәисе, Округ суды әгъзасы һәм Хәрби Совет әгъзасы була. Ш.Хәмидуллин Сарапул шәһәрендә, 3 нче Армия политбүлеге кушуы буенча, «Кызыл көрәшче» газетасын чыгара. Сарапул башкарма комитеты әгъзасы һәм милләтләр эше буенча бүлек мөдире вазыйфаларын башкара. Ш.Хәмидуллин, адмирал А.В.Колчак армиясеннән качып, 1919 елның 4 апрелендә Казанга кайта һәм анда 1 нче Мөселман бригадасы политбүлеген оештыруда катнаша. Шул ук елның 30 апрелендә ул Үзәк Мөселман хәрби коллегиясе тарафыннан Көнчыгыш фронтка агитатор-оештыручы итеп җибәрелә. Ш.Хәмидуллин – 8 июльдән 31 августка кадәр Әгерҗе башкарма комитеты рәисе. 1919 елның 1 сентябреннән 9 октябренә кадәр ул Көньяк фронтта мөселманнар арасында агитация эшләре алып бара, Саратов шәһәрендә мөселманнар съезды үткәрә, мөселманнар эше буенча губерна комиссариаты коллегиясе рәисе итеп сайлана. Яңадан Әгерҗегә кайтарылып, башкарма комитет рәисе итеп билгеләнә. Ш.Хәмидуллин шунда эшләгәндә Совет яклы муллаларның 3 съездын үткәрә, Әгерҗе кантоны оештырылуның башында тора, 1921 елның 8 декабренә кадәр кантонда төрле вазыйфалар башкара. 1922 елдан соң без аны Уфада, Алабуга, Тәтеш һәм Мамадышта күрәбез: ул анда типографияләр оештыра, газеталар чыгара, «Алласызлар» җәмгыятьләре оештыра. Шакирҗан Хәмиди шул ук вакытта бик күп яза: аның «Динсез Морат Сәйфигә хөкем», «Мостафа муллага сәяси хөкем» (1925) дигән пьесалары билгеле.

Садыйк Хәмиди

Әлеге шәхесләрнең энесе – Садыйк Әсәдулла улы 1883 елның 10 декабрендә туа, Казандагы «Учительская школа»ны тәмамлый, 1910 елга кадәр Казан губернасының Царевококшайск (Йошкар-Ола) өязенең Мөрки волостендагы Әлмәмәт авылында казна уку йортында укыта. Ул җәй айларында олы абыйсы яшәгән Яхшыбай авылына кайта торган була. Гомумән, бу йорт алар өчен «төп йорт»ка әйләнә. Садыйк Хәмидуллин 1910 елның 1 октябреннән Пермь губернасының Надеждинск шәһәре (хәзер Свердловск өлкәсенең Серов шәһәре) урыс-татар уку йортында укыта башлый. Аның белән бергә хатыны Мәһирә, кызлары Сафия белән Суфия яшиләр. Абыйлары Шакирҗан муллалык итә, тик аны 1911 елның октябрендә, хакимияткә каршы җыеннар җыюда гаепләп, төрмәгә дә ябалар, сөргенгә дә озата-

лар. Шакирҗанның азатлыгы өчен көрәшү Садыйкка кала. Ул иң башта башкалада чыга торган «В мире мусульманства» газетасында абыйсы, аның эшләгән эшләре, гаепсезгә хөкем ителүе хакында язып чыга. Надеждинскиның алдынгы карашлы мөселманнары Садыйк янына җыела башлыйлар, ә бу полиция шымчылары тарафыннан күзәтелеп торыла. Нәтиҗәдә, 1912 елның 12 апрелендә губерна идарәсе чыгарган 1673 нче карар нигезендә, Садыйк укытучылыктан азат ителә. Августта Садыйк, әнисен, үз гаиләсен, икенче атадан туган сеңлесе Мәргупҗамалны, киленнәре Гайшә белән аның кызы Әминәне алып, Яхшыбайга кайтып төшә. Баштарак, хәзерге Зәй районына кергән Олоҗы авылында (Роберт Батулла да шуннан), аннан Теләнче Тамак авылында, 1914 елда Гөлшат Зәйнашеваның авылы Иске Теләнчедә (соңгы икесе хәзерге Тукай районында) казна мәктәбендә укытучылык итә. Торулары да шунда, мәктәпнең бер ягы булган иркен фатирда тәгаенләнә. Ләкин, көтмәгәндә, 1919 елның язында ул салкын тидерә һәм 37 яшендә вафат була. Гаиләдә җиде бала кала. Аларның Искәндәр белән Тәзкирә исемлеләре Яхшыбайда вафат булалар; Габбас белән Сафия Теләнче Тамак балалар йортында, аннан Семипалат балалар йортында тәрбияләнәләр. 1921 елны аларны казакъ гаиләләре балалыкка ала һәм Габбас белән Сафиядән бүтән хәбәр булмый. Суфия шулай ук балалар йортында үсә, ул сеңлесе Мәрьям белән, Теләнче Тамак 2 нче баскыч мәктәбендә укый. Суфия 1925-1929 нчы елларда Казан җир төзүчеләр техникумында да белем ала. Иң кечеләре Фатыйма 1916 елгы. Башлангыч белемне ул Теләнче Тамакта ала, 5 сыйныфны Казанда укый, 7 сыйныфны исә Чаллыда тәмамлый, урта белемне Алабугада ала. Фатыйма Казан авыл хуҗалыгы институтында ике ел укый, Каташ Каран мәктәбе, 1942 нче елдан Салкын Аланда, 1943-1946 нчы елларда Иске Кәшердә укыта. 1946-1969 нчы елларда ул Күтәмәле мәктәбендә белем бирә. Фатыйма 1966 елда Ленин ордены белән бүләкләнә.


(قرائت ترکیه‌دن)

منبت المعارف

(اوّل مرتبه باصلنوی)

اوچنچی صنف بالالاری اوچون ، تورلی فندن جیولغان ، قزان تلنده تزلمش

«اوقو» کتابی

مرتبی : شاکرجان الحمیدی .

ترتیبی : میلادی ۱۹۰۵ نچی سنه‌نك ۹ نچی دیکابرنده ، تمام بولدی .

طبع ایدلدی قزانده مطبعهٔ کریمیه ده کند مصارفلری ایله ۱۹۰۶ سنه

КАЗАНЬ.
типо-Литографія Торговаго Дома „Братья Каримовы“.
1906.

Шакирҗан Хәмидинең уку китабы

Файдаланылган әдәбият:

1. Мензелинский край: история и современность / Сост.: Ю.Ю.Юсупов, М.Н.Сафиуллин. – М.; 2006. – 497с.

2. Шәрипов И. «Минзәлә» газетасына 95 яшь (Страницы истории). – Минзәлә, 2012.

3. Сарман районы энциклопедиясе. 1 нче, 2 нче китаплар / Төзүче Д.Гарифуллин. – Яр-Чаллы, 2000, 2006 нчы еллар.

4. Старостин А. Судьба забытого джадида: Шакирзян Хамиди. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре[1]

Әхмәдвәли Рәхими

67 Әбү Мәсгуд әл-Әнсари разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Әгәр рөкүгънең[2], сәҗдәнең[3] азагы булмаса, ирнең намазы яраклы булмас».

Укы һәм исеңдә калдыр!

68 Гали кәррамәллаһу вәҗһәһү (Аллаһ аның йөзен хөрмәтләсен) риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Йә Гали, өч әмер кичектерелмичә кылынсын: «Вакыты җитсә, намазны уку; мәет әзер булса, җеназаны уку; тиң сораучы тапсаң, кызны кияүгә бирү».

Укы һәм исеңдә калдыр!

69 Ибн Гомәр разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Намазның әүвәл вакытта укылганы – Аллаһның ризалыгыдыр. Ахыр вакытта укылганы – Аллаһның гафуыдыр».

Укы һәм исеңдә калдыр!

70 Сәһл бине Хисмә разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Берегез алдына сәтрә (пәрдә) куеп намаз укыса, сәтрәсенә (пәрдәсенә) якын булсын. Шайтан намазын бүлмәс».

Укы һәм исеңдә калдыр!

71 Гайшә разыйаллаһу ганһә сөйләгән: «Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам намазга керешсә: «Субхәәнәкәл-лааһуммә уә бихәмдикә уә тәба-арәкәс-мукә уә тәгәәлә җәддукә уә ләә иләәһә гайрук» («Йә Аллаһ, Сиңа дан һәм мактау булсын. Синең исемең мөбарәк һәм дәрәҗәң олугтыр. Синнән башка бернинди Илаһи зат юк»), – дип әйтә иде».

Укы һәм исеңдә калдыр!

72 Әбү Һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Имам башлык булыр өчен билгеләнде. Тәкбир әйтсә, тәкбир әйтегез. Әмма кыйраәт вакытында тик торыгыз».

Дәвамы. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

[1] Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтүль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.

[2] Рөкүгъ – кыямнан соң иелү (бөгелү).

[3] Сәҗдә – маңгайны җиргә, намазлыкка тидерү.

Текстны басмага ***Айсылу Вәлиева*** *әзерләде.*

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

Шәрәф Мөдәррис шигырьләре

Шагыйрь, Чүпрәле районының Түбән Каракитә авылы тумасы Шәрәф Мөдәррис (1919-1963)

Сәгать суга

Шекспирча әйтсәк: вакыт комсыз,
Үтеп китә дөнья рәхәте;
Гүргә кертә бөтен яманлыкны
Мәрхәмәтсез үлем сәгате.

«Кеше өчен кеше – бүре» дигән
Ерткыч закон озак яшәмәс, –
Халык җанын ятлар мыскылламас,
Адәм башын адәм ашамас!

Сәгать суга! Аңлый колбиләүче
Соңгы кабат сулыш аласын, –
Колонияләр, ватан яулап алып,
Утыртырлар ирек агачын!

Сәгать суга! Тиздән җимерелер
Тираннарның сөяк тәхете;
Җилгә тузар коллык хәрабәсе,
Үсеп чыгар халык бәхете.

1959

Бер рәсем

Эх, ничек соң бүген ашкын җанга
Көчле илһам ташып кермәсен?! –
Германиядә утлар аркылганда
Туган яктан алдым бер рәсем.

Рәсем – матур: азрак көлемсерәп,
Бер сылу кыз уйный гармунын;
Салып көйгә җырын – бөтен теләк,
Бөтен җанын, хисен, бар моңын.

Йөзләрендә һич юк кайгы-сагыш,
Нурга тулып, бәхет чәчелгән.
Агыла сыман җанлы, шаулы тавыш
Бу гүзәл һәм җанлы рәсемнән.

Тонса да тик монда колакларым,
Кичергәндә сугыш дәһшәтен, –
Ишетә йөрәк барын – Мозаффарын,
Хәбибуллин, Фәйзи, Сәйдәшен.

Әй син, иркәм, кичеп тугай-кырны,
Аккош булып очып килсәңче...
Җырлар идем мин дә туган җырны,
Тыным бетеп, иренем кипкәнче.

Җырлар идем шунда барын-барын –
Кечкенәдән янган-көйгәнем,
Чит-ят җирдә сөеп-сагынганым –
«Галиябану», «Шахта» көйләрен.

Җырлар идем ярсу йөрәкләргә
Туган илнең матур, саф җырын;
Канны түгеп, данлы көрәшләрдә
Яулап алган җиңү шатлыгын...

Җырлар идем бөтен өметләрнең
Көрәшләрдә чынга чыкканын;
Идел-йортта үскән егетләрнең
Тимер-корыч кебек ныкларын.

Җырлар идем горур арысланның
Тауга каршы ничек чапканын;
Туган шәһәр, туган авылларның
Бакчаларын, урам чатларын...

Ә аннан соң, сузып башка җырны,
Һәр юл саен кушып ис(е)меңне, –
Җырлар идем синең кашларыңны,
Нечкә билең, алсу ир(е)неңне.

1945 ■



Үлемсезлек җырчысы

Нурмөхәммәт Хисамов

Әдәбият галиме, шагыйрь, Чүпрәле районының Мунчәли авылы тумасы Нурмөхәммәт Хисамов

Менә ничә ел инде Каракитә белән Мунчәли арасындагы көмеш чишмә тагын да моңсурак ага сыман. Чишмә буендагы бөдрә талларда, Мунчәли мәктәбенең шәфәкъ алсулыгында янган зур тәрәзәләрендә, хәтта Чүпрәле районында кояшлы иртәне беренче булып сәламләүче Бизнә тауларында да ниндидер сагыш бар. Алар ничә ел инде Казаннан кайтып үзләрен Тукай сүзләре белән сәламләүче нечкә хисле шагыйрьне күрмиләр.

Шәрәф Мөдәррис, туган якка кайтып төшүгә, Тукайның «Туган җиремә» шигыреннән шушы өзекне укырга ярата иде:

«Ул таныш кырлар, болыннар
тартты әүвәл хиссеми;
Тарта торгач, куймады,
кайтарды ахыр җисмеми...»

Бу – шагыйранә як. Ш.Мөдәррис аны гомер буе йөрәгендә йөртте, аның белән горурланды. Әлеге якларның бер үзенчәлеге шунда: аңа Казан белән Сембер яктысы гомер-гомергә тигез төшкән. Мәйданга киләчәк яңа әдәбияттан узган йөздә үк аваз биреп куйган Г.Кандалый, соңрак XIX гасырның күренекле укымышлыларыннан шагыйрь В.Алкаев-Чүпрәли шушыннан чыккан. Ш.Мөдәрриснең «Ленин – безнең якташ» дип горурланырга хакы нигезле иде. Чөнки ул – дөньяга Сембердән күтәрелгән шушы кояш шифасында бөреләнгән талант. Шагыйрь үзен юксынучы туган ягын җырларына кертеп калдырды. Хәзер инде ул үзе – шушы якның горурлыгы.

Шәрәф Мөдәррис... Көндәлек тормышта аралашып йөргән чагында, кайчак моңсу-уйчан, күбесенчә исә шат күңелле, җор телле, хак сүзне кешенең күзенә карап туры әйтүчән бу шагыйрьнең иҗаты поэзия тарихында үзенчәлекле бер дөнья булып калыр дип күз алдына китерми идек шикелле. Инде аның вафатына байтак вакыт узды. Шәрәф Мөдәрриснең бераз каушап, карашын трибуна өстенә төбәп, шигърият турында олы кайгырту белән сөйләгән ярсу чыгышларының инде яңгырамавына, «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы битләрендә тәвәккәл рухлы публицистик мәкаләләре күренми башлауга да инде күнектек. Яшь шагыйрьләрнең талантлы яңа буыны аны бөтенләй күреп белми.

Шагыйрьнең иҗат юлын эзлекле рәвештә күзәтеп чыгу өчен, исән чагында дөнья күргән «Минем яшьтәш» җыентыгына үзенә хас таләпчәнлек белән мөрәҗәгать итәргә кирәк. Анда автор 40 яшькә кадәр иҗат ителгән әсәрләренең иң яхшыларын туплаган. Шәрәф Мөдәрриснең өйрәнчек чоры да, шигъри эзләнүләре һәм җитлегү баскычлары да, яңарак күренешләрнең үрентеләре дә биредә анык чагылыш тапкан.

Шәрәф Мөдәррис – Бөек Ватан сугышының гади солдаты. Аның бөтен язганнарын кырыс чынбарлык сугара, шигырьләренә җимерелгән рус шәһәрләре өчен җан әрнүе килеп керә: Смоленск, Ельня, Русса… Әсәрләренең исемнәре дә – «Землянкада», «Сукыр лампа», «Партизан», «Сапёр», «Корыч каска»…

Шагыйрьнең Ватан сугышы лирикасында үзәк урынны татар халкының ил язмышын хәл итүдәге өлеше, гражданлык һәм сугышчан намусы турында уйланулар алып тора. Аның гармун моңы, курае, Гөлсем Сөләйманова кебек җырчылары, тугрылык саклап, егетен батырлыкка рухландырган сабыр кызлары – барысы да илне яклап-саклап калуга хезмәт итәләр…

Шәрәф Мөдәрриснең киң кызыксынулары аны дөнья әдәбиятының бәрәкәтле хәзинәләренә алып килде. Инглиз телен өйрәнеп, ул Шекспир сонетларын тәрҗемә итәргә кереште. Нәтиҗәсе шагыйрьнең үз иҗаты өчен дә, гомумпоэзия өчен дә зур булды. Татар укучысы кулына бөек инглиз гуманистының зирәк шигъри мирасы килеп керде.

Шәрәф Мөдәрриснең үз шигырьләре дә фәлсәфи тирәнәя, форма ягыннан камилләшә төште. Алай гына да түгел, ул безнең поэзия өчен яңа шигъри форма – сонет өлкәсендә кызыклы тәҗрибәләр ясады. Аның бала туу, аны тәрбияләп үстерү турындагы бер сонетыннан:

«Чикләнсә берзаман юлыңда офык,
Юл ачар ераграк синең яшь онык
Һәм атлар чорларга синең үзеңсез...
Нәрсә бар дөньяда туудан бөек?
Ул яшәр тормышны, ватанны сөеп
Һәм, димәк, мәңгегә син дә үлемсез!» –

дигән юллары фәлсәфи тирәнлеге, гомумкешелек мәгънәсе һәм олы яңгырашы белән Шекспир сонетларына тиңләшә.

Шәрәф Мөдәррис – иҗатка, гомумән, кырыс таләпчәнлек белән караган шагыйрь. Үз-үзенә таләпчән булганга, ул яшьләргә дә, өлкәннәргә дә тәнкыйть сүзен туры һәм ярып әйтүчән иде. Бервакыт Хәсән ага Туфан яшь шагыйрьләр семинарына ике кулына ике китап тотып керде.

– Менә сезгә шигырь техникасы ягыннан үрнәк алырлык, әйбәт рифмалар өлгесе булырлык ике китап, – диде ул.

Аларның берсенә – «Шәрәф Мөдәррис», икенчесенә «Зәки Нури» дип язылган иде. Алар икесе дә – бер районда туып-үскән, бер мәктәптә укып чыккан кешеләр.

Шәрәф Мөдәрриснең сонетка мөрәҗәгать итүе очраклы түгел иде. Шагыйрь бөтен иҗаты буена, нигездә, традицион формаларга таянды…

Шәрәф Мөдәррис – татар шагыйрьләренең Бөек Ватан сугышында катнашкан каһарманнар плеядасы вәкиле. Аның иҗатына шушы хакыйкать аша гына якын килергә һәм тулы аңларга мөмкин.

Вакытсыз үлем поэзияне шагыйрьнең яңа ачышларыннан мәхрүм итте. Ләкин аның иҗат иткән кадәре дә үзенә бер мәгънәви дөнья, кадерле мирас булып кала. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

ӘДИП ХӘЙДӘР ГАЙНЕТДИНОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Хәйдәр Гайнетдинов: «Гел көтмәгән җирдә ява карлар...»

Шагыйрь Хәйдәр (Хәйдәр Гайнетдинов)

Шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче һәм журналист, СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1983) Хәйдәр Гайфетдин улы Гайнетдинов (әдәби тәхәллүсе – Хәйдәр) 1952 елның 27 ноябрендә Татарстанның Зәй районындагы Дүрт Мунча авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң (1970), ул бер ел колхозда эшли, аннары, Казанга килеп, 1971-1976 нчы елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. Хәйдәр Гайнетдинов 1976 елның апреленнән бирле матбугат эшендә була: «Ялкын» журналы редакциясендә җаваплы сәркатип вазыйфасын башкара.

Хәйдәр Гайнетдинов – әдәбиятка җитмешенче еллар башында килгән яңа буын татар шагыйрьләреннән берсе. Шигъри әсәрләре белән ул республика көндәлек матбугатында 1974 елдан бирле катнаша, 1982 елда Татарстан китап нәшриятында лирик шигырьләре һәм бер поэмасы («Иске кара урман») тупланган «Ут теле» исемле тәүге җыентыгы дөнья күрә.

1989 елда Хәйдәр Гайнетдинов Мәскәүдә Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый. 1989-1991 нче елларда – «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй» журналы) газетасының бүлек мөдире, 1991 елдан «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясендә (ГТРК «Татарстан») өлкән редактор һәм алып баручы булып эшли.

Хәйдәр Гайнетдинов укучыларга хикәяләре, очерклары һәм газета-журналларда басылган әдәби тәрҗемәләре аша да билгеле.

Китаплары: «Ут теле» (шигырьләр, поэма, 1982), «Яшел алма» (повесть, хикәяләр, 1987), «Солдат абый» (хикәяләр, 1988), «Су кызы» (повестьлар, 1990).

Хәйдәр Гайнетдинов турында хезмәттәше Эльмира Закирова болай дип искә ала: *«Университеттан соң «Ялкын» журналы редакциясендә без шагыйрь, журналист Хәйдәр Гайнетдинов белән бер бүлмәдә утырып эшләдек. Хәйдәрне студент елларыннан ук беләм. Матур шигырьләр язудан тыш, бик матур итеп җырлый да иде әле ул. Концертларда Илһам Шакиров репертуарындагы җырларны башкара, тавышы да*

Шагыйрь Хәйдәр (Хәйдәр Гайнетдинов) «Салават күпере» журналы редакциясендә. 1990 нчы еллар ахыры.
Л.Лерон фотосы

атаклы җырчыныкына охшаган. (Салих Сәйдәшевнең Таҗи Гыйззәт сүзләренә язган «Җәй айлары» җыры Хәйдәр башкаруында гел Илһам Шакировча яңгырый.) Алай гынамы, аның туганы да дип сөйлиләр. Әйе, Хәйдәр Илһам Шакировның апасының улы булып чыкты. Сарманның (хәзер Тукай районына керә) Яңа Бүләге (Илһам Шакиров туган авыл) кайда да, Хәйдәрнең Зәй районындагы Дүрт Мунчасы кайда, дип аптыраган идем башта. «Авыллар урман аша гына. Әни, кияүгә чыгып, Дүрт Мунчага килен булып төшкән», – дип аңлатты Хәйдәр...»

Хәйдәр Гайнетдинов 2000 елның 23 июлендә үз фатирында фаҗигале төстә вафат булды һәм туган авылы зиратына җирләнде.

Хәйдәр
Узып китте болыт...

Беренче кар алып килермен, дип,
вәгъдә биргән иде ап-ак болыт...
Аңламассың хәзер табигатьне,
табигатьтә хәзер начар холык.

Узып китте болыт, ярылып ята
күмелергә тиеш кайбер эзләр.
Әзерләндек кышка керәбез дип,
күңел хәзер менә аклык эзләр.

Өлгермәгән чакта таралырга
җир өстеннән хәтта алма исе,
кемнең генә килми йомшак карга,
мамык карга ятып тәгәрисе!..

Тәгәрисе килә туган җирнең
яңа гына яуган ак карында,
яумый бит ул менә кирәккәндә,
күңелләрдә шундый уй барында.

Узып китте болыт, яумады кар,
биреп китте бары акыл гына:
ышанычын алды кайберәүнең,
сабырлыклар салды акыллыга
бу табигать!

...Ява кайлардадыр,
гел көтмәгән җирдә ява карлар.
Нәкъ шулай бит кайбер заманнар да!
Әмма кеше үзенең бәхетен табар.

Ашыкмагыз, явар йомшак карлар,
алда әле аунап тәгәрисе.
Көткәндәге кебек булмас ләкин:
таралыр шул инде алма исе... ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

Хаҗ сәфәре

Ләбиб Лерон

Ният иттем изге юлга чыкмакка...

«Көче җиткән кешеләргә, Аллаһыга гыйбадәт кылу өчен, Хаҗ кылу фарыз булды».

(«Гыймран» сүрәсе, 97 нче аять.)

Хаҗга зыярәт – гамәлдә булган, шул ук вакытта рәхәт һәм михнәтле бер фарыз төш ул.

Тәлгат Галиуллин

Кәгъбәтуллаһ

Бисмилләәһир рахмәәнир рахиим.

«Кайбер сүзләрдә – сихер, кайбер шигырьләрдә хикмәт бар». (Хәдис)

Әстерхан кызы, шагыйрә һәм тәрҗемәче Роза Кожевникова-Баубекованың (1930-2007) «Молитва» дигән шигыре бар. Мин шул шигырьгә тәкълид итеп, ягъни ияреп, 1989 елда «Дога» дигән шигырь язган идем:

«Бисмилләәһир рахмәәнир рахиим...»
Тоепмы илаһи көч барын,
Әйтәләр шул сихри тәкъбирне
Йокыга талганда кичләрен.

Шып-шыксыз, кап-кара төннәрдә
Сырхаулап ятканда өйдә мин,
Әнием тибрәтте бишекне:
«Бисмилләәһир рахмәәнир рахиим...»

Дәвамы. Башы журналның 9 нчы (2022) санында.

Хәтерли борынгы заманнар:
Килгәндә куаныч йә кайгы,
Айга шул сүзләрне пышылдап,
Ничәмә иреннәр ялварды...

Кайвакыт шикләнеп куйсаң да,
Юк, диеп, гайре көч – илаһи,
Үзең дә сизмәстән әйтәсең:
«Бисмилләәһир рахмәәнир рахиим...»

Ул елларда бу шигырь, җыруга әйләнеп, тумышы белән Кукмараның Битләнгур авылыннан булган җырчы Нурәхмәт Мөхәммәтҗанов (1963-2006) башкаруында берара радиодан да яңгырап алган иде.

Мин нигә бу шигырьне исемә төшердем? Шушы шигырьне язганнан соң, язылачак һәрбер яңа әсәремне «Бисмилләһ...» дигән изге сүзләрне язып куюдан башладым...

Сүз башым бит шүрәле, дигәндәй...

Ниһаять, сәфәр көне килеп җитте.

Әүвәлтен, көндәлегемнең эчтәлеген сезнең хозурыгызга җиткерер алдыннан, төрле вакытларда, ягъни төрле чорларда, төрле елларда хаҗ сәфәрендә булган кайбер шәхесләребезнең изге юлга кузгалу көнен бәян иткән язмаларына күз төшереп алыйк әле.

Мәшһүр дин галиме, мәгърифәтче һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889)

«Һиҗри 1297 елның Рамазан аеның 17 нче көнендә (милади 1880 елның 11 нче августында), иртәнге намаздан соң, Мәккәгә юл алып, Казаннан аерылдык. Пароход белән Нижнийга килдек. Аннары тимер юл белән Мәскәү, Курск һәм Киев шәһәрләрен узып, Одессага килеп җиттек. Бу арада дикъкать итәрлек бер хәл булмады. Казан белән Одесса арасы 2385 чакрым чамасы булыр. 25 нче Рамазан – Одессадан Истанбулга юнәлдек...» – дип башлаган үзенең хаҗ сәфәрен мәшһүребез – дин галиме, мәгърифәтче һәм тарихчы **Шиһабетдин Мәрҗани** (1818-1889).

Атаклы ишан, күрнекле дин әһеле, Троицк өязенең Туңгатар волостендагы Шәрип авылы (хәзерге Башкортстанның Учалы районында) тумасы Зәйнулла Рәсүлев (1833-1917)

Атаклы ишан, күренекле дин әһеле, Троицк өязенең Туңгатар волостендагы Шәрип авылы (хәзерге Башкортстанның Учалы районында) тумасы **Зәйнулла Рәсүлев**ның хаҗга бару тарихын яшь галим, Троицк каласы мәчетенең имам-хатыйбы Данис Әхмәтшин (тумышы белән Троицкидан) үзенең «Ушедшая история, но оставшаяся в наших сердцах» китабында (Казан, «Иман» нәшрияты, 2020) болай сурәтли: *«Җәппәс ыруыннан Ях-*

шымбай исемле бер казакъ бае вафат булгач, аның өчен хаҗ кылуын сорап, Зәйнулла хәзрәткә мөрәҗәгать итәләр, Мәрхүмнең туганнарыннан 1 мең сум акча алып, ул шунда ук сәфәр чыга. Бу һиҗри буенча 1285 елда, ягъни 1869 елда була. Шул елның 18 августында утыз алты яшьлек Зәйнулла хәзрәт Истанбулга килеп җитә һәм суфый-шәех ***Әхмәд Зыятдин әл-Гөмешханәви*** *(1833-1893) белән таныша. Төрек шәехенең киңәш-тәкъдиме белән булса кирәк, Зәйнулла хәзрәт җир астында корылган бүлмәдә, көн саен Аллаһ исемен 100 мең мәртәбә кабатлап, кырык көн ялгызы ураза тота. Шуннан соң ул бертуганы Фәтхулла хәзрәтнең улы Муса Рәсүлев (1838-1904) белән бергә Истанбулдан Мәдинәгә юл тота һәм зөлхиҗҗә аеның 2 нче көнендә алар Мәккәгә килеп җитә...»*

Суфый-шәех Әхмәд Зыятдин әл-Гөмешханәви (1833-1893)

1906 елның җәендә танылган дин эшлеклесе, галим, мәгърифәтче, Тәтеш өязенең Морзалар авылы (хәзерге Апас районында) тумасы **Нургали хәзрәт Хәсәнов** (1852-1919) хаҗ сәфәренә кузгала. Сәфәр вакытында ул, Мәскәү, Петербург, Бакчасарай, Одесса, Истанбул, Бурса, Родос, Дәмәшекъ, Бәйрут, Мәдинә, Мәккә, Җиддә һ.б. калаларда була, Төркиянең башкаласы Истанбулда ул Госманлы империясенең җитәкчесе, мөселманнарның танылган хәлифе, солтан Габделхәмид II белән очраша. Н.Хәсәновның хаҗга сәфәрен әлеге олуг шәхескә нисбәтле китабында («Дин галиме Нургали Хәсәнов», Р.Амишов. Казан, 2022) яшь галим, мөгаллим, тарих фәннәре кандидаты Рәшит Амишов болай дип шәрехли: *«Хәлиф аңа, зур галим, мөхтәрәм кунак буларак, иң югары хөрмәтен күрсәтә. Аның чакыруы буенча, Нургали хәзрәт Рамазан аен солтан сараенда үткәрә. Аңа пәйгамбәрләрнең борынгы заманнардан сакланган шәхси әйберләрен, тарихи урыннарны, мөһим уку йортларын, китапханәләрен күрсәтәләр. Моның өстенә, солтан аңа, ислам дине үсешенә керткән зур хезмәте өчен, иң югары дәрәҗәдәге дәүләт ордены бирә һәм хөкүмәт делегациясе составында олы хаҗ сәфәре белән бүләкле. Мәдинәдә аны, солтанның мөхтәрәм кунагы буларак, Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) каберенә, Әбү Бәкер һәм Гомәр җирләнгән урынга (төрбәгә), ә Мәккәдә изге Кәгъбә эченә кертәләр...»*

Дин эшлеклесе, галим, мәгърифәтче, Тәтеш өязенең Морзалар авылы (хәзерге Апас районында) тумасы Нургали хәзрәт Хәсәнов (1852-1919)

Дин белгече, галим, мәгърифәтче, нашир, журналист, Әстерхан тумасы Габдерахман Гомәри (1867-1933)

1926 елда (7 июнь-5 июль аралыгында) Мәккә шәһәрендә Бөтендөнья мөселманнары конгрессы булып уза. Согуд Гарәбстаны короле Габделгазиз ибн Габдерахман әл-Согуд чакыруын алган делегатлар арасында Совет Россиясеннән

һәм Төркестаннан сигез мөселман кардәшебез (алар – Ризаэддин Фәхреддин (делегация башлыгы, 1859-1936), Кашшафетдин Тәрҗемани (башлык урынбасары, 1877-1943), **Габдерахман Гомәри** (сәркатип, 1867-1933), Мәрҗани мәхәлләсе имам-хатыйбы Таһир Ильяси (сәркатип ярдәмчесе, 1881-1933), Муса Бигиев (1875-1949), Себердән казый Мәһди Мәгъкули (Петропавловск мәчетенең имам-хатыйбы, туган һәм вафат булган көннәре билгесез), Кырым мөфтие Мөсләхетдин хәзрәт Хәлили (аның турында мәгълүмат юк) һәм Ташкенттан Габделвахит хәзрәт Кариев (1855(59)-1937) та була. Әлеге мөһим вакыйганы яктырткан язмалардан бары тик Г.Гомәринең юлъязмасы гына сакланган. Танылган дин белгече, галим, мәгърифәтче, нашир, журналист, Әстерхан тумасы Габдерахман Гомәри бу конгресска ничек барулары, шунда чакта барлык делегатлар белән Хаҗ гамәлләрен кылулары хакындагы әлеге юлъязмасында (иске татар телендә язылган) Истанбулдан Мәккәгә кузгалуларын шушы рәвешле теркәгән: *«Ходио» ширкәтенең «Фамака» пароходына билетлар сатып алып, 26 май көнне (1926) Истанбулдан Җиддәгә таба кузгалдык. Без сигезәү идек, әмма беребез – Муса әфәнде Бигиев, таможня тикшерүен уза алмау сәбәпле (аның Мисыр илчелегеннән бирелергә тиешле рөхсәт кәгазе юк иде), ул Истанбулда калды һәм без сәфәрне җидебез генә дәвам итә алдык...»*

Бөтендөнья мөселманнары конгрессы делегатлары Мәскәүдә. Сулдан уңга: Мәскәүдәге икенче Җамигъ мәчетенең имам-хатыйбы Габделвәдүт Фәттахетдинов, мөфти Ризаэддин Фәхреддин, казый Кашшаф Тәрҗемани. Артта (Р.Фәхреддин һәм К.Тәрҗемани арасында) – Зур Татар урамындагы беренче Җамигъ мәчетенең имам-хатыйбы Габдулла Шәмсетдинов

Язучы һәм әдәбият галиме, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2019) **Тәлгат Галиуллин** үзенең «Хаҗга зыярәт шәхси эшме?» дигән язмасында («Дәгъва» китабы, 1995), Хаҗ сәфәренә кузгалуын (1993 елның 25 мае) болай дип искә төшерә: *«Даны зәңгәрсу томанлы риваятьләргә төрелгән ерак гарәп иленә бару мөмкинлегенә берәү дә ышанмый башлаган иде инде. Ник дисәгез, хаҗга зыярәт кылырга теләүчеләрнең исемлеге төзелеп, яңа чит ил паспортлары тутырылып, ихрамнар, намазлыклар, сөлгечынаяклар әзерләнеп беткәч, «сәяхәт барып чыкмаячак, Согуд Гарәбстаны безне кабул итүдән баш тарткан, Татарстан Президенты диндарларга ярдәм сузарга әзер, әмма кул астында акчасы юк икән, анда барачак самолетка мазут табылмаган» кебек тузга язылган хәбәрләр яшен тизлеге белән безгә килеп җитте. Барысы да Ходай Тәгалә кулында, кәгъбәгә бармаганнарның да йөрәге тибә бит әле, язмыштан узмыш юк, эш тә күп, хәерле булсын, дип тәмам тынычланып калган идек, шундый ук җәһәтлек белән икенче яңалык ирешә: виза да бар, акча да бирелгән, самолет та 25ендә иртәнге биштә очып чыгарга әзер икән.*

Совет делегациясе мөселманнары. Сулдан уңга: Г.Гомәри, К.Тәрҗемани, Р.Фәхреддин, Т.Ильяси. Икенче рәттә сулдан уңга: М.Хәлили, М.Мәгъкули, Г.Кариев. 1926 ел

Ат-хат җитмәс юлга чыгар алдыннан әзерләнәсе дә бар. Аттым-бәрдем, киттем-бардым гына чыгып китә алмыйсың. Туарылган чемоданнарны, сумкаларны ашык-пошык тутырып, табигый ки, иң кирәкле нәрсәләрне онытып, Казан-2 аэропортына йөгердек. Адәм баласына уйланырга бик аз вакыт бирелде. Чынында исә Татарстанда үткәрәсе вакытыбыз шактый булып чыкты. Алмасы артыннан тормасы көттермәде....

Шулай да кичке бишкә Сочига килеп җиттек...»

Икенче бер каләмдәшем – язучы, тарихчы галимә **Фәүзия Бәйрәмова**ның «Тәгәри китте йомгагым...» дип аталган хаҗнамәсендә изге сәфәргә кузгалуын тасвирлавына тукталыйк:

«1998 ел, 27 март.

Ниһаять, без күктә. Көне буе Казан аэропортында самолет көтеп ятканнан соң, без, Хаҗга баручылар, кыйблага таба очып киттек. Җомга, икенде, ахшам намазларын Казан аэропортының таш идәннәренә тезләнеп укыган идек, ястү намазын укырга самолетта әзерләнәбез...

Без бу самолетта Хаҗ сәфәренә 160лап кеше очабыз. Күренеп тора – хатын-кызлар күбрәк. Бездән башка тагы 200ләп кеше очачак икән, алар Корольнең кунаклары булачак, ди, гарәпләр Татарстанга, татар халкына шундый зур бүләкләр ясаган...

Шушындый озын юлга тәвәккәләп сәфәр чыккан бу апа-абзыйларга карап, күңел тула... Безнең бу төркемдә дин әһелләре, исемле, билгеле кешеләр, язучы-галимнәр, интеллигенция юк дәрәҗәсендә аз. Биредә – үз хисапларына Хаҗ кылучы ихлас мөселманнар, гади, бөек кешеләр...

Бу Хаҗ сәфәренә кайбер шәһәрләрдән төркем-төркем булып, бик зур әзерлек белән килгәннәр. Әлмәттән Наил хәзрәт җиткәчелегендә 27 кеше Хаҗ сәфәренә чыккан, алар гел бергә, киңәшләшәләр, ярдәмләшәләр... Түбән Камадан да егермегә якын кеше бергә тупланып юлга чыккан, аларны Түбән Камада тәкбирләр әйтеп, намазлар укып, Казанга хәтле зур автобус белән озатканнар. Ә без, чаллылылар, урык-сурык, аерым-аерым, таксилар тотып килдек. Чаллыдан без 12-13 кеше булырга тиешбез...

Төне буе самолетта очтык. Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә туктап, ягулык алдык, аннары тагы очып киттек. Ястү, витр намазларын самолетта укыдык...

Менә без Җиддә аэропортына якынлашабыз...»

Төрле шәхесләр тарафыннан хаҗнамәләр язылу тарихын җентекләп өйрәнгән һәм 1698 елда татар әдәбиятында үзенчәлекле бер жанр – хаҗнамә барлыкка килүен һәм әлеге хаҗнамәнең күренекле якташы, нәсел чыгышы Тәтеш ягыннан булган Мортаза Гали бине Котлыгыш әс-Симети әл-Казани тарфыннан язылган булуын ачыклаган журналист һәм язучы **Тәлгат Нәҗмиев** (1950-2014) «Изге гамәл җиңел гамәл түгел» дигән язмасында олуг сәфәргә кузгалуын шушы рәвешле сүрәтли: *«2 октябрь көнне (2013. – Л.Л.) өйлә намазы алдыннан Казан аэропортына җыйналдык. Универсиада алдыннан «Халыкара» дигән статус алган заманча терминалларны күргән булмаган икән әле. Алда бирелгән программада Казан-Җиддә һава юлы буенча очу планлаштырылган иде. Соңрак Дубай аша барачагыбыз игълан ителде. Җитәкче имамыбыз Рамазан хаҗи Хисаметдинов Саба кияве булып чыкты. Аның икенче баруы икән инде. Башкортстанда туып-үскән Радик (паспорттагы исеме шулай) Казандагы Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исмендәге мәдрәсәне армиядән соң тәмамлый (хәзер Россия ислам институтында югары белем ала). Аннары «Кулон» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Альберт*

Фәхретдинов соравы буенча Балык Бистәсенең Яңавыл авылына имам булып кайта. Бу Альберт Шамил улының туган авылы икән, ул Яңавылга мәчет салдыра, мулла өчен йорт-җир җиткерә, хезмәт хакы билгели. Хәзер дә бар бит иманлы-игелекле меценантлар...

Менә 22 кешелек төркемебез тупланып бетте. Озатырга «ДУМ РТ Хадж» җәмгыяте вәкилләре дә килгән иде. Алар безгә визалы чит ил паспортларыбызны тараттылар. Аэропортның өченче катында бөтен уңайлыклары белән ирләр һәм хатын-кызлар өчен аерым намаз уку бүлмәләре ачканнар икән...

...Менә без күктә, унбер мең чакрым биеклеккә күтәрелеп, кыйблага таба очып киттек. Очкычның тизлеге сәгатенә 777 чакрым, салкынлык 56 градус күрсәтә. Һәркем үз уй-хисләренә чумган. Булачак хаҗи-хаҗияләр Алладан сабырлык, ныклы иман, ихласлык, саулык-сәламәтлек сорый... Мәккәгә кадәр 3000 чакрым, диләр... Дүрт тапкыр күккә күтәрелеп төшәсе бар...»

Инде килеп, ошбу юлларның авторы язган көндәлеккә күчик. Тышлыгына зәңгәр өчпочмаклар төшерелгән шакмаклы 96 битле гомум дәфтәр шушы язу белән ачыла: «Аллаһы ризалыгы белән, 2022 елның 1 июлендә Казан вакыты белән кичке 22:00дә Истанбул аэропортында ошбу көндәлекне башладым. Ниһаять, сәфәр көне килеп җитте.

Иртәнге 5:00дә телефондагы будильник шылтырады. Өстә – ак чалбар, кыска җиңле шакмаклы күлмәк. Аякта, кем әйтмешли, «чабата».

6:00дә, юлга кузгалыр алдыннан, «Фатиха» сүрәсен укыдым, хатыным Фидания кабатлап барды.

Такси чакырттым. «Кио-Рио» машиансында җилдереп, ярты сәгатьтән Казан аэропортында идем инде. Бина эченә узып, сак хезмәте аша тикшерелү үткәч, Әгерҗедән килгән бер кардәш белән (Ришат хәзрәт исемле әлеге сәфәрдәшем белән без һәрбер кунакханә номерында бергә туры килеп, һәммә җирдә бергә булачакбыз) бергә лифтта өченче катка күтәрелдек.

Таныш йөзләр күзгә чалына башлады: Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин (хатыны һәм улы белән), Татарстан Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте җитәкчесе Резеда Закирова (аның белән без, журнал редакциясе, даими элемтәдә), Исламны кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә мөгалимме Азат хәзрәт Шәфыйков, Балтач мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт Бикбаев...

Минзәләнең Бикбау авылы тирәсендәге бер авылдан булган

Изге сәфәргә кузгалыр алдыннан «Гаилә» мәчетенең имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин һәм Ләбиб Лерон Казан аэропортында. 1 июль, 2022 ел

Юл догасын укыган чак. Казан аэропорты. 1 июль, 2022 ел

иптәш (Мөхәммәт Мәһдиев әйтмешли), мине танып, яныма килеп күреште, рәхмәт төшкере.

Дини җырлар җырлаучы, мөнәҗәтче Ильяс Халиков белән күрештек. Ул кемнедер озатырга килгән иде.

Бераздан мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин килеп җитте. Күрештек. Мөфтине озатырга беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов (Кама Тамагы районы тумасы) килгән иде. Узган елның апрель аенда, Илфар хәзрәтне мөфтинең беренче урынбасары итеп тәгаенләгән вакытта, баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев: «Мөфти урынбасары түгел, ярдәмчесе булырга язсын!» – дип әйткән иде. Шул искә төште.

Догалар укылды. Юл букчалары тәртипкә китерелде. Фотоларга һәм видеоларга төшелде. Мөфти хәзрәтләре изге сәфәргә чыгучыларга хәерле, имин сәфәр теләде.

Мөфти белән кабат сөйләшеп торган чакта, яныбызга Ильяс Халиков килде дә, хәзрәткә карап:

– Тукай премиясе алган язучының шул ук елны хаҗ сәфәренә барырга җыенуын беренче мәртәбә күрәм! – диде. Мөфти хәзрәтләре, башын кагып, елмаеп куйды…

Регистрацияне әйбәт кенә уздык. Беренче каттагы буфет сыман җирдән 280 сумга бергамотлы чәй сатып алдым да, икенче катка күтәрелеп, тимер-калайдан ясалган эскәмиягә утырып, Фиданиягә шылтыратып алдым.

Җәлил хәзрәт Фазлыевның ярдәмчесе дә безнең белән бергә юлга чыккан икән. Ул төркемебезнең җитәкчесе Габбас хәзрәткә бик булышты.

Очкыч күккә күтәрелер алдыннан гына үзем Казан аэропортында төшергән фотосурәтләрне һәм видеоларны соцчелтәргә куеп өлгердем…

Теле…

(Ошбу урында язудан бүленеп тордым: Равил хәзрәт Бикбаев белән Азат хәзрәт Шәфыйков, яныма килеп, гәпләшеп торды.

– Сәфәребез турында язасыңдыр инде? – диделәр егетләр.
– Әйе, – дидем, – вакытында теркәп куймасаң, күбесе хәтердән җуела…
– Язмаңа безне дә кертәсеңме соң? – диде Азат хәзрәт.
– Әлбәттә! – дидем.

Мәдинәгә очарга тиешле очкычыбыз сәгать ярымга кичектерелә икән – монысы бер дә әйбәт түгел әле…)

…Телефон Истанбул аэропортында тотмый.

Казаннан көндезге 11:25тә кузгалган идек, Истанбулга 16:15тә килеп төштек. Очкычта урыным 25А иде. Рөстәм хәзрәт Хәйруллин миннән алда – 23 нче рәттә, Рамил хәзрәт Бикбаев алардан ике-өч рәт алдарак утырды.

Истанбул аэропортында Рафил кардәшем Ситтигуллин белән таныштым. Ул, Әтнә районының Өҗем авылыннан булып, шул авыл мәчетенең имам-хатыйбы вазыйфасын башкара икән. Аның белән якындагы буфет сыман җирдә ике тапкыр чәйләп алдык. Уртак танышыбыз – Әтнә муниципаль районы хакимияте башлыгы Габделәхәт Хәкимовны искә төшереп, үзебез белән дә бәйле вакыйгаларны хәтердә яңарттык.

Аэропортта махсус бүлмә бар икән – намаз уку өчен. Сәгать кичке ун тулып киткәч, шул урынга ястү намазына бардым – илледән артык кеше җыелдык.

Истанбул аэропорты (яңа аэропорт икәнен соңыннан гына белдем, искесендә булганым бар иде) галәмәт зур – очына чыга торган түгел.

Истанбул аэропортында. 1 июль, 2022 ел

Телефонга вай-фай кушкач кына бер сәгать элемтәдә булып алдым – соцчелтәргә берничә фото-текст куйдым.

Казаннан очкан чакта һәрбер утыргыч артына куелган экранга игътибар иткән идем. Үземнең каршыдагысыннан очыш вакытын күрсәткән картадан карап шуны белдем: Казаннан очканда башта Әстерханга таба туры, аннары туксан градус кырт борылып, Грузия (Тбилиси, Батуми) кырыннан юл алып, Төркиянең Самсун һәм Кастамону шәһәрләре (икесендә дә эшлекле сәфәрдә булганым бар) яныннан үтеп, Истанбулга (аэропортына) барып җиттек. Биеклек күпчелек 9730 чакрым булды. Элек Истанбулга өч сәгать очканнар, безнең очу исә биш сәгатькә сузылды – илдәге вазгыять аркасында…

Мәдинәгә сәгать 2:20дә очып китәргә тиешбез…» ■

Истә, һаман да истә!

Язучы Гали Рәхимнең тууына 130 ел

Язучы, әдәбият тарихчысы, тәнкыйтьче Гали Мөхәммәтшакир улы Рәхим (Габдерәхимов) 1892 елның 4 ноябрендә Казанда II гильдия сәүдәгәр гаиләсендә туган.

1909 елда «Җир йөзе» дигән беренче фәнни-популяр жанрдагы китабы дөнья күрә. Ул – «Җанвар» (пьеса), «Бер шагыйрьнең өйләнүе» (хикәя) һәм «Идел» (повесть) авторы.

Гали Рәхим фәнни эш белән дә шөгыльләнә («Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә», «Татар әдәбияты тарихы» (Г.Газиз белән бергә язылган), «Утыз еллык хезмәт», «Беренче тюркология корылтае һәм аның тикшергән мәсьәләләре»).

1930 нчы елларда Гали Рәхим ике тапкыр хөкем ителә. Ул 1931 елның 8 маенда кулга алына, 1932 елның 11 маенда ОГПУның махсус коллегиясе аны 5 елга концлагерьгә җибәрә. 1937 елның июлендә исә ул кабат тоткынлыкка эләгә. Ике еллап төрмәдә тоткач, 1940 елда аны 8 елга хезмәт белән төзәтү колониясенә озаталар. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, 1943 ел башында ул вакытыннан алда ирекккә чыгарыла.

Гали Рәхим 1943 елның 3 мартында Казанда вафат булды.

Артист Барый Тархановның тууына 130 ел



Актер, режиссер, ТАССРның атказанган артисты (1926) Барый Тарханов (Барый Шиһабетдин улы Гаффаров) 1892 елның 5 ноябрендә Сембер губернасының Сембер өязендәге *(1920 елдан – Буа кантоны, 1938 елдан – Олы Тархан районы, 1959 елдан – Тәтеш районы)* Олы Тархан авылында *(кайбер чыганакларда – Сембер шәһәрендә)* туган.

1908 елда ул «Сәйяр» труппасында уйный башлый. Инкыйлабка кадәр «Нур» труппасында (Уфа) эшли. 1916 елда Сембердә «Ирек» татар артистлары коллективы (инкыйлабтан соң «Кызыл йолдыз») исеме астында татар драма труппасын оештыра (труппа 1921 елда таркала). Әлеге труппада төрле елларда К.Тинчурин, Т.Гыйззәт, К.Нәҗми, Ф.Йосыпова, С.Булатов һ.б. уйный.

Барый Тарханов 1924-1926 нчы елларда – Буа театрында сәнгать җитәкчесе. Шул ук елда ул хөкүмәт биргән 12 мең сум акчага театр өчен махсус бина салдыра.

Барый Тарханов 1933 елда вафат булды.

Шагыйрь Хатыйп Касыймның тууына 90 ел

Шагыйрь, 1993 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Хатыйп Касыйм (Хатыйп Касыйм улы Исрафилов) 1932 елның 15 ноябрендә Татарстанның Түбән Кама районындагы Болгар авылында туган.

1990 елда ул, инженерлык эшен калдырып, Түбән Камада чыга торган «Туган як» газетасы редакциясенә әдәби хезмәткәр булып эшкә күчә. 1991 елда «Ак чишмә» исемле беренче мөстәкыйль китабы басылып чыга.

«Кичке моң» (2001), «Мин җирдә калам» (2004), «Ак болытка орынам» (2006) дигән китаплар авторы.

Хатыйп Касыйм 2009 елда вафат булды.

Җырчы Ренат Ибраһимовның тууына 75 ел

Җырчы, РСФСРның, ТАССРның һәм Каракалпак АССРның халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Ренат Ислам улы Ибраһимов 1947 елның 20 ноябрендә Украина ССРның Илбау (Львов) каласында туган.

Ул музыка мәктәбендә домра классында белем ала, кечкенәдән үк классик арияләр һәм җырларны җырлап үсә. Ренат Ибраһимов Казан дәүләт консерваториясендә икеллык әзерләү бүлегендә укыганнан соң, вокал бүлегенә укырга керә. Җырчы М.Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли, эстрадада да чыгышлар ясый. Төрле конкурсларда лауреат исемен ала.

Ренат Ибраһимов 2022 елның 14 маенда вафат булды.

Җырчы Зөләйха Хисмәтуллинаның тууына 100 ел

Җырчы, педагог, профессор, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Зөләйха Гатаулла кызы Хисмәтуллина 1922 елның 22 ноябрендә Казанда туган.

Башлангыч музыкаль белемне ул Казанның 1 нче балалар музыка мәктәбендә ала. Зөләйха Хисматуллина 16 яшендә радиокомитетның вокал ансамблендә җырлый башлый. Ул вакытта радиода музыкаль редактор булган Җәүдәт Фәйзи киңәше буенча, 1940 елда ул Ленинград дәүләт консерваториясе каршындагы музыка училищесына керә.

1945-1974 нче елларда Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында солист булып җырлый.

1950 елда ул Казан консерваториясен тәмамлый. 1961 елдан Казан консерваториясендә укыта башлый.

Зөләйха Хисмәтуллина 1994 елда вафат булды.

*Сахифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Халык җырчысы

Алсу Хәкимова



Габдулла Мөхәммәтгалим улы Рәхимкулов

«Бер гүзәлен сагынам чишмәнең», «Арча кичләре», «Балкый Шәйморза утлары», «Кайтыгыз, торналар», «Керфегеңә тамармын мин» һәм башка җырлар – халкыбызның яраткан җырчысы, Татарстанның халык артисты Габдулла Рәхимкулов башкаруында тамашачы күңеленә, хәтеренә кереп калган җырлар. Аларны тыңлаганда җырчыны искә алабыз. Әйе, күп кенә җырларны популярлаштырган, халык мәхәббәтен казанган җырчыларны башкарган әсәрләре дә гомерле итә, алар халык хәтерендә башкарган җыр-моңнары белән яши. 2012 елда Г.Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясендә Габдулла Рәхимкуловны искә алу кичәсе уздырылган иде. Фойеда җырчыга багышланган күргәзмә дә оештырылды. Габдулла Рәхимкуловның Самарада яшәүче оныгы Айрат белән дә шунда таныштык. Әлеге кичәне оештырып йөрүче егет шул чакта күргәзмәдә кулланырга дип бабасының кайбер фоторәсемнәрен дә тапшырды. Алар хәзер музей архивында саклана. Җырчының бакыйлыкка күчүенә быел октябрь аенда 25 ел булды. Аның тормыш һәм иҗат елларын искә алыйк...

Габдулла Мөхәммәтгалим улы Рәхимкулов 1926 елның 18 маенда Татарстанның Чүпрәле районындагы Кече Шәйморза авылында күп балалы гаиләдә туып-үсә. Әтисе авылда 23 ел буе колхоз рәисе булып эшли. Кечкенәдән җырларга яраткан Габдулла мәктәптә укыганда төрле үзешчән сәнгать чараларында актив катнаша.

1943 елда унҗиде яшендә ул армиягә алына, Одесса-Харьков юнәлешендәге фронтта ил чигендә хезмәт итә. 1944 елда аны Молдавиянең Измаил шәһәреннән Батумига күчерәләр һәм ул анда хәрби җыр һәм бию ансамблендә җырлый башлый, 70-80 кешедән торган бу танылган ансамбльдә солист буларак та чыгыш ясый. Җиде ел хезмәт иткәннән соң, ул Магнитогорск шәһәренә кайта һәм, училище тәмамлап, тау токымнарын шартлатучы горняк-мастер таныклыгын ала һәм шахтада эшли башлый. Габдулла Рәхимкулов биредәге татар җыр һәм драма түгәрәгенә язылa, аңа йөрүчеләр катнашында төрле концертлар оештырыла. Ул елларда күренекле җырчы Рәшит Ваһаповның Магнитогорскида берничә мәртәбә концерты була. Шунда Рәшит Ваһапов, Габдулла Рәхимкуловның җырлавын ишетеп: «Синең урының – профессиональ эстрадада!» – дип, Казанга чакыра...

Шулай итеп, ул 1954 елда Казанга кайта, Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенә – Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле хорына кабул ителә. Габдулла Рәхимкулов тора-бара хорда солист буларак та чыгыш ясый башлый, аның иң беренче башкарган җыры – татар халык җыры «Сарман» була. Җырлап бетергәч, тамашачы, Габдулла Рәхимкуловны көчле алкышлап, аны кат-кат сәхнәгә чакыра. Ул җыр хәтта үзенә кызыклы кушамат булып тагылып та кала. Сәхнәдәшләре аны, эшкә килгәч: «Безнең «Сарманский» килде. Кәефләр ничек, «Сарманский»? – дип шаяртып каршы ала торган булганнар.

Габдулла Рәхимкулов Татарстан радиосында да җырлар яздыра башлый. Шул чакта Гөлсем Сөләйманова, аны ишетеп: «Энем, син бигрәк моңлы җырлыйсың инде, әллә үзең башкорт баласымы? Киләчәктә дә шулай җырла. Кеше сүзен тыңлама, тавышыңны бозма. Синең күкрәгең бик киң, сулышың тирән...» – ди.

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле белән гастрольдә. Уңнан бишенче – Г.Рәхимкулов. Казакъстан. 1955 ел

Әле кайчан гына тормышның төрле михнәтләрен кичергән эшче егеткә, чын профессиональ җырчы булып танылганчы, сәнгать юлында күп киртәләрне үтәргә туры килә. Мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакировның Габдулла Рәхимкулов турында язган истәлегеннән бер өзек моңа мисал булып торадыр: *«1955 ел. Режиссер Сәет ага Булатов, Габдулла белән мине радиокомитетка чакырып, болай ди: «Егетләр, мин бер радиоспектакль әзерлим, шунда сезнең җырлавыгыз кирәк». Без инде ишек төбендә дер калтырап торабыз. Сәет аганың кыяфәте дер калтырата торган иде шул. Радиоспектакль булды, җырладык. Менә шуннан соң Габдулла Рәхимкуловның авазы халык колагына керде дә инде...»*

Измайлов паркы. Мәскәү. 1969 ел

1961 елда ул Алма-Атага «Казахконцерт» оешмасына эшләргә чакыру ала, анда бер ел эшләү аралыгында тамашачы аны яратып өлгерә, концертлар гел тулы заллар белән үтә. Язмыш аны янә Казанга кайтара, 1962 елда аның уңышларын читтән күзәткән Филармония директоры Х.Ә.Калинина Габдулла Рәхимкуловны Татар филармониясенә чакыра, бу вакытта Рәшит Ваһапов авырып китү сәбәпле, аңа алмашка тиз арада җырчы табарга кирәк була. Шулай итеп, ул эстрада бүлегендә эшли башлый, тора-бара үзенең концерт төркемен оештыра.

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләү чорында, танылган җырчылар Р.Тимерханова, Җ.Сәлахова, Д.Сираҗетдинова, Ф.Сөләйманова һәм башка җырчылар белән бер бригадада эшләп, Габдулла Рәхимкулов озак еллар халкыбызга хезмәт итә. Ул сәхнәдәшләренә дә, үз иҗатына да бик таләпчән карый, яңа җырлар өйрәнә, онытыла башлаган көйләрне табып, аны үз репертуарына кертә. Көне-төне җыр өйрәнеп торырга әзер иде, дип искә алалар Габдулла Рәхимкулов хакында сәхнәдәшләре. Мәсәлән, халык арасында бик популяр булып киткән «Зәңгәр төймә» дигән җырның язылуы да аның катнашында була. Фәйзи Садыйков репетиция вакытында әлеге җырның көен уйнап җибәрә, ул аны кайдандыр ишетеп отып алган була, авторын белми, сүзләре дә юк булып чыга. Габдулла Рәхимкулов, тиз арада телефон будкасыннан Гөлшат Зәйнашевага шалтыратып, шул көйне көйләп бирә һәм шуңа сүзләр кирәк булуы турында әйтә. Күп тә үтми, шагыйрьгә сүзләрен язып китереп, әлеге җыр дөньяга чыга. Яраткан композиторыбыз Сара Садыйкова да күп җырларын нәкъ аның тавышына туры китереп язган. Җырчы аларны иң беренче булып сәхнәләрдән башкара, бу җырлар халык күңелендә иң матур аһәңнәр булып яңгырап яши. Сара Садыйкова аңа, үз итеп – «Апушым», Габдулла Рәхимкулов исә аңа «Сарушым» дип дәшә торган була.

Габдулла Рәхимкуловка 1972 елда «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелә. Аның концерт бригадасы республикабыз шәһәрләрендә һәм авылларында бик күп концертлар бирә. Халык соравы буенча, хәтта бер авылда

Рәсемдә (уңнан сулга): Әлфия Авзалова, Борис Андреев, Габдулла Рәхимкулов. «Сәнгать бәйрәме». 1975 ел

гына да икешәр-өчешәр концерт куярга туры килә аңа. Җырчының тавышы, республикабыздан тыш, илебезнең төрле сәхнәләрендә яңгырый. Илнең кайсы почмагында гына булмасын – Урта Азиядәме, Себер киңлекләре яки Урал таулары артында урнашкан шәһәр һәм авыллардамы – татар һәм төрки халыклар яшәгән барлык җирләрдә дә аны үз итеп, шатланып каршы алалар.

1979 елда лаеклы ялга чыкса да, Габдулла Рәхимкулов әле тагын унбиш ел буе үзенең концерт төркеме белән республика буйлап чыгышлар ясый. Халык мәхәббәтен казанган җырчыга «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исем 1996 елның 21 февралендә генә бирелә. Халкына күпме хезмәт куйган, трактор арбаларында авылдан-авылга йөреп, салкын клубларда чыгыш ясап милләттәшләребезгә моң өләшкән җырчы, гомеренең ахырында гына рәсми рәвештә бу исемгә лаек була, гәрчә, аны яраткан тамашачысы күптән шулай атап йөрткән булса да.

Габдулла Рәхимкулов 1997 елның 8 октябрендә язучыларның Г.Тукай клубында соңгы тапкыр чыгыш ясый – Әхәт Сафиуллинның юбилей кичәсендә җырлый. Ул икенче көнне кинәт вафат була һәм туган төбәгендә – Чүпрәле районының Кече Шәйморза авылында җирләнә. Гомеренең ахырына кадәр халкына хезмәт иткән җырчының исеме яраткан тамашачылары күңелендә, сәхнәдәшләренең истәлекләрендә, җырларында яши. Рухы шат, урыны оҗмахта булса иде.

Сәхнәдәшләре җырчы турында

Татарстанның халык артисткасы Зөһрә Шәрифуллина:

«Габдулла абый Рәхимкулов белән мин 1980 нче еллар башында таныштым. Ул вакытта музыка училищесын бетереп, Җыр һәм бию ансамбленә эшкә килдем. Ә Габдулла абыйның исә, пенсиягә чыгып, иҗат эшчәнлеген дәвам иткән чаклары иде. Габдулла абый мине еш кына үзенең концертларына чакыра, юлда йөргәндә аталарча кайгыртуы, яратып «кызым» дип эндәшүе әле дә хәтеремдә. Миңа, атасыз үскән балага, «кызым» сүзен ишетүе гаҗәеп рәхәт иде. Фатирларга кергәндә дә үзе белән алып керә иде. «Безнең Зөһрә ит ярата, йомырка, бәрәңге белән генә котыла алмассыз», – дип, фатир хуҗаларын көлдерә иде. Сүз уңаеннан, шуны гына әйтим әле: элек кунакханәләргә керү юк иде, авылларда фатирларга урнаша идек. Иҗатымда тәүге роль уйнаучыларның берсе Габдулла абый Рәхимкулов булды. Мин аңа бик рәхмәтлемен. «Әкрен генә, кычкырмыйча җырла, моңга өстенлек бир, кызым, шулай булганда гына җырың кеше күңеленә барып җитәр», – дип киңәшләрен бирә иде ул. Гастрольдә төрле кызык хәлләр була иде. Гомумән, Габдулла абый җор

Бер төркем сәхнә ветераннары. К.Тинчурин театры бинасы. 1993 ел

телле, күңелле кеше булды. Ул концертны шундый җыр белән башлый иде: «Килмәс идем бу якларга, сез дусларым булмаса», – дигән сүзләр бар иде анда. Концерт беткәч, без, әлеге җырның сүзләрен үзгәртеп, үзара: «Килмәс идек бу якларга, акча кирәк булмаса», – дип көлешә торган идек. Әлбәттә инде, аның акчасы да кирәк, дуслар белән дә күрешәсе килгән чаклар булгандыр.

Тагын бер кызык хәлне искә аласы килә. Яшел Үзән районында бер авылда булды бу хәл. Авылның исемен хәтерләмим, салкын клуб, җылыткыч куйганнар. Шул җылыткычка басып, Габдулла абый сәхнәгә чыгарга әзерләнә. Берзаман гримерныйга көек исе чыкты. Габдулла абый бернәрсә сизмичә безгә эндәшә: «Алло, кем яна анда?!.» Карасак, Габдулла абыйның көрән кримплен чалбары эрегән. Шул көе, тамашачыга сиздермичә, күрсәтмичә генә җырлап керде. Кергәч: «Җырлавым җырлау булмады, гел чалбар турында гына уйладым», – дип көлдергән иде.

Тагын Габдулла абыйның хатыны Гамилә апа белән бер-берсенә булган мөнәсәбәтләре исемдә калган. Алар бер-берсенә «милыем» дип эндәшәләр иде. Бик матур яшәделәр. Кызы Тәнзиләне искә алмаган көне булмагандыр. Габдулла абыйның иң якын иҗатташ дусларының берсе баянчы, композитор Сафьян Ибраһимов булды. Сафьян Ибраһимовның бик күп җырларын ул беренче булып башкарды. Сафьян абыйдан башка гастрольләргә чыкканын хәтерләмим. Аннары ул халык җырларына бик зур өстенлек бирде һәм бездән дә шуны таләп итте. Азат белән бергә аны бик еш искә алабыз, сагынып сөйлибез. Шундый кешелекле, олы йөрәкле иде ул безнең Габдулла абый Рәхимкулов. Урыны җәннәт түрләрендә булсын».

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Мирсәет Сөнгатуллин:

«Габдулла абый белән төрле концертларда бергә чыгыш ясарга туры килде. Заманында Спорт сараенда Республика көнен билгеләп үткәндә, Татарстан турында җырны башкаргач: «Шәп җырладың!» – дип әйткәне истә калган. Мәскәүдә Мулланур Вахитовның 100 еллыгы уңаеннан 1985 елда узган зур концертта да бик күп артистлар белән бергә чыгыш ясадык, Габдулла абый шунда: «Энекәш, болай ялгыз йөрмә инде, өйлән син», – диде. Күп тә үтми, шунда булачак иптәшем Кадрия белән танышып та киттем. Аннары Габдулла абый талантлы яшьләрне гел мактап, үсендереп җибәрә иде. Мин бер концертта «Кичке авыл көен» җырлагач, ул миңа: «Синең тавышың шәп, тавышыңа халык җырлары бата, шулай дәвам ит, мин дә халык җырларыннан башладым, «Шахта», «Сарман», «Дөм-дөм» кебек озын, моңлы көйләрне өйрән», – диде. Уфада узган концертта, Фәридә апа Кудашеваның

да: «Синең тавышың моңлы, халык җырларын күңелеңнән төшермә», – дип әйткәне истә калган. Гомумән, халык бәгырендә урын алган шундый җырчылар белән бер сәхнәдә чыгыш ясавым, аларның уй-теләкләрен ишетүем белән бик бәхетле мин».

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәйдәр Сафин:

«Безнең буын кешеләренең яшьлеге Габдулла абый Рәхимкулов кебек моңлы җырчыларыбызның иҗаты чәчәк аткан чорга туры килде. Бигрәк тә авыл халкы аны бик үз итте, яратты. Җырлавы ягыннан ул – самородок. Беркем дә моны инкяр итми. Ул баянчыларга бик игътибарлы, аларны якын итеп, яратып сөйли иде. Рәис Сафиуллин, Рафаэль Курамшин, Рамил Курамшин, Фәйзи абый Садыйков, Фәрит Хатыйпов, Данис Хафизовлар аның белән бергә эшләделәр. Кыска гына вакыт инструменталь ансамбльгә дә кушылып җырлады. Башлыча аның бөтен язмалары да баяннар белән булды. Сара Садыйкованың «Кайтыгыз, торналар» җырын ул алып чыкты: Рамил Курамшин, Габдулла абый һәм Сара апа белән бер тапкыр репетиция ясыйлар да, аны радиога барып яздыралар. Тәүге тапкыр башкарылган җыр булса да, ул тыңлаучыга әллә кайчан язылып, шомарып беткән җыр кебек тоела. Күренекле композитор Рөстәм Яхин аңа бервакыт «Үзең аңла» дигән җырның нотасын язып бирә, Габдулла абый аны гастрольдә чакта көйләп йөри, әлбәттә, нота белеме юк, әмма баянчысы ярдәмендә тиз өйрәнә. Аны өйрәнгәндә Габдулла абый: «Үзем җырлыйм, үзем елыйм», – ди, ул аның күңеленә шулкадәр тәэсир итә, күрәсең, йөрәге аша үткәреп, бөтен күңелен биреп җырлый. Рөстәм Яхинга тыңлаткач, композитор: «Чын халык көе ясагансың икән бу җырдан», – дип, шулчакта аңа соклануын белдерә».

Рәсемдә Г.Рәхимкулов (сулдан беренче), Данис Хафизов (уңнан беренче), алдагы рәттә сулдан – Мансур Шиһапов, Лена Шагыйрьҗан

Татарстанның халык артисты, баянчы Кирам Сатиев:

«Без аның белән соңгы тапкыр 1997 елның 1 октябрендә Арча районының Урта Бирәзәбаш авылындагы мәчеттә (ул бер үк вакытта мәдәният йорты да булып тора иде) концерт бирдек. Бу Габдулла абыйның сольный концерты иде. Дөрес, ул моннан соң да Язучылар берлеге йортында җырлаган, ләкин үз концерты түгел иде. Әле тагын да эшләргә исәбе бар иде аның, тик көтмәгәндә арабыздан китеп барды. Сөекле җырчыбызның, «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исеме бирелү уңаеннан, концерт афишасын да миңа ясатырга туры килгән иде, тик, ни кызганыч, ул афишалар белән эшләргә язмаган икән. Вафатына бер ел тулу алдыннан Габдулла Рәхимкуловны искә алырга туган авылына – каберенә бардым. Җәсәде Казаннан ике йөз чакрым чамасы ераклыкта ятса да, ул безгә якын, бүген дә безнең арада күк...» ■

Җуелмас хәзинә

«Балкый Шәйморза утлары» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Балкый Шәйморза утлары

(Мостафа Ногман сүзләре, Сара Садыйкова көе)

Балкый Шәйморза утлары
Зәңгәр таңнарга кадәр.
Шәйморзаны оныта алмыйсың,
Бер барып күрсәң әгәр.

Кушымта:
Шәйморза, Шәйморза,
Туган җиребез Шәйморза;
Безнең яшьлек елларыбыз
Гөр килеп синдә уза.

Мактанмый безнең Шәйморза
Урманнар, күлләр белән.
Балкый ул кайнар йөрәкләр,
Якты күңелләр белән.
Кушымта.

Яшь кызларын, егетләрен
Шәһәрләр, вузлар тарта.
Бик күпләре, канатланып,
Туган якларга кайта.
Кушымта.

Яңара безнең Шәйморза,
Нурланып үсә һаман.
Илебез күгендә янган
Бер якты йолдыз сыман.

Кушымта:
Шәйморза, Шәйморза,
Туган җиребез Шәйморза;
Безнең яшьлек елларыбыз
Гөр килеп синдә уза.

Мәшһүр җырчы, ТАССРның атказанган (1970) һәм Татарстанның халык артисты (1996), Чүпрәле районының Кече Шәйморза авылы тумасы Габдулла Рәхимкулов (1926-1997)

Әлеге атаклы җырның барлыкка килү тарихын Татарстанның атказанган икътисадчысы Сәгыйть Бикчуров яхшы хәтерли. Ул вакытта Сәгыйть абый «XXII партсъезд» колхозының баш бухгалтеры булып эшли. Сәгыйть ага колхоз эшләре белән район үзәге Чүпрәлегә җиңел машинада бара. Эшләрне башкара торгач, кич җитә. Бер төркем галимнәр Казаннан районга иҗат сәфәренә килгән була. Шул вакытта телефон аша шалтыратып, Шәйморзага Чүпрәледән группа составындагы шагыйрь Мостафа Ногманны алып кайтырга кушалар. Сәгыйть Бикчуров юлда кайтуларын болай дип искә ала: *«1968 елның көз айлары. Бу вакытта район 1967 елдан Буадан Чүпрәлегә күчкән иде инде. Юлга чыкканчы шактый караңгыланып өлгерде. Ул вакытта әле Чүпрәлегә асфальт юл юк, әйләнгеч юллардан Тархан Убие аша, Кече Чынлы авылы, аның уртасындагы бик таза булмаган күпер аша уздык. Юлда сөйләшеп кайтабыз. Мостафа үзе дә төрле хәлләр сөйли, шофер Алиакберов Әсхәт тә сүзгә кушыла. Шулай кайта торгач, сүзләр бетте. Инде кайтып җитәбез дигәндә, бер борылышны узгач, иңкүлектә ялт итеп Шәйморза утлары күренде. Әле генә тирә-як караңгы иде һәм кинәт электр утларына күмелгән Шәйморза күренеше шагыйрь күңеленә тәэсир итте, Ногман урыныннан кузгалып куйды һәм бераздан авыз эченнән генә нәрсәләрдер көйли башлады...»*

Бу вакыйга онытыла да башлаган була инде. 1968 елның җәендә Шәйморза авылында Габдулла Рәхимкулов кайта икән, дигән хәбәр тарала. Җырчы үзе белән шагыйрь Мостафа Ногманны һәм композитор Сара Садыйкованы алып кайта.

«Башта җырны Габдулла Рәхимкулов идарәдә җырлап күрсәтте. «Балкый Шәйморза утлары» дигәч тә, кышкы юлда Чүпрәледән кайту искә төште. Кичке концертта мәдәният йорты халык белән шыгрым тулы иде. Концертның үзәгендә «Балкый Шәйморза утлары» җыры булды. Текст авторы Мостафа Ногман җырны нәкъ халыкча итеп, моңлы да, дәртле дә итеп язган иде», – дип хәтерен яңарта Сәгыйть Бикчуров.

Тәртип радиосы

*Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – **Гөлфия Мөхәммәтгәрәева**) материалларына нигезләнеп, **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Өрәңге

Түрәң Кобагыл өрәңгедән каты икән.
«Идегәй»

Өрәңгенең безнең илдә кырлы-кырлы киң яфраклысы таралыш алган. Бу агач уртача 200 ел яшәргә мөмкин, биеклеге – 30 метрга, юанлыгы метр ярымга кадәр җитә. Олы өрәңгенең кайрысы көрән төскә керә. Яфраклары эре, биш чатка җәенке, бик үзенчәлекле матур, аның яфракларын башка бер агач яфрагы белән бутап булмый.

Туфракка талымлы булганлыктан, төньякка таба ул яхшы туфраклы җирләрдә генә чыршы, нарат белән бергә очрарга мөмкин. Өрәңге шулай ук кара туфраклы, дымсу, әйбәт җирне, күләгәле урынны ярата. Кискәч тә, яңа үсентеләрен тиз чыгара, тиз үсеп тә китә, орлыгын чәчеп, үзлегеннән дә бик җиңел тарала.

Язын өрәңгенең ботакларында кечкенә-кечкенә саргылт-яшел чәчәкләр пәйда була. Ул чәчәкләр агачта беренче яфраклар күренгәнче генә тора.

Өрәңге агачы уен кораллары ясаганда кулланыла, аннан эшләнгән коралның тавышы ачык, чиста була.

Нык агач исәпләнгәнгәдер, өрәңгедән утын өчен агач хәстәрләүдә кирәк булган чөйләр ясыйлар. Агачның әлеге сыйфатын белгән элекке кеше өрәңгедән нечкә, озын тешле тараклар, кашыклар ясаган. Бу турыда җырлар да чыгарган:

«Җырларга (ди) кушсагыз (да) без
җырлыйбыз,
Өрәнгедин (лә), өрәнгедин кашык (ди)
сырлыйбыз;
Саклый торган, саклый торган
җырыбызны җырлыйбыз».

Өрәңге яфрагы

Өрәңге агачының яфраклары элек-электән үзенең матурлыгы, үзгә формасы белән үзенә җәлеп иткән. Борынгы болгарларның күп кенә эшләнмәләрендә өрәңге яфракларын күрергә була. Өрәңгенең каты сортларын идән җәю өчен паркетлар, мебель ясауда кулланалар, агач спирты алалар, йомшакларыннан тартмалар, тоткалар, каләмнәр эшлиләр.

Татар мәдәниятендә паремик берәмлекләр бик аз күләмдә. Асылда алар мәзәк төсмерен алган, тел бизәгеч рәвешендә кулланыла: «Хәзер өрәңгедә өрек үстерәләр, Базарың гына якын булсын»; «Юкәгә утыр, өрәңгегә кара, Бабаңның сакалын тара».

Сәхифә «Татар халкы традицияләрен саклау һәм үстерү «Татар ядкярләре» шәхси учреждениесе (җитәкчесе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе ***Фәнзилә Җәүһәрова****) белән берлектә әзерләнде.* ■

Өрәңге турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Өрәңге дәвалый

Өрәңге төнәтмәсе

Өрәңге чәе

Борын-борыннан татарлар өрәңгегә дәвалау чарасы итеп караган һәм аны халык медицинасында актив кулланган. Аның ботакларын, яфрагын үт һәм сидек кудыргыч, антисептик буларак файдаланганнар, согын витамин кытлыгыннан һәм иммунитетны ныгыту өчен, зәңгелә авыруыннан, нерв системасын торгызу өчен эчкәннәр. Өрәңгенең орлыгы – ашказаны һәм эчәк эшчәнлеген җайга салуда бик яхшы чара. «Өрәңге яфрагы чәен инсульт һәм инфаркттан профилактика чарасы буларак та эчәргә кирәк», – дип киңәш итүчеләр бар.

Казан арты татарлары өрәңге актив үсә торган урманнарда аның суын күпләп хәстәрли. Ул хәтта каен суына караганда баллырак һәм туклыклырак та исәпләнә. Өрәңге суын апрель башында, агачның суы кәүсә буйлап хәрәкәт итә башлагач җыялар. Бу эшне башкарганда табигатькә, агачка зыян салмыйча, сак эш итәргә кирәк, җыйганда комсызланмыйча, чама белән, шифа өчен, дип җыярга киңәш ителә.

Инде мәшһүребез **Каюм Насыйри** (1825-1902) язганга игътибар итик:

«Өрәңге (клен) агачының гарәпчә исеме беленмәде. Дәүләтебездә күренекле агач, һәркайда бар. Өрәңгенең яшь яфракларын һәм бөресен кайнатып эчсәң, эчтәге катуларга, күкрәк авыруларына сихәт бирер. Шулай ук ул сидерткеч тә, согы бәвелгә файдалы. Дару өчен бер кадак суга өрәңгенең ике-өч яшь яфрагын салып, өч чирек кадак калганчы кайнатып кулланалар. Әгәр берәү яз башында көн саен берәр касә өрәңге суы эчсә, гомерендә зәңгелә зәхмәте күрмәс, дип әйтә табиблар. Өрәңге суы каен суыннан татлырак һәм файдалырак, диләр».

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2022

Килен төшә – тура пешә

Чүпрәле районында татар һәм чуаш халыклары бер-берсенең традицияләрен, мәдәниятен һәм милли бәйрәмнәрен хөрмәт итеп, тату яши. Чыннан да, биредә татар халык бәйрәме Сабан туе чуаш халкының яраткан Уяв бәйрәме белән бертигез дәрәҗәдә үткәрелә. Халыклар дуслыгы төрле чараларда, йолаларда гына түгел, ә милли ашларда да ачык сизелә. Мәсәлән, пәрәмәч һәм кабартма кебек тәмле сыйлар чуаш һәм татар йортларында әле дә табынга бик яратып куела. Әлбәттә, һәрберсенең үзгә рецептлар җыентыгы, ашлар төрлелеге сакланып калган.

Чүпрәле районы татарлары гына пешергән ризыкларның берсе тура дип атала.

Татар халкының элек-электән терлек асрау белән шөгыльләнгәнлеге билгеле. Моннан чыгып, татарлар ит кенә түгел, ә шул мал-туар, кош-корт биргән продуктларны – сөт, йомырка кулланган дип әйтергә була. Татар халык ашларында сөт бик зур роль уйный. Ул аерым сый булып та эчелә, камыр ризыкларына да кушыла, эчлек ясаганда да салына. Сөтне бала имезгәндә кулланганнар яки чәйгә салып эчкәннәр. Олылар исә әче сөт продукциясенә өстенлек биргән. Мәсәлән, әчетелгән сөттән күпләрнең күңеленә хуш килгән катык ясаганнар. Май язганда (каймактан май ясаганда) исә әйрән барлыкка килә. Сөтне кайнатып, эремчек тә әзерләгәннәр. Аны башта махсус капчыкларга (мәсәлән, берничә кат марлядан тегелгән) салганнар һәм, элеп куеп, суы сыркып беткәнче тотканнар.

Эремчек – татар халкы ашларында еш кулланыла торган ризык. Аны казанда кайнатып, күп сыйларга туры килгән эчлек – корт ясаганнар. Кортны төрле кайнатмалар белән туглап, яңа төрле эчлекләр дә булдырырга өлгергәннәр. Билгеле булганча, эремчектән сыр да ясап була. Әмма сырны бай татарлар гына табынга куйган, гади халык аның белән кызыксынмаган. Гадәттә, эремчекне өстәлгә туглап, төрле җиләк кайнатмалары яки җиләк-җимеш белән чыгарганнар.

Алда әйтелеп узганча, эремчекне камыр ризыкларына эчлек буларак кулланганнар. Ләкин эремчек шулай ук үзе дә камыр буларак файдаланыла алган. Чүпрәле районында сакланган тура рецепты да нәкъ шундыйлардан. Әйдәгез без дә аны пешереп, авыз итеп карыйк.

Тура әзерләү турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Кирәкле ингредиентлар:

- 500 гр эремчек;
- ½ стакан он;
- 1 йомырка;
- 30 гр атланмай (эретелгән);
- ¼ чәй кашыгы тоз;
- ¼ чәй кашыгы сода.

Эш барышы:

1. Башта эремчекне яхшылап туглыйбыз. Аннары шуңа бер йомырка сытабыз һәм янәдән яхшылап болгатабыз.
2. Әлеге массага ¼ чәй кашыгы сода һәм тоз салабыз. Тагы туглыйбыз. Килеп чыккан катышмага он өстибез.
3. Бу массаны камыр сыман изеп, түгәрәк формага китерәбез.
4. Тура өстен атланмай белән майлыйбыз.
5. Килеп чыккан «кабартма»ны 180 градуска мичкә куябыз.

«Килен төшә, тура пешә», – дигән халык әйтемен ишеткәнегез бармы? Бу сүзләр татар халкының борынгы йолаларына килеп тоташа. Чүпрәле районында килен төшүнең үз үзенчәлекләре бар. Кияүгә чыккан һәр килен тура пешерә белергә тиеш булган. Тураның никадәр тәмле, йомшак һәм йомры булуы кызның никадәр уңган, оста хатын икәнлеген исбатлаган.

Тура яшь киленнәр арасында гына түгел, ә инде күптән кияүгә чыккан кызлар өчен дә актуаль аш-су. Шуңа сез дә туганнарыгызны шундый тәмле, шул ук вакытта җиңел әзерләнә торган тәм-том белән сыйларга ашыгыгыз.

(Сүз уңаеннан: кайбер якларда эремчек коймагын да пешерәләр.)

*Сәхифәне **Айзилә Сабирова** әзерләде.* ■

Көлке куа килә...

Әхәт Фазылҗанов (1927-2009)

Ике әти

Нәкыйп, эшеннән иртәрәк китеп, өенә кайтып яткан булган. Шулчак, йорт хуҗасын сорап, кемдер телефоннан шылтыраткан.

Хуҗабикә исә:

– Әтиләре эштә шул әле, кайтмады, – дип ялганлаган.

Моны ишетеп торган биш яшьлек Марат:

– Әни, безнең әти икәүме әллә? – дип сорап куйган.

– Нишләп алай дисең?

– Бер әти бүлмәдә йоклап ята, икенчесе эштә мени? – диган малай.

1990

Туфан Миңнуллин.
Илдус Әҗемов шаржы

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Юану

Тышта кыш – буран котыра.
Карап торам тәрәзәдән:
Борын очын уа-уа,
Егет бара бер кыз белән.

Үзе, бәгырь, көлгән була,
Кызга нидер әйткән була.
Карап торам тәрәзәдән –
Күңел йомшый, күңел тула.

Яшь егетләр нужа чигә,
Мин өемдә, мин җылыда.
Хатын коймак чыжылдата –
Кайчак ярый ир булу да.

Әхмәт Рәшит (1936-2020)

Кайбер редакторларга

Эт турында шигырь яздым,
Тик бастырган чагында
Этемнең калмаган иде
Теше дә, тырнагы да.

Рәшит Гәрәй (1931-1999)

Эпиграмма

(Шәрәф Мөдәррискә)

Тормышка ят булган нәрсәләрне
Эзли идең элек һәр төштән...
Тының чыкмый соңгы вакытларда,
Курыктың мәллә Әбдүштән?!

Земфира Гыйльметдинова (1967-2021)

Итле тавыш шәп яңгырый

Кемнән кем яхшы? Ач артисттан тук артист яхшы! Татарстанның халык артисткасы Әлфия Афзалова районнарда концертлар белән йөри. Бер колхозда боларны бик әйбәт кунак итәләр. Икенчесендә шулпа «сыеграк» була. Сәхнәдән Әлфия апа: «Кичә, ит ашагач, тавыш шәбрәк чыккан иде. Бүген, бәрәңге генә ашагач, бик җырлап булмый шул», – ди. Бурлаттай кызарган колхоз рәисе бәлеш пешерергә кеше чаптыра. «Гаебен» шулай төзәтә.

Равил Шәрәфи (1938)

Эпиграмма

*(Чүпрәле районының
Кече Чынлы авылы тумасы
Ринат Таҗетдиновка)*

Каты теллле мишәр идең,
Йомшардың тора-бара.
Хәзер синдәй йомшак телне
Театрда табып кара!

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2022



БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БАЛАЧАКТАН

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Каюм Насыйри (1825-1902)

Комсыз эт

(Мәсәл)

Авызына сөяк капкан бер эт күпердән чыкканда суда үзенең шәүләсен күрде, үзе кебек, ул эт тә авызына сөяк кабып йөгереп бара икән. Ләкин аңар судагы этнең сөяге зуррак кебек күренде. Шунлыктан үзенең авызындагы сөякне суга төшерде дә үзе суда күренгән эт авызындагы сөякне алмакчы булып суга сикерде. Ләкин ул арада инде авызындагы сөяге дә су төбенә киткән иде.

Кави Нәҗми (1901-1957)

Көз

Үтте-китте матур җәйләр,
Көзләр килеп җиттеләр.
Ак каенның яфраклары
Саргаешып киптеләр.

Әхмәт Исхак (1905-1991)

Чишмә

Тау астында чишмәбез,
Су алырга төшәбез.
Татлы суын без аның
Бик яратып эчәбез.

Гамил Афзал
(1921-2003)

Беренче кар

Кояш йөри сүрелеп кенә,
Болытка төренеп кенә.
Кыяр-кыймас әйләнгәләп,
Кар ява иренеп кенә.

Бу әле кышның малае,
Бу – беренче кар әле.
Ак сакаллы, җил-буранлы
Кыш бабае бар әле.

Табигатьтә кунакта

Жираф

Жираф – җирдәге хайваннарның иң озыны. Аның озынлыгы алты метрга җитә һәм шуның яртысы муенына туры килә. Койрыгы бер метр чамасы.

Жирафларның казык тешләре дә, тырнаклары да юк. Алгы аяклары арткыларыныкыннан озынрак. Жираф чабыш атларыннан ким йөгерми.

Зәки Нури
(1921-1994)

Без инде хәзер зурлар

Уйныйлар биттә нурлар,
Әлифба алды куллар.
Мәктәпкә илтә юллар...
Без инде хәзер зурлар!

Сүз ясарга өйрәнәбез
Хәреф кушып хәрефкә.
Тапкырларбыз, бүләрбез
Төрле санны дәрестә.

Ак кәгазь буйлап үтәр
Безнең тәүге юлыбыз.
Оста эшчеләр итәр
Безне оста кулыбыз.

Әнә алыр кулга, без
Киң келәмнәр чигәрбез.
Чыгып иркен кырга, без
Бергә иген игәрбез.

Бердәм атлап йөрербез –
Талмаслар аяк-куллар.
Тиздән мәктәпкә керербез,
Без инде хәзер зурлар!

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ОКТЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● **25 сентябрь-4 октябрь** көннәрендә Пермьдә, Екатеринбург һәм Серов шәһәрләрендә (Свердловск өлкәсе), Чиләбедә һәм Троицкида, Бәгәрәктамак һәм Мөслим авылларында (Чиләбе өлкәсе) Бөтенроссия татар төбәкчеләре форумы булып узды. Әлеге чарада «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон да катнашты.

● **Октябрьдә** язучы, тәрҗемәче, әдәбият белгече, «Безнең мирас» журналы авторы, Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы районындагы Иске Төгәлбуга авылы тумасы, шушы көннәрдә генә 90 яшен тутырган Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллинның «Ерактагы ак җилкәннәр» дигән китабы (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2022) дөнья күрде.

● **6 октябрьдә** ТР Дәүләт Киңәшчесе, ТРның Беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев шәхси архивындагы өч меңнән артык китабын ТР Милли китапханәсенә тапшырды.

● **8 октябрьдә** Мари-Эл Республикасының Бәрәңге бистәсендә Насретдиновлар исемендәге I нче фәнни-мәгариф төбәкара конференция булып узды. «Мари-Эл җирендә ислам горефләре. Фидаймөхәммәт хәзрәт (1869-1924) һәм Хәлилрахман хәзрәт (1890-1964) Насретдиновлар мирасы» исеме белән үткән әлеге күркәм чарада МР мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе Фәрит Шаһиев, Бәрәңге муниципаль район хакимияте башлыгы Әлфит Ибраев, БТКның Аксакаллар шурасы рәисе Рәүф Хәсәнов, Бәрәңге район газетасының баш мөхәррире Фәнил Мусин, ТРның «Сугышчан дан клубы» ассоциациясе рәисе Михаил Черепанов, «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Ләбиб Лерон, Ленар Гобәйдуллин һ.б. катнашты.

● **11 октябрьдә** «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Чүпрәле районында эшлекле сәфәрдә булып, хакимият башлыгы Марат Ринат улы Гафаров белән очрашты.

● **13 октябрьдә** Татарстан Язучылар берлегендә Төркиядә дөнья күргән «Татар хикәяләре антологиясе» (тәрҗемәчесе – Фатиһ Кутлу) тәкъдим ителде.

«Әлеге антология Мәскәүдә рус телендә басылып чыгачак. Азәрбайҗан телендә дә нәшер ителә, Казакъстан белән дә сөйләшүләр бара. Бәлки, ул вакытта, үзгәрешләр кичереп, яңа авторлар да өстәлер», – диде Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла.

Татар әдәбияты тарихында мондый антология соңгы тапкыр моннан 30 ел элек, ягъни 1992 елда басылган булган.

Әлеге күркәм чарада катнашкан һәм «Татар хикәяләре антологиясе»нә хикәяләре кергән язучыларга – Рабит Батулла, Марсель Галиев, Вахит Имамов, Ринат Мөхәммәдиев, Фоат Садриев, Галимҗан Гыйльманов, Рифә Рахман һәм Хәбир Ибраһимга кичә ахырында китаплар тапшырылды.

● **13 октябрьдә** Татарстан Язучылар йортының Г.Тукай исемендәге клубында язучы, нәфис сүз остасы, баянчы, җырчы, композитор, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Түбән Каманың Ташлык авылы тумасы Алмаз Наил улы Хәмзинга 75 ел тулуга нисбәтле әдәби-музыкаль кичә булып узды.

● **14 октябрьдә** Татарстанның Норлат районында татар театрына нигез салган Габдулла Кариевка һәйкәл (скульпторы – Россия һәм Татарстан Рәссамнар берлекләре әгъзасы Александр Дресвянников) ачылды.

Тантаналы чара ТР Дәүләт Советы Рәисенең урынбасары, татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре буенча ТР Президенты каршындагы комиссия рәисе М.Әхмәтов, ТР мәдәният министрының урынбасары Д.Натфуллин, РФ Дәүләт Думасы депутаты А.Метшин һәм республика театрларының баш режиссерлары, шулай ук күпсанлы мактаулы кунаклар, театр сөючеләр катнашында узды.

● **18-22 октябрь** көннәрендә «Мәдәни җомга» газетасының һәм «Безнең мирас» белән «Казан утлары» журналларының баш мөхәррирләре Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин Оренбург өлкәсендә һәм әлеге өлкәгә чиктәш булган Башкортстан районнарында эшлекле сәфәрдә булып кайтты. ■

МИРАСВОРД

Мич агарткыч

Язучы ... Рәкыйпов

...-Абеба

Шагыйрь Нәҗип ...



Шагыйрь ... Аймәт

Сынчы ... Нигъмәтуллина

Актриса ... Хәйруллина

Кабыгыннан буягыч матдә алына торган тропик агач

Борынгы грек мифологиясендә: сугыш алласы

Индуизм мифологиясендә: изге үгез

Хәсән Туфан поэмасы

Чүпрәле районындагы авыл җирлеге

Борынгы Урарту дәүләтендә яшәгән кабиләләр төркеме

Беларусь каласы

«... да бер кичә»

Борынгы Рим мәсәлчесе

Язучы ... Шабай

Борынгы һинд эпосы

Борынгы грек мифологиясендә: уңыш алласы

Татар яшьләре журналы

Амудәрьяның борынгы исеме

Һинд хатын-кызлары киеме

Укылган текстны үз сүзләрең белән кабат язу

Зур скрипка

Җырчы Фәхри ...

Мәдәният йорты

Әтнә районындагы авыл

1912-1918 елларда Казанда татарча чыккан әдәби журнал

Кыерсытырга бирмәү, канат астына алу

Теркәгеч

Мөнир ... (Уфада яшәүче татар шагыйре)

Тәрҗемәче ... Миңлебаев

Мавритания акчасы

Хуҗа, башлык

Татар эстрадасы җырчысы

«... Скала» театры

Мөгез быргы (иск.)

Үзәк Азиядәге скиф, Иран кабиләләре яшәгән тарихи төбәк

Сунар

Татар шагыйре дә, уен коралы да

Балетмейстер ... Таһиров

10 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: күнәк, Гата, Кәрам, дар, сыза, Тәслимә, куа, Галиев, флокс, «Уку», Вәлиев, сада, хәя, Хайт, Ра, кәлам, Вәлиди, Хуҗи, Мансур, сари, Нуаре, фәни.
Өстән аска: какы, Густав, Тракай, ниргә, луда, Ахриман, Камалиев, Ада, вәхи, Инсаф, әл, Сара, «Әлфия», Неру, ел, Фәхри, Садыйкова, Лу, «Таз», ук, таҗ, Карамасар, Ми.

Рәис Габдулла *төзеде.*

«Безнең мирас»
елъязмасы / ноябрь

Казан кирмәне

470 ел элек (1552)

Казанны яклаучылардан биш тапкырга ишлерәк булган Мәскәү гаскәре каланы яулап алганнан соң, башкаладагы бихисап байлыкларны талау, халкын аяусыз рәвештә үтерү дәвам итә.

210 ел элек (1812)

Мәшһүр фикер иясе һәм дин белгече Габденнасыйр Ибраһим улы әл-Курсави (1776-1812), хаҗ сәфәренә чыккан юлында авырып китеп, Истанбул шәһәренең Азиядәге өлешенә караган Искедар бистәсендә вафат була.

115 ел элек (1907)

Петербургта Рәшит казый Ибраһимов мөхәррирлегендә, казакълар катнашы белән, «Сиркә» *(җитәкче)* исемендә газета нәшер ителә башлый.

100 ел элек (1922)

8 ноябрьдә Казанда «Октябрь революциясе» исемендә беренче татар театры рәсми рәвештә ачыла. Төрле оешмаларның тәбрикләвеннән соң, Фәтхи Бурнашның «Җирсезләр» дигән әсәре буенча куелган спектакльнең бер пәрдәсе уйнала.

85 ел элек (1937)

7 ноябрьдә Казанда В.И.Ленинның (1870-1924) музей-йорты эшли башлый.

80 ел элек (1942)

7 ноябрьдә Татар дәүләт академия театрында Нәҗип Җиһановның «Илдар» операсының (Муса Җәлил либреттосы) премьерасы күрсәтелә.

60 ел элек (1962)

10 ноябрьдә Мәскәүдә татар совет язучысы Мәхмүд Максуд (1900-1962) вафат була.

30 ел элек (1992)

1 ноябрьдә Төркиядә төрки әдәбият вәкилләренең корылтае тәмамлана. Корылтайда төрки халыклар язучылары берлеге оештырыла, берлекнең рәистәше итеп Ринат Мөхәммәдиев сайлана.

6 ноябрьдә Татарстан Республикасының Төп Кануны – Конституциясе кабул ителә.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Содержание. Ноябрь 2022

И останется в мире слово моё...: Заки Нури.

Историческое наследие: «Парень из Чынлы – достойный наследник Марджани». И.Закиров; «Надгробный памятник Сафиулла бине Абдуллы». А.Гайнутдинов; «Утерянная и вновь найденная деревня». В.Данилов; «Легенды Уби». А.Сабирова; «Дрожжанное в прошлые века». И.Гафаров; «Одеяние остроумной чувашки». А.Сабирова; «Татарский мир 100 лет назад»; «Кадыкай абыз». И.Закиров.

Татарский мир: «Марат Гафаров: «У полиглотов духовный мир богаче»; «Мунчали – село с богатой историей и культурой». И.Измайлов; «Ильяс хазрат Зиганшин: «Мы на себя взяли большую ответственность»; «Мы – внуки деда Иманкула». И.Халитов.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Наследие братьев Хамиди». Н.Махмутов; «Хадисы пророка Мухаммеда (с.г.в.)». А.Рахими.

Литературное наследие: «Стихи Шарафа Мударриса»; «Певец бессмертия». Н.Хисамов; «Хайдар Гайнутдин: «Снег выпадает там, где не ждешь...»

В глубинах памяти: «Поломничество». Л.Лерон; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Народный певец». А.Хакимова.

Алхәбәр:

Шагыйрь Мостафа Ногман улы Искәндәр белән. *(«Татар йөзе»)*

«Безнең мирас» галереясы

«Ялгызлык». 2020 ел. *Картон, гуашь. Журналист һәм язучы Дания Гайнетдинова эше*

«Яңгырдан соң». Мунчәли. *Айдар Хисамов*

«Туган якта». Мунчәли. *Айдар Хисамов*

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- ***uslugi.tatarstan.ru*** сайты ярдәмендә
- редакциядә
- ***podpiska.pochta.ru*** сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.